ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№03 (374)
МАРТ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

«ТАТАРСТАН» ХАНБИКӘЛӘРЕ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

ҺӘР БИТТӘ – ХАНБИКӘ

Урамда март. Яз. Гүзәл туташлар һәм ханымнар...

«Татарстан» журналында алар аеруча матур күренә.

Һәр яз саен. Һәр март саен. Һәр март санында. Гүзәлләрдән гүзәл затлар гына!

Сезнең игътибарыгызга бүген без чын ханбикәләрне тәкъдим итәбез – ханбикәләр киеменнән, ханбикәләрчә сөйкемле һәм нәзакәтлеләрне! Барлык сорауларыбызга ханбикәләрчә җаваплары белән.

Алдыгызда – затлы сан, аны карау да, уку да бик рәхәт булыр, дип өметләнәбез.

Сезнең язгы редакциягез.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррире: Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Заһидуллин, Луиза Шарова, Николай Коновалов, Мария Ермакова, Анастасия Маркелова, Диләрә Сафиуллина
Фотографлар: Александр Ефремов, Александр Сафронов, Алсу Шакирова, Михаил Захаров, Мария Ефремова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Аль-Варис» медицина косметологиясе клиникасын оештыручы һәм аның баш табибы Лилия Муллахмәтова. Александр Сафронов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С-0618
Басарга кул куелды: 13.03.2023
Басмадан чыкты: 16.03.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«СОЮЗ»НЫҢ ЯШЕРЕН КОНСТРУКТОРЫ

Мәскәүдә ракеталарга каршы оборона (ПРО) стратегик система-
сының сугышчан кизүгә басуы турында илебез ММЧ тыйнак кына
эндәшми кала. Шулай ук ПРО составына кергән ракеталарга каршы
системаның двигательләре Казандагы «Союз» Тәҗрибә-конструк-
торлык бюросында уйлап табылуы турында да. Урамда – 1990 ел,
«Катгый яшерен» грифы тайпылышсыз үтәлә. Баш-конструктор –
«Союз»ның генераль директоры Ирек Фәхретдиновны бу хакта
хәбәрдар булырга тиешле кешеләр генә белә. Өстәвенә, ракеталарга
каршы система өчен каты ягулыклы двигательләр эшләү техник
фәннәр докторы Фәхретдинов һәм аның конструкторлык бюро-
сы катнашкан бердәнбер уңышлы оборона проекты булмый. «С-
300», «Бук» һәм «Давыл» зенит комплекслары өчен ракета, илнең
ракета-космик оборонасына кергән ракеталарга каршы системалар,
ерак авиация һәм тавыш тизлегеннән югарырак тизлекле раке-
та йөртүчеләр двигательләре – Казанның «Союз» конструктор-
лык бюросында уйлап табылган һәм коралланута кабул ителгән
эшләнмәләрнең бер өлеше генә. Соңрак шуны да исәпләп чыгара-
чаклар: Ирек Фәхретдинов дистәдән артык ракета двигателен уйлап
табуда һәм җитештерүдә катнашкан һәм бу эшкә җитәкчелек иткән.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Лаеклылар арасында иң яхшылар
РФ субъектлары башлыкларының «Милли рейтинг» проектындагы урыны

6. Утсыз-сусыз, әмма өмет белән
Лисичанскида Татарстан журналистлары нәрсәләр күрде

14. Кыюлык нәтиҗәсе
«Ел җитәкчесе» уңышка ничек ирешә

20. Директор һәм аның командасы
Алмазны ничек бриллиант дәрәҗәсенә җиткерергә

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

игелекле эшләр

24. Эшлекле ханымнар
Хәйриячелек белән бизнес ничек яраша

30. Редакция кухнясы
Ханнар сые

35. Ханбикәләр киемендәге ханымнар
Алар безнең тормышыбызны ничек бизи

46. Барысы да табигый булганда
Олеся Мостаевадан матурлык серләре

54. Дәва булырлык шәфкатьлелек
Алга таба яшәр өчен каян көч табарга

62. Әбидә кунакта
Элек керне ничек юганнар

66. Безнең кунакханәдә
Марсель Галиев ни өчен Алтайга барырга ярата

мәңгелек кыйммәтләр

72. Тарих сәхифәләре
Габделбари Баттал – татар-төрек галиме

80. Афиша
«Төшенкелеккә каршы» концерт кайда узачак

82. Татар авыллары
Нурлы Чутай

88. Югалмаган утрау
Ни өчен Зөягә кышын барырга кирәк

Фото: kremlin.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

24.02

Сергей Когогин, «КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры, – Яр Чаллы шәһәр советының йомгаклау сессиясендә:

– Җитди карар кабул ителде – КАМАЗ җиңел автомобильләр җитештерүгә әйләнеп кайта. Сез беләсез, без «Москвич» җыю белән шөгыльләнәбез, ләкин Татарстан турында да онытмыйбыз. «Атом» проекты кысаларында киләчәктә илебездә шәһәр мобильлеген үзгәртергә сәләтле цифрлы автомобиль булдыру планлаштырылды.

9.02

Ренат Мистахов, «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясенең генераль директоры:

– Җәен «Метеор»да каядыр барыр өчен кешеләр бер ай элек билет алып куярга мәҗбүр – болай булырга тиеш түгел. Әлегә без ике теплоход чыгардык. Әмма җитештерү куәтләре елына алты-сигез судно җыярга мөмкинлек бирә. Без СССР чорындагы күләмнәргә чыгуны планлаштырабыз. Ул чакта максатчан планлаштыру нигезендә елына 10 «Метеор» төзелә, тагын икесе икенче елга күчә иде. Әлегә без елына алтыдан алып сигез берәмлеккә кадәр судно җыя алабыз, әмма ихтыяҗ булганда күләмнәрне арттырырга да мөмкин.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР



22.02

Анна Трофимова, Дәүләт Эрмитажының Антик дөнья бүлеге мөдире, – Казанда, Дәүләт Эрмитажы тупланмасының «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсе ачылышында:

– Без үз проектыбызны Казан кебек күркәм шәһәрдә тәкъдим итә алуыбызга шат. Күргәзмә дөнья тарихының бөек эшлеклесе Александр Македонскийның Көнчыгыш походына багышланган кыска, әмма вакыйгаларга бай тормышы турында сөйли. Әлеге поход кешелек тарихын мәңгелеккә үзгәрткән. Без Македонскийның хәрби юлы турында гына сөйләп калмыйбыз, бәлки вакыт агышында сәяхәт кылабыз.

Фото: tatar-inform, мистахов-ренат.рф, grad-petrov.ru/Екатерина Степанова

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр /
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Лаеклылар арасында **кем** иң яхшысы

Лисичанскида Татарстан журналистлары **нәрсәләр** күрде

«Ел җитәкчесе» нәтиҗәгә **ничек** ирешә

Алмазны **ничек** бриллиант дәрәҗәсенә җиткерергә

РФ СУБЪЕКТЛАРЫ БАШЛЫКЛАРЫНЫҢ

«Милли рейтинг» проекты кысаларында 2022 елда Россия Федерациясе субъектлары башлыклары эшчәнлеген бәяләүгә багышланган йомгаклау тикшеренүе «Рейтинг» мәгълүмат коммуникацияләре үзәге тарафыннан әзерләнде*. Нәтиҗәләр эксперт берләшмәсе вәкилләрен читтән торып анкеталау, читтән торып һәм турыдан-туры сораштырулар нигезендә ясалды.

1 урын
СЕРГЕЙ СОБЯНИН
ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ

2 урын
РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

3 урын
РАМЗАН КАДЫЙРОВ
ЧЕЧЕН РЕСПУБЛИКАСЫ

4 урын
АЛЕКСЕЙ ДЮМИН
ТУЛА ӨЛКӘСЕ

ЭКСПЕРТ ФИКЕРЕ

АЛЕКСАНДР МАЛЬКЕВИЧ, сәясәт белгече, РФ Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Санкт-Петербург» телеканалының генераль директоры:

– Татарстан Республикасы һәм аның лидеры Рөстәм Миңнеханов узган елгы авырлыклар каршында югалып калмады, аларны вакытында күрә алуын һәм җавап бирергә әзер булуын раслады. Гаять катлаулы шартларда төбәк, кыенлыклар йогынтысында үсешен туктатмыйча, ресурсларны туплый һәм аларны дөрес юнәлтә белде. Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан ителүгә, Рөстәм Миңнеханов республика гражданнарының көнүзәк ихтыяҗларын тулысынча аңлап эшләвен күрсәтте. Солдатлар өчен булдырылган шартлар күзлегеннән караганда, Татарстандагы җыелу пунктларында көндәлек тормышны оештыруны үрнәк дип санарга мөмкин. Халыкара элемтәләр санының объектив кыскаруы шартларында Татарстан башлыгы 2022 ел дәвамында партнерлар таба белүен дә күрсәтте. Татарстан Республикасы җитәкчесенең халыкара сөйләшүләр процессында катнашуының югары дәрәҗәсен бу сәфәрләр вакытында Миңнехановның еш кына чит илләрнең беренче затлары белән очрашуы раслый.

* «Милли рейтинг» федераль иҗтимагый проектының эксклюзив операторы булып тора, халык һәм экспертлар бергәлегенең региональ хакимиятка мөнәсәбатен ачыклауда махсуслаша.

Фото: tatar-inform.ru, ТР Рәисе матбугат хезмәте, alexeydumin.ru, mosreg.ru, kremlin.ru, moskultura.ru, peoples.ru

«МИЛЛИ РЕЙТИНГ» ПРОЕКТЫНДАГЫ УРЫНЫ

ЭКСПЕРТ ФИКЕРЕ

АЛЁНА АВГУСТ, сәясәт технологы, җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч:
– «Быел ел авыр булды» дигән сүзләрнең мәгънәсе 2022 елда тулысынча ачылды, шул исәптән губернаторлар өчен. Нәкъ менә аларга үз төбәкләрендә илдә һәм хәтта дөньяда барган вакыйгалар өчен җавап бирергә туры килә. Махсус хәрби операциянең нәрсәгә, ничек баруы һәм аның кешеләр тормышында чагылышы, социаль-икътисадый өлкәдә нәрсәләр эшләнүе, халыкның бүгенгене ничек аңлавы һәм киләчәкне ничек күрүе өчен дә. Әйтергә кирәк, губернаторлар боларның барысын да төрлечә эшли. Артта калучылар бар, төрле рейтингларда шактый югары урыннарга ирешүчеләр бар. Минемчә, иң мөһиме – губернаторның кешеләрнең намус турындагы төп соравына җавап бирә алу сәләте. Халыкны борчыган теләсә кайсы сорау буенча анык һәм төгәл сөйләшү-аралашу булырга тиеш.

«Губернаторларның милли рейтингы» ШАКТЫЙ ТӨРЛЕ ПРОФЕССИОНАЛЬ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ӨЛКӘЛӘРГӘ КАРАГАН ЭКСПЕРТЛАРНЫҢ МАКСИМАЛЬ КИҢ ДАИРӘСЕН үз эченә ала. Бу тикшеренү нәтиҗәләрен демократик юл белән, «гади кеше» фикеренә якынайтып ясау мөмкинлеге бирә, шул ук вакытта, аңлашыла ки, бу эксперт җәмгыяте вәкилләренең хәбәрдарлыгы һәм анализлау сәләтенең зур булуын исәпкә алып эшләнә.

5 урын **АНДРЕЙ ВОРОБЬЁВ** МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ

6 урын **АЙСЕН НИКОЛАЕВ** САХА (ЯКУТ) РЕСПУБЛИКАСЫ

7 урын **АЛЕКСАНДР ДРОЗДЕНКО** ЛЕНИНГРАД ӨЛКӘСЕ

8 урын **ВЯЧЕСЛАВ ГЛАДКОВ** БЕЛГОРОД ӨЛКӘСЕ

9 урын **ЕВГЕНИЙ КУЙВАШЕВ** СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕ

10 урын **СЕРГЕЙ ЦИВИЛЁВ** КЕМЕРОВО ӨЛКӘСЕ – КУЗБАСС

11 урын **ДМИТРИЙ АРТЮХОВ** ЯМАЛ-НЕНЕЦ АВТОНОМ ОКРУГЫ

12 урын **АЛЕКСАНДР БУРКОВ** ОМСК ӨЛКӘСЕ

«Рейтинг» Мәгълүмат коммуникацияләре үзәге шәрехләвеннән:

– Экспертлар фикеренчә, 2022 елгы тышкы сәясәт факторлары Татарстан хакимияте өчен көтелмәгән булмаган, республика бу авырлыкларга адекват каршы тора алган: төбәктә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча оператив штаб эшли, предприятиеләргә ярдәм итү һәм халыкны беренчел кирәк-яраклар белән тәэмин итү планы кертелгән, эшкуарлык җәмәгатьчелеге өчен зыянны киметү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла, Донбасс төбәкләренә ярдәм билгеләнгән. Татарстанда күченергә мәҗбүр булган 1 000 нән артык кеше урнаштырылган, алар барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителгән.

Экспертлар фикеренчә, Петербург халыкара икътисадый форумы Татарстанга тагын бер мәртәбә үзен күрсәтү мөмкинлеге биргән. Анда республиканың Россия төбәкләрендә инвестицияле климат торышының Милли рейтингында икенче урынны яулавы, бары Мәскәүдән генә калышуы игълан ителгән. Ә РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко 2024 елда Казанның тарихта беренче мәртәбә халыкара статустагы «Киләчәк уеннары» югары технологияле кибертурнирын кабул итәчәге турында җиткергән. Һәм бу закончалыклы да. Республика көненә бирелдә югары технологияләр өлкәсендә яңа технопарк – «Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк» ачылган. Бу Татарстанда шундый өченче технопарк санала. Ә Татарстанның төп цифрлы вакыйгасы – Kazan Digital Week форумы IT-өлкәгә караган 200 дән артык проект тәкъдим иткән 65 ил вәкилен җыйган.

KazanSummit халыкара икътисадый саммиты, аерым алганда, «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик караш төркеменең пленар утырышы да Рөстәм Миңнеханов үзен күрсәтә алган мәйданчык булган. Узган елда гадәттәгечә Татарстан башлыгы халыкара мәйданда, аерым алганда, ислам дөньясы белән хезмәттәшлектә активлык күрсәткән. Моны РФ тышкы эшләр министры Сергей Лавров Казанны Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы башкаласы – 2022 буларак тәкъдим итү чарасында да билгеләп үткән.

ХӘРБИ ХӘБӘРЧЕ



ДИГӘН ҺӨНӘР БАР



Фото: Михаил Захаров, Александр Ефремов

Светлана Белова һәм Михаил Захаров Лисичанскига барганчы үзләрен хәрби хәбәрче санамый. Светлана – «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының вакыйгалар бүлеге мөхәррире, Михаил – фотохәбәрче. Һәм менә, волонтёр Мария Ефремова белән бергә, алар Луганск Халык Республикасына, Татарстан шефлыкка алган Лисичанск шәһәренә юл тота.



Лисичанскида гуманитар ярдәм тарату үзәге каршында кайнар ризыкка чират. Татарстан волонтёрлары көн саен 5 меңгә якын кешене ашата.

Тимер юлга төшкән ракета койрыгы. Поездлар биредә күптәннән йөрми, рельслар күгәрек белән капланган.



Ял вакыты. Волонтёр Мария Ефремова һәм Ася исемле батальон песие.



Луганск Халык Республикасы юлларында баннерлар күп. Аларда Россиягә рәхмәт белдерелгән, кушылганнан соң уңай якка үзгәрешләр турында язылган.

ЛАСКАВО ПРОСИМО!

Алар эшенең нәтиҗәсе – шушы көннәрдә «Татмедиа»да ачылган фотокүргәзмә. Халык бәйрәмнәреннән коронавирус эпидемиясенә кадәр – журналистлар тормышының төрледән-төрле якларын чагылдырган фотоларны күргән холл диварларына хәрби хәрәкәтләр турындагы сурәтләр беренче тапкыр эленде.

– Куркыныч булдымы? – дип сорыйлар күргәзмәгә килүчеләр, ядрәләрдән тишкәләнгән бина фотосын карый-карый.

– Әлбәттә, куркыныч! – дип җавап бирә Михаил Захаров. – Кайчан нәрсә очып киләчәген белмисең бит.

Ләкин фотограф объективы кыю һәм тиз эш итә. «Анда барма, монда йөрмә», «Боларын төшермә!», «Монда карама!» – дип әйтеп торсалар да, хәрбиләр сагы астында гына төшерергә туры килсә дә, күргәзмәгә куярлык кадрлар туплана.

Үзәк өзгеч кадрлар арасында журналистлар, мәсәлән, «12 стульев» фильмында Федор атакай кайнар су алырга дип төшкән Попасная станциясен танып алды. «Федор атакай юкка чыкты. Аны Донецк юлларындагы Попасная станциясендә күргәннәр дип сөйләделәр. Кайнар сулы чәйнеген тоткан килеш перрон буйлап арлы-бирле йөгереп йөргән...», – диелә әсәрдә.

– Мин көн саен үзем белән песиләрне ашатырга күп итеп ризык алып йөрдем, – дип сөйли Михаил. – Алар бик кызганыч, күбесе җимерекләр арасында иясез калган. Менә, мәсәлән, медвзводтан Ася исемле батальон мәчесе. Тиздән балалары туарга тиеш. Ә безнең Мария Казанга үзе белән Лисичанск шәһәреннән песи алып кайтып китте. Аңа Магнит дип исем кушты...

PRESSA

Лисичанск үзәгендәге бина. Мондый шартларда да кызлар матур күренергә тырыша.

Попаснаядагы атышлар нәтиҗәсендә ишелгән храм. Чаң манарасы гына җимерелми калган.

Шарон исемле эт. Кайберәүләр шәһәрдән киткәндә үзләренең эт-мәчеләрен калдырырга мәҗбүр булган. Хәзер аларны монда калган кешеләр һәм волонтёрлар ашата.

Попаснаядагы бәрелешләр вакытында зыян күргән скульптуралар.





Ә безнең Мария Казанга үзе белән песи алып кайтып китте. Аңа Магнит дип исем кушты...

БАРЫСЫ ДА ЯХШЫ!

– Минем алда Лисичанскига барыргамы-юкмы дигән сорау тормады, – дип искә ала Светлана Белова. – Мин вакыйгалар бүлегендә эшлим, шуңа күрә МХО башланганнан бирле даими рәвештә моңа кагылышлы хәлләрне яктыртып барабыз. Мария белән танышкач һәм аннан – чакыру, ә «аның батальонынннан» (Казаннан гуманитар ярдәм китерелә торган. – Ред. иск.) Лисичанскига килергә рөхсәт алганнан соң, Михаил белән без махсус әзерлек уздык һәм шул якларга юл тоттык.

Анда бер атна булдык. Бронежилетларда. Хәрби сак астында. Шартлауларга, атыш тавышларына күнегеп булмый, дип уйлыйм. Ләкин андагы халык ияләшкән. Безнекеләрдән үзгә, хәтта ки капма-каршы тормыш кыйммәтләре белән күзгә-күз очрашканда, бу айнытып җибәргәндәй була. Нәтиҗәдә син дөньяга яңача карый башлыйсың. Безнең монда тамагыбыз тук, өстебез бөтен, өебез җылы. Әмма гел нәрсәдер җитми, без һаман булганыннан канәгать түгел. Ә анда су юк, ут юк, җылы юк. Волонтёрлар китереп биргән кешеләрдә генә «буржуйка» мичләре бар. Ашау һәм су артыннан каядыр барырга, суны 4 нче, 7 нче катка ташырга кирәк...

«Хәлләрегез ничек?», «Ничек яшисез?» дигән сорауга алар: «Барысы да яхшы», – дип җавап бирә. Һәм Татарстанга, волонтёрларга ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерәләр, шәһәрнең торгызылуын көтәләр, тиздән барысы да яхшы булачагына ышаналар. Ә бу вакыйгаларга кадәр Татарстанның барлыгын да, Казанның кайда урнашканын да белмәгәннәр.

ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН БЕРЕНЧЕ БАРУЫМ

– Луганскига инде дүртенче мәртәбә баруым. Журналистлар белән – беренче тапкыр, – дип сөйли Мария Ефремова. – Барысы да автосәфәрләр белән мавыгудан башланды – берничә волонтёр миннән бирегә алып баруымны сорады. Ул вакытта без медицина взводына эләктек. Мин табибларның авыр яраланганнарга ничек ярдәм итүен үз күзләрем белән күрдем. Медиклар авыр шартларда эшли, аларга генератор кирәк иде. Казанга кайткач, акча җыюны оештырып, генератор сатып алдым. Аннары, башка гуманитар ярдәм белән бергә, генераторны Луганск якларына илттем, шуннан бу эшкә ныклап кереп киттем.

Икенче баруымда «минем медицина взводына» яралыларны күчереп йөртү өчен автомобиль кирәклеген ишеттем. Акча җыйдык, машинаны сатып алдык, батальонга илттек, медвзводка тапшырдык. Һәм шулай итеп аларга ярдәм итә башладык.

Бу сәяхәтләргә мин һәрвакыт үзем белән кемнедер алырга тырыша идем. Бер яктан куркыныч та, авыр да, юлы ерак... Ләкин бөтен кешене дә алмыйм. Бу дүрт ай эчендә нәрсәләр генә күрмәдем! Төрле кеше бар.

Әйтик, күптән түгел волонтёрлар бөтен газета-журналларда: «Без солдатларга шиннар илтеп кайттык!» – дип лаф ордылар. Ә миңа батальоннан бөтенләй иске, яраксыз резина китерүләре турында яздылар. Күз алдына китерәсезме? Иске шин илтү өчен тулы бер колонна оештырганнар. Юл чыгымнарына 120 мең сум акча киткән. Әрәм акчалар! Бу акчаны гуманитар ярдәмгә тотсалар, күпме файда булыр иде. Бу шиннар минем батальонга эләккән, шуңа күрә бу турыда дөресен беләм. «Мин мондый гуманитар ярдәмне илтергә оялыр идем!» – диделәр миңа егетләр. Ә менә хәзер күз алдына китерегез: көпчәгенә шундый резина кидертелгән «уазик» тайгак, пычрак юлдан, җитмәсә атышлар барганда, яралыларны алып чыгарга дип, алгы сызыкка барырга тиеш.

Мин хәрбиләр гаиләсендә үстем, мине фронтовик бабам тәрбияләде, мондый әйберләрне һичничек кабул итә алмыйм.

Фото: Мария Ефремова

НИЯЗ ГАЗИЗУЛЛИН: «КОММУНИКАЦИЯЛӘРСЕЗ ЮЛ БУЛА АЛМЫЙ»

«Полистрой» ҖЧҖ җитәкчесе, «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы җиңүчесе кыенлыкларны җиңәргә яратуы һәм кечкенә команданың зур уңыш казана алу серләре турында сөйли.

– Бүген Татарстан компанияләре бөтен Россия буйлап гамәлгә кертелә торган зур проектларда катнаша. «Полистрой» җәмгыятенең дә шундый тәҗрибәсе бармы?

– Яңа Мәскәү һәм Мәскәү янындагы Үзәк боҗра автомобиль юлы (ЦКАД), М-25 Новороссийск-Керчь юлы төзелеше һәм реконструкциясе, хәзер төзелә торган югары тизлекле М-12 Мәскәү–Түбән Новгород–Казан автомагистрале – без шундый һәм башка федераль объектларда эшлибез.

– Соңгы ике елда компаниянең кереме берничә тапкырга арткан. Мондый нәтиҗәгә ничек ирешә алдыгыз?

– Күреп торабыз бит, хәзер шәһәрләр бик интенсив үсә, яңа торак микрорайон һәм комплекслар, социаль объектлар төзелә, сәнәгать предприятиеләре яңартыла, юллар салына. Профессионаллар – ә «Полистрой»да нәкъ менә шундый осталар эшли – хезмәтенә ихтыяҗ бүген бик югары. Без инде берничә ел федераль проектларда катнашабыз, һәм безнең портфолио хәзер үзебезгә файда китерә.

– Әлеге проектларда «Полистрой»ның роле нинди?

– Безнең төп юнәлешебез – су һәм газ белән тәэмин итү өчен инженерлык коммуникацияләрен төзү, аларны үзгәртеп кору һәм ремонтлау. Бу эш, мәсәлән, юлның үзен төзү, ремонтлау яки реконструкцияләү кебек бик күзгә бәрелеп тә тормыйдыр, әмма юл һәм коммуникацияләр – нефть һәм газүткәргечләр, суүткәргечләр, электр тапшыру линияләре, элемтә кабельләре – бербөтенне тәшкил итә. Коммуникацияләрсез юл була алмый.

– Горурланырлык тәҗрибәгез бармы?

– Без һәр объектны горурланырлык итеп эшләргә тырышабыз. Үзәк боҗра автомобиль юлы (ЦКАД) – безнең тәүге зур проектыбыз, ул аеруча әһәмияткә ия. Ул чакта «Полистрой» әле беркем дә белмәгән компания иде. Заказ бирүчеләр безгә шикләнеп карады, графикны узып эшләргә кирәк булды, генераль подрядчы финанслауны тоткарлап интектерде. Стандарт булмаган чишелешләр табарга һәм тәвәккәл карарлар кабул итәргә туры килде, чөнки генераль подрядчыга банкротлык янады, ә безгә исә төзелеш буенча үз бурычларыбызны үтәү һәм үзебезне ышанычлы партнер итеп таныту бик мөһим иде. Без, бөтен мөлкәтне – компаниянекен дә, шәхси милекне дә – закладка салып, зур заем алдык. Бу төзелешне төгәлләү һәм объектны вакытында тапшыру

Фотолар «Полистрой» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

мөмкинлеген бирде. Тәвәккәллек үзенаклады. Бүген «Полистрой» – «Автодор», «Газстройпром», «Автобан», «РТЮ» ААҖ, «Юл төзелеше компаниясе» кебек зур компанияләрнең ышанычлы, сыналган подрядчысы.

– Абруйлы клиентлар, көйләнгән эш процессы, киң география. Сезнең компаниядә эшләр көнләшерлек икән!

– Әгәр сез тармак үзенчәлекләрен белмисез икән, шулай тоелырга мөмкин. Әмма шәп нәтиҗә күрсәтер өчен, безгә даими рәвештә байтак әчке бурычларны хәл итәргә кирәк. Мәсәлән, хәзер югары квалификацияле белгечләрне – җитештерү-техника бүлеге инженерларын, прорабларны, эретеп ябыштыручыларны, махсус техника механизаторларын табуы бик кыен. Яхшы экскаваторчы, торба салучы машинист, бульдозерчы – менә чыннан да бик сирәк белгечләр! Җитмәсә, өйдән, туганнардан меңнәрчә чакрым еракта эшләргә кирәк. Эш көне төнгә ялгана, теләсә нинди һава шартларында эшләргә кирәк, еш кына әле уңайлы торак та булмый.

– Моны ничек хәл итәсез?

– Яшьләрне җәлеп итәбез. Аларда энтузиазм, тәвәккәллек, энергия күп. Аларны укытабыз – күбесе өчен бу бик яхшы мотивация. Аттестацияләүне оештырабыз. Бер сүз белән әйткәндә, үзебезнең кадрларны үстерәбез. Билгеле инде, хезмәткәрләребезгә матди ярдәм күрсәтәбез, бүләклибез, торак һәм башка көнкүреш мәсьәләләрен хәл итәргә булышабыз. Компаниянең корпоратив рухын ныгытабыз: ел саен Төзүчеләр көнен билгеләп үтәбез, даими рәвештә корпоратив тренинглар уздырабыз.

– Тармакта үзгәртәсегез килгән нәрсә бармы?

– Проект-смета документациясе эшләрнең фактагы күләменә һәм бәясенә туры килмәве аркасында бик күп проблема пәйда була. Минем һәм, мөгаен, барлык подрядчы оешмаларның хыялыдыр бу – ул һәрвакыт бик төгәл төзелсен иде. Һәм, әлбәттә инде, башкарылган эш өчен акча тулысынча түләнергә тиеш. Вакытында түләмәү бик сирәк күзәтелә, әмма мондый очраклар безнеке кебек кечкенә компанияләрне аяктан егарга да мөмкин.

– «Полистрой» сайтында: «Кыенлыклар туганда, без үз мөмкинлекләребезнең бөтен куәтен эшкә җигәргә тырышабыз, һәм, тәҗрибә күрсәткәнчә, безнең өчен үтәп булмый торган бурычлар юк», – дип язылган. Югарыда әйтелгәннәрне искә алып, бу нинди чаралар аша тормышка ашырыла?

– Без – бердәм һәм нәтиҗәле команда. Бу – иң мөһим күрсәткечләрнең берсе. Хезмәткәрләремнең күбесен мин яшь чакларыннан ук беләм, бергә «Татнефтепроводстрой» ААҖдә эшләгән идек. Бергә бик күп колачлы проектларны гамәлгә ашырдык, утны-суны бергә кичтек, дип әйтергә була. Бүген алар – зур эш тәҗрибәсенә ия югары квалификацияле белгечләр, мин һәркайсына таяна алам. Икенчесе – куәтле техник ресурслар. Бүген безнең автопаркта 42 берәмлек эре төзелеш техникасы исәпләнә. Без моның көндәшлеккә сәләтле булуның мөһим ресурсы икәнен яхшы аңлыйбыз һәм ел саен керемнең шактый өлешен техниканы яңартуга тотабыз. Өченчесе – заказ бирүчеләрнең хөрмәте һәм хуплавы. Үзара ышанычлы хезмәттәшлек булганда гына көтелмәгән вакыйгаларны тиз арада хәл итәргә мөмкин, ә мөһим объектларда эшләгәндә исә мондый хәлләр шактый еш очрый.

– Сезне эшегездә нәрсә илһамландыра?

– Мин үземнең эшемне һәм ул тудырган мөмкинлекләрне яратам. Бала чагымнан ук күп нәрсәгә ирешү, җәмгыятьтә танылу һәм ихтирам казану турында хыялландым. Миңа катлаулы бурычларны хәл иткәндә нәтиҗәле юллар эзләү һәм табу бик ошый. Ә кыенлыкларны җиңеп алга барырга гаиләм һәм компания коллективы каршындагы җаваплылык хисе ярдәм итә. Алар миңа ышана, киңәшләре белән булыша. Бу бик зур ярдәм, һәм мин аның булуына горурланам. Ул – безнең киләчәктәге казанышларыбызның нигезе. «Киләчәк бүгенгедән башлана», – минем эш принцибым һәм «Полистрой» ҖЧҖ командасының девизы менә шундый. Т

ПАВЕЛ КОЧНЕВ: «ТЫШКЫ ПАРТНЁРЛАРСЫЗ ЭШЛӘП БУЛМЫЙ!»

Кечкенә компаниягә зур заказчыларны ничек җәлеп итәргә, яшьләрне сакларга кирәкме һәм VR-күзлек белән импортны алыштыру үзара ничек бәйләнгән? Бу хакта «Татарстан» журналына «Союзхимпромпроект» проект институты директоры һәм «Ел җитәкчесе 2022» Павел Кочнев сөйләде.

– Павел Владимирович, бүгенге көндә институт эре сәнәгать предприятиеләре өчен проектлар эшләүгә йөз тота. Шул ук вакытта IT-тармак экспертлары мондый компанияләр тарафыннан үзләренең үсеш һәм проектлау бүлекләрен булдыру тенденциясенең көчәюен билгеләп үтә. Эшләү авырлаштымы?

– Әлегә без сәнәгать объектларын проектлау белән бәйле заказларның артуын гына күрәбез. 70 еллык эш тәҗрибәсе билгеле бер өстенлекләр бирә. Төрле проектлардан торган база булмаган килеш, мондый юнәлешне үзләштерү, аны кыска вакыт, ягъни бер-ике ел эчендә үзебездә гамәлгә кертү бик кыен.

– Бу тәҗрибәне сез хәзер ничек кулланасыз?

– Узган елдагы зур казанышыбыз – производстволар төзү буенча «нульдән» башлап гамәлгә ашырылган ике проект. Биналарны да, производствоның үзен дә чип-чиста кырда диярлек проектлау безнең өчен өр-яңа эш, зур үсеш баскычы булды. Проектлау комплексы булды. Ике проект та бик катлаулы, икесе буенча да параллель эшләдек. Берсе – Ленинград өлкәсендә «Еврохим» өчен метанол җитештерү буенча завод, киләчәктә метанол җитештерү буенча иң зур производство булачак, икенчесе – Поляр арьягында, Ненец автономияле округында, «Русхимгаз» өчен завод төзелеше. Йөз миллиард сумлык «Русхимгаз» проекты табигый газны тирәнтен эшкәртеп метанолга әйләндерү өчен газүткәргеч һәм газ-химия комплексы, порт төзүне күздә тота. Без комплексның үзен проектладык, ә төзүчеләр өчен бистә һәм бу территориядәге барлык коммуникацияләрне башка проектлаучылар эшләде. Ике проект та «Баш дәүләт экспертизасы»ның уңай бәяләмәсен алды.

– Санкцияләрнең йогынтысы сизелдеме?

– Чит илләр тарафыннан лицензия бирү туктатылган программа тәэминатына килгәндә, без моңа әзерләндек, даими файдалануга дип берничә дистә эш урыны сатып алдык. Моннан тыш, без хәзер Россия инженерлык софтын куллана башладык. Ул камил түгел, ләкин аны бүгенге шартларда яхшы итеп эшләп бетерү, камилләштерү ягыннан бөтен мөмкинлекләр дә бар. Технологияләрне эшләү белән кызыклы вазгыять туды. Элек без чит ил лицензиарлары заказы буенча аларны Россия объектларына яраклаштырдык. Бүгенге шартлар безне җитештерү технологияләрен үстерүгә этәрә. Без башлангыч мәгълүматны заказчыдан алдык һәм КМТТУ-КХТИ белән бергә гамәлгә кертүгә әзер ике база проекты булдырдык инде. Бу безгә дә, бөтен проект тармагына да хас түгел, аның каравы тышкы вакыйгаларга бәйсез булу юнәлешендә эшли.

– «Союзхимпромпроект» коллективының яртысы – яшьләр. Аларны ничек җәлеп итәргә?

– Югары уку йортыннан килгән генә белгеч бездә 25–30 мең сум хезмәт хакы ала. Ләкин аның акчасы әкренләп үсә башлый. Тәҗрибәле белгеч бездә 95 мең сумга якын акча ала. Бездә күпме эшлисең, шуның кадәр аласың. Элек без акчаны белгечләр арасында дөрес, тигез итеп бүләргә тырыша идек. Әмма соңгы елда эш күләме гаять зур булды, шуңа күрә хәзер һәркем хезмәт хакын үзе башкарган эшкә пропорциональ рәвештә ала. Сүз уңаеннан, хезмәт өчен түләү системасын даими рәвештә җитештерү чынбарлыгына карап җайлыйбыз. Һәм индивидуаль график принцибын саклыйбыз: кемдер 8:00 дән 17:00 гә кадәр эшли, кемдер – 9:00 дән 18:00 гә кадәр, кемгә ничек уңайлы.

– Ни өчен предприятие хезмәтне оештыруга шулкадәр акча сала?

– Без барлык хезмәткәрләргә дә уңайлы булуын телибез. Яшь составы төрлерәк булган саен, предприятиенең эш тәҗрибәсе тулырак була бара. Бүген без эшләгән нәрсәләр өчен төрле проектларда эшләп карау тәҗрибәсе бик мөһим. Бу төрлелек эшкә килгәннән соң өч ел узгач кына башлана. Проектны булырга беркайда да өйрәтмиләр бит. Шуңа күрә башта һөнәрнең асылына төшенергә туры килә. Мисалга үземне китерә алам: мин дә монда яшь белгеч буларак кил-

Фотолар «Союзхимпромпроект» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

дем һәм элеге юлны үттем. Башта бертөрлерәк иде, аннары кызыграк була башлады, алга таба ниндидер яңа эш эшләүгә, аны яхшы итеп башкаруга кызыксыну уянды. Хаталар да булмый калмады. Минем белгеч булып өлгерүемдә элеге хаталарны төзәтергә ярдәм иткән коллегаларымның тәҗрибәсе төп рольне уйнады, алар өйрәттеләр, контрольдә тоттылар. Бүген бездә яшьләр дә, 30 һәм 50 яшьлек белгечләр дә эшли. Бу безнең күп кырлылыгыбызның нигезе.

– Авыр хәлләрдә нишлисез?

– Без алдан ук хәстәрен күрергә тырышабыз. Мәсәлән, 2021 елда, санкцияләргә кадәр үк, белгечләребез мәгълүмати технологик модельләштерүнең чит ил софты белән эшләргә өйрәнгән иде, бу бик шәп булды. Шуның нәтиҗәсендә без хәзер яңа технологияләр булдыру белән шөгыльләнә алабыз – документларны өйрәнү стадиясеннән цифрлы прототип булдыруга һәм өр-яңа продукция җитештерү процессын модельләштерүгә кадәр, моны «Лукойл» өчен эшләп тә карадык.

– Базарда көндәшлек сизәсезме, әллә мондый тәҗрибә булганда аңардан курыкмыйсызмы?

– Сизәбез. Ләкин көндәшлек бик мөһим. Бу эшне ала алырлык башка оешма барлыгын белгәндә, сез клиентка яхшырак шартлар тәкъдим итәсез. Бәхеткә, хәзер клиентлар бәядән бигрәк, сыйфат, компетенция һәм өстәмә хезмәтләр күрсәтүгә игътибар итә.

«СОЮЗХИМПРОМПРОЕКТ» ПРОЕКТ ИНСТИТУТЫ

1953 елда махсус химия производстволары өчен проектлар эшләүгә нигез салына.

1990 нчы елларда төп юнәлеш нефть химиясе була.

Бүген институтның заказчылары һәм партнерлары арасында – «Сибур» («Түбән Кама Нефтехим»), «Казан Оргсинтез», «Лукойл», «Татнефть» һәм башка сәнәгать лидерлары.

Павел Кочнев, «Союзхимпромпроект» институты директоры, «Ел җитәкчесе 2022» республика иҗтимагый конкурсы лауреаты.

Әгәр боларның барысын да тәкъдим итә алабыз икән, бәяләребез иң түбәне булмаса да, алар безне сайлый. Безнең чыннан да баш оешмадан (ул бездә юк та) алынган проектлардан түгел, бәлки конкурсларда җиңү яулаган үз проектларыбыздан торган портфолиобыз бар.

– Ә чит ил проект оешмалары белән көндәшлек итеп буламы? Яисә хезмәттәшлек итәсезме?

– Уникаль үсеш тәҗрибәсенә һәм сыгылмалылыкка ия булуыбыз нәтиҗәсендә чит ил заказчылары чыннан да безнең белән кызыксына. Мин киңкырлы хезмәттәшлек яклы. Канада, Австралия, Латин Америкасы – бик кызыклы потенциаль партнерлар. Бездә Кытай белән Находкада, Иран белән потенциаль проектларыбыз бар. Безне илебездән аерып карау мөмкин түгел. Дөнья күпполярлы булырга тиеш, дип саныйм. Тышкы партнерларсыз беркем дә эшли алмый.

– Сез технологик модельләштерүне бик вакытлы өйрәнүегезне әйтеп үттегез. Гомумән, технологияләр үсешен күзәтәсезме? Сезнеңчә, ниндидер перспективалы юнәлеш бармы?

– VR-күзлек – шәп тема. Мәйдан цифрлаштырыла, аның виртуаль моделе ясала һәм, күзлек кигәч, сез үзегезне андагыдай хис итәсез. Бу, мәсәлән, автор күзәтчелеге буенча хезмәт чыгымнарын киметергә бик ярдәм итәр иде. Менә без Амур газ химиясе комплексы буенча проект эшлибез. Анда барып җитәр өчен генә дә ике тәүлек вакыт кирәк. Әгәр VR-модель булса, подрядчы аңа сканерланган сурәтне йөкләр, ә без монда, Казанда, аны карар идек. Әмма элегә, Россия – иң тиз һәм куәтле интернетлы илләрнең берсе булса да, мондый проектлар өчен ул җитәрлек түгел. Ә бит VR мөмкинлеге күп белгечләр эшен тизләтәчәк. Бу кадрлар кытлыгы проблемасын өлешчә чишәр һәм илнең технологик суверенитетын арттырыр иде.

СИРӘК БЕЛГЕЧ, АКЫЛЛЫ ОСТАЗ

«Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры Рафинат Яруллин – Татарстанда нефть химиясе тармагының иң күренекле вәкилләреннән. Республиканың нефть химиясе язмышы белән чын-чынлап кызыксынып, предприятиеләр дә, кешеләр дә уңышка ирешсен, чәчәк атсын өчен, ул бик күп эш башкара.

Павел Кочнев,
«Союзхимпромпроект» проект институты директоры

Берничә ел элек Рафинат Самат улы ул вакытта әле Татарстан белән бәйле булмаган «СИБУР» вәкилләренә, малеинлы ангидрид җитештерү заводын төзү идеясен тәкъдим итә. Бу матдә косметикадан алып ягулыкка кадәр башка бик күп төрле продуктлар җитештергәндә кулланыла. Һәм әле соңгы елларга кадәр нигездә чит илләрдә сатып алына. «СИБУР», киңәшкә колак салып, малеинлы ангидрид җитештерүне бер ел элек Тубылда җайга салып җибәрде. Бүгенге санкцияләр шартларында бу адымның никадәр вакытлы булганлыгы турында әйтеп тору да артык.

Минем һәм институтның Рафинат Яруллин кебек тиңсез белгеч, үз эшенә ихлас бирелгән чын профессионал белән аралашу, нефть химиясе тармагында процесслар турында белем-тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге булуына бик куанам. Ул сирәк очрый торган сәләт – гомуми картинаны анализлау сәләтенә ия, беренче карашка вак кына тоелган, ләкин соңрак зур роль уйнаячак детальләрне күрә ала. Җитештерү процессының бөтен чылбырын күзаллап, аны тагын да нәтиҗәлерәк итәр өчен, кайсы этапта ни өстәргә кирәклеген төгәл белә.

Рафинат Самат улының тормышка ашырылган киңәш-тәкъдимнәре нефть химиясе сәнәгатебез үсеш юлында очраткан мәсьәләләрне алдан ук хәл итеп куюга әйләнгәненә күп тапкырлар шаһит булдым. Ул «Союзхимпромпроект» институтының бүгенге казанышларына зур өлеш кертте. Рафинат әфәнде ярдәме белән без бүген үзебез өчен дә, заказчылар өчен дә, илебезнең технологик суверенитеты өчен дә мөһим компетенцияләрне булдырдык. Берничә ел элек без аның белән технологик модельләштерүне үзләштерүнең киләчәге турында сөйләшкән идек, асылда безнең белгечләр өчен җитештерү мәйданчыгын гына түгел, ә җитештерү технологиясен проектлаштыруда да яңа күнекмәләр турында сүз барды. Әнә шундый укуларны 2021 елда оештырдык. Нәтиҗә – яңа компетенцияләр һәм яңа проектлар: «Лукойл» өчен өстәмәләр җитештерүне күздә тоткан база проекты, «СИБУР» өчен катализаторлар һәм антипиреннар җитештерүне проектлау өчен беренчел мәгълүмат.

Рафинат Яруллин кебек тармак үсешен 10, 20 елга алдан фаразлый белүче белгечләр төрле-төрле өлкәләрдә күбрәк эшләсә, бәлки, илебезнең үсеш темплары бөтенләй башка булыр иде.

Хөрмәтле Рафинат Саматович!

Акыллы, зирәк остаз булганыгыз, җылы, дустанә мөнәсәбәтегез өчен Сезгә ихластан рәхмәт. Сезнең бүгенге күзлектән караганда искиткеч сыйфатыгыз – киңәш, ярдәм сорап, сөйләшергә теләп мөрәҗәгать иткән һәркемгә игелекле мөгамәләгез. Бәйрәм уңаеннан котлаулар белән килүчеләр үзләре дә бүләк белән китә. Шундый юмарт бүтән кешене белмим.

«Союзхимпромпроект» институтының бөтен коллективы исеменнән Сезне матур гомер бәйрәмегез белән котлыйм!

Сезгә бәхет, сәламәтлек, барлык планнарыгызны, теләк-омтылышларыгызны тормышка ашыру өчен җитәрлек энергия һәм, әлбәттә, озын гомер телим! Юбилеегыз белән!

Фотолар «Союзхимпромпроект» компаниясеннән һәм «Татарстан» журналы архивыннан алынды

ЭШ СӨЙГӘННЕ ИЛ СӨЯ

Татарстанда нефть-химия комплексы үсеше стратегиясен билгеләү – «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенең миссиясе шуннан гыйбарәт. Ә Рафинат Яруллин – аның алыштыргысыз генераль директоры, тармак үсешен күп еллар алдан фаразларга сәләтле профессионал.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго»
АҖ генераль
директоры

Фото «Татэнерго» АҖ

Бервакыт журналистлар белән әңгәмәсе вакытында Рафинат Самат улы үзенең өч төп тормыш принцибын атаган иде. Беренчесе – зур түрәме яки гади башкаручымы ул – һәркемне тигез күрү: беркемне дә түбәнсетергә, беркемгә дә куштанланырга ярамый. Икенчесе – яшеңә һәм йөкләнгән вазыйфаңа карамастан, даими уку-өйрәнү. Һәм өченчесе – рухи яктан камилләшү, башкаларга зыян китерерлек гамәлләр кылмау. Аның белән аралашу дәверендә мин әллә ничә тапкыр инандым инде: Рафинат Самат улы үз принципларына һәрчак тугры. Алай гына да түгел, әлеге зирәк һәм конструктив җитәкче кул астындагылар, коллегалары, хезмәттәшләре дә аның төп принципларына хилафлык китермәскә тырыша. Әхлакый яктан камилләшә. Һәм, табигый ки, даими белем эсти, һөнәри һәм иҗади яктан үсә.

Башкача була да алмый. Рафинат Самат улы һәм аның командасы җилкәсенә салынган җаваплылык даирәсе бик мөһим, республика икътисадының нәтиҗәле үсеше, аның көндәшлеккә сәләтле булуы күп очракта шуңа бәйле. «Инновацияләрне туплау» дип гади генә аңлата «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенең төп вазыйфасын җитәкче үзе һәм һәрвакыт шуңа басым ясый: Рөстәм Миңнеханов әле премьер чагында ук шундый бурыч куйган – ил буйлап йөрергә, иң яңа технологияләрне эзләп табарга һәм шулардан файдаланырга.

Рафинат Самат улы шәхесенең колачы, аның энциклопедик белеме, алдан күрә белү таланты һәм тагын бер бик сирәк очрый торган – хәвефләрне җентекләп фаразлау сәләте әнә шул куәтле катализатор булып тора да инде, бу республикада фән һәм техниканың иң яңа казанышларын, инновацион технологияләрне берсе артыннан берсен гел кертеп тору мөмкинлеген бирә. «Татнефтехиминвест-холдинг» ярдәмендә хәл ителгән яки хәзер гамәлгә ашырыла торган аеруча мөһим бурычлар арасында – нефтьне тирәнтен эшкәртү, минераль һәм комплекслы ашламалар җитештерү технологияләрен эзләү һәм файдалану. Импортны алыштыруда яңа юнәлешләр ачылу күп кенә предприятиеләр өчен чын үсеш этәргеченә әйләнгән. Мәсәлән, шулардан берсе – Татарстаныбызда формалаша башлаган полимер композицион материаллар тармагы.

Холдингның Рафинат Самат улы һәм аның командасы әзерләгән һәр утырышы – һөнәрмәндләр өчен чын имтихан ул. Компетентлыкка, яңаны кабул итүгә, киләчәкне күрә белүгә. Әлеге утырышларда беренче тапкыр яңгыраган фикерләрнең күбесе башта фантастика булып тоела, әмма бераз гына вакыт үтүгә, шуңа инанасың: әллә никадәр инновацион тәкъдим арасыннан аеруча өметлеләре, кирәклеләре, тормышчаннары сайлап алынган. Мисал эзләп ерак барасы түгел: күптән түгел холдинг утырышында полимер композит җиңсәләр ярдәмендә торбаларны траншея казымыйча алыштыру технологиясе тәкъдим ителде, бу – коммуналь хуҗалыкта революция ясарлык яңалык. Әйе, җылылык трассаларын реконструкцияләү өчен бу технология әлегә яраксыз, тик ул һичшиксез камилләштереләчәк бит! Әлбәттә, без аны игътибарга алдык.

Бүген без моңарчы күрелмәгән санкцияләр басымы чорында яшибез, дус булмаган чит илләр безгә инновацияле технологияләрне ничек тә бирмәскә тырыша. Авырмы бу? Һичшиксез авыр! Әмма бу очракта Рафинат Самат улының тагын бер принцибына тугры булу җитә: «Иң мөһиме санкцияләр түгел, ә безнең үзебезнең үсеш зарурлыгы. Шуңа күрә без өстенлекле юнәлешләрне үзебездә тагын да активрак үстерә алабыз», – ди ул.

Хөрмәтле Рафинат Саматович!

Һич арттырмыйча әйтеп була, Сез үзләрендәге искиткеч һөнәрмәндлек һәм таләпчәнлекне вазыйфасы-статусына карамыйча барлык кешегә ихлас мөнәсәбәт белән берләштергән җитәкчеләрнең алтын категориясенә керәсез. Сез үзегезнең бөтен белемегезне һәм талантыгызны туган Татарстаныбызга багышлыйсыз, инновацион асыл республика икътисадының төп двигателе булсын өчен мөмкин булганның һәм булмаганның барысын да эшлисез.

«Татэнерго» коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Сезнең иң кыю идеяләрегезнең дә уңышлы тормышка ашуын, тәҗрибә һәм белемегезнең һәрвакыт республика файдасына эшләвен, нык сәламәтлек һәм зур казанышларга бай бәхетле киләчәк телим!

Җитәкчеләр төрле була: кемдер һәрвакыт җитди костюмнан һәм боздай салкын карашлы, кемдер кабаланучан һәм һәрчак һавалы, кемдер үз дөньясына чумган да һичкемне күрми. Эчке эшләр министрлыгы структурасында 15 еллык карьерасын уңышлы тәмамлап, Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводы директоры урынбасары вазыйфасына килгән подполковник Александр Тришкин 2016 елда эшкә алынганда да һәм соңрак, 2018 елда предприятиене җитәкләгәндә дә, бөтенләй башка кыяфәттә була.

ДИРЕКТОР ҺӘМ АНЫҢ КОМАНДАСЫ

Фотолар Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводының матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

Югарыда искә алынган типажлардан бер, әмма хәлиткеч аерма күзгә ташлана – Александр Сергеевич үз кул астында эшләүчеләрне хөрмәт итә, завод хезмәткәрләре белән уртак тел табып, аларны тимер-бетон белән бәйле уртак эшкә үзе кебек үк намуслы мөнәсәбәттә булырга рухландыра.

Энергиясе ташып торган элекке офицер килгәнче, предприятиедә эшләр эленке-салынкы барган дип әйтеп булмый. Әүвәлге җитәкче – бай тәҗрибәле Александр Васильевич Матюшин дәвамчысына зур эшләр башкарырга сәләтле коллективка ия, керсез абруйлы, җитештерү эше җайга салынган заводны калдыра. Яңа җитәкченең төп бурычы үзенә ышанып тапшырылган алмазны бриллиантка җиткерерлек итеп шомартудан гыйбарәт була – һәм бу эш уңышлы чыга да!

– Мин үземә кадәр эшләнгәннәрне дәвам итәм. Миңа кадәргеләр тарафыннан өлге итеп алынган кыйммәтләрне без саклыйбыз, үстерәбез һәм үзебезнекен дә өстәп алга барабыз, – ди Александр Сергеевич. Завод үсә һәм алдынгылар рәтенә чыга – «100 иң яхшы товар» конкурсының беренче дәрәҗәдәге дипломы яулана, берничә ел рәттән предприятие хезмәт иминлегенә бәйле конкурсларда җиңә, сәнәгать өлкәсендә иң яхшы предприятие дип тә таныла. Ләкин бу гына җитми – производствоны алга таба үстерү таләп ителә.

Комбинатта шундый традиция яшәп килә: һәр ел башында директор үз командасын җыя да бу тармакка бәйле төрле күргәзмәләрдә һәм форумнарда телгә алынган идеяләр белән уртаклаша һәм җыелыштагыларга тупланган мәгълүматның завод өчен никадәр файдалы булуын дискуссия режимында билгеләргә тәкъдим итә. Фикер алышу нәтиҗәләре нигезендә игътибарга лаек яңа тәҗрибәне өйрәнү өчен, белгечләр Россия, якын һәм ерак чит илләргә командировкага юл тота. Грузия, Калининград, Италия, Әрмәнстан, Санкт-Петербургка юнәлә алар, истәлекле урыннар буйлап экскурсияләрне эшлекле очрашулар белән бергә алып баралар. Бу сәфәрләр предприятие кассасыннан түләнсә дә, артыгы белән кире кайта – яңа белемнәр һәрвакыт яңа офыкларга юл ача. Әлбәттә, хезмәткәрләрне инициативалылыкка һәм үсешкә этәрү юнәлешендә бик яхшы кызыксындыру чарасы ролен дә үти.

Нәтиҗә күзгә күренеп тора – күбесенчә әнә шул рәвешле алынган мәгълүмат ярдәмендә предприятиедә автоматлаштыруны арттыруга һәм җи-

тештерү процессларының куркынычсызлыгын яхшыртуга ирешәләр. Элек ике йөз кеше таләп ителгән урында хәзер йөз эшче дә эшне бик җиңел башкара ала. Башка уңышлар да бар – 2022 елда завод «Татнефть» карамагындагы нефть сервисы оешмалары өчен төп тәэминатчы оешма булып тора, ә кубометрлар белән исәпләгәндә, тимер-бетон бөтен завод тарихындагы күләмнәрдән күбрәк җитештерелгән. Эшләр тагын да яхшырак барыр, дип уйларга тулы нигез бар, һәм бу завод эшчеләренә дә, башкаларга да кагыла.

– Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводы – ачык акционерлык җәмгыяте, анда дәүләтнең өлеше юк. Без «шәхсиләр» саналабыз, үз эшчеләребез өчен эшләгән бар нәрсә предприятие акчалары хисабыннан түләнә, чөнки барыбыз да бер көймәдә. Монда 30 елдан артык эшләүче ветераннар бар, алар ярдәме белән буыннар дәвамчанлыгы тәэмин ителә. Без – фикердәшләр, уртак эш башкарабыз, һәм мин бөтен нәрсәнең дә кешеләр өчен иң яхшы булуын телим, – ди Александр Тришкин. Бу сүз җитештерү мәсьәләләренә дә, башкаларга да кагыла, хәтта заводта оештырылган футбол командасына да. 2017 елдан 2019 елга кадәр ул башка предприятиеләрдәге көндәшләрен тар-мар итеп килә, гәрчә аларга шактый нык командалар каршы торса да! «Заводта барысы да ничек шулай уң бара?» дигән сорауга директорның җавабы бер – «Аллаһ безне ярдәменнән ташламый». Бу сүздә шаярту бармы соң? Мөгаен, бик аздыр, чөнки предприятие тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм үз хезмәткәрләре белән генә чикләнми. Инде шактый озак еллар коллектив мөмкинлекләре чикләнгән балаларга даими булышлык күрсәтә.

Изге эш менә болай башлана. Авыру сабыйларны аэроторбада «очарга» алып килгән булалар. Александр Сергеевич, үзе дә ике малай атасы, моны күреп хәйран кала. Һава агымында «йөзеп йөрү» балаларга авырту китермиме соң, дигән соравына: «Юк, алар менә шушында гына авыртуны сизми дә инде», – дип җавап бирәләр. Завод хезмәткәрләре компаниясе (ул көнне алар директор җитәкчелегендә 23 февраль бәйрәмен билгеләп үтәргә килгән була) шунда ук бу балаларга ярдәм итү юлын табарга карар кыла, соңрак предприятиенең калган хезмәткәрләре дә аларның теләген күтәреп ала. Шул көннән башлап, кечкенә балаларга, яшьләренә карап, татлы күчтәнәчләр тапшырыла, беренче сыйныф укучылары өчен кирәк-яраклар туплана, сабыйлар өчен «Игелек чыршысы» оештырыла, Кыш Бабайга язылган хатларга җавап итеп, күптән көтелгән уенчыклар килә. Завод цехлары хәйриячеләре үз ярдәмнәрен «шефлык» дип санамаса да, мохтаҗ гаиләләргә дарулар һәм хастаханә сертификатлары даими рәвештә килеп тора. Тимер-бетон – бик нык нәрсә. Александр Тришкин командасы гына аннан ныклырактыр. Җитәкче үзе дә командасын республикада иң яхшысы дип саный. Әнә шул команда белән ул теләсә кайсы үрләрне яуларга һәм теләсә нинди рекордлар куярга ниятли. Ә Аллаһ, әлбәттә, ярдәм итми калмаячак.



www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татар авыллары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+

акыллы
гамәлләр
**игелекле
эшләр**
мәңгелек
кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Бизнес белән хәйриячелек **ничек** яраша

Замандашларга үткәннәрдән **ничек** сәлам бирергә

Авырлыкларны **ничек** җиңәргә

Селте суында керне **ничек** юарга

Алтайда **нәрсәләр** карарга

БУЛЫШМЫЙЧА ҺИЧ ЯРАМЫЙ...

Фото: Алсу Шакирова

Алсу Троицкая

Бизнес һәм хәйриячелек: «Туган авылым» милли комплексындагы гаҗәеп җылы мохиттә редакциянең түгәрәк өстәле узды – биредә «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы вәкилләре җыелды.

Бизнеста нәкъ менә хатын-кыз булуыгызга бәйле кыенлыклар килеп чыккаладымы? Үсешкә нәрсә комачаулый, һәм моны ничек үзгәртергә? Бизнес һәм хәйриячелек үзара яраша аламы? Татарстанның бизнес-ханымнары әнә шул һәм тагын бик күп башка нәрсәләр турында фикер алышты.

«ХАТЫН-КЫЗЛАР» БИЗНЕСЫ

– Бизнеста бары тик хатын-кызларга гына хас өлкәләр бармы, хатын-кызлар эшкуарлыгы кебек күренеш турында сөйләшү урынлымы?

Гүзәл Галиева, «СкинМед» клиникасы директоры:

– Минемчә, бизнес, ахыр чиктә, бизнес-процесстан гыйбарәт ул. Аның гендерлыгы юк. Хәер, әлбәттә, бизнесны хатын-кызларча алып бару хакында сөйләп була торгандыр. Хатын-кызлар күпчелек очракта эмпатия хисеннән чыгып эш итә – үзләренә ошаган кеше белән генә эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырга, үз бизнесын шулар белән көйләргә тырыша.

Тик шулай да еш кына без бизнесның аеруча файда китерерлек, эксклюзив продукт җитештерерлек юнәлешен сайлаган булып чыгабыз. Менә ул ирләрнекенә һәм хатын-кызларныкына бүленергә мөмкин. Косметология өлкәсендә эшләгәнгә күрә, ышандырып әйтә алам: бу тармактагы бизнес белән нигездә хатын-кызлар шөгыльләнә, ирләр бик аз. Пациентлар белән дә шул ук хәл. Әмма инде ир-ат пациент безгә килгән икән, аңардан үзгә бер энергетика бөркелә.

Оксана Савинова, бизәү һәм яшелләндерү студиясе җитәкчесе:

– Мин бик матур бизнес – чәчәкләр белән шөгыльләнәм. Күп еллар буе бу минем хобби гына иде, ә аннары ничектер гаиләнең өстәмә табыш чыганагына әйләнде. Һәм бу бик шәп тә.

Нинди тармакта хатын-кызлар ирләрдән яхшырак булдыра, дип әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, флористикада. Стильне тою, креативлык, гаҗәпләндерә белү сәләте, минемчә, ирләрдә көчлерәк чагыла – ихтимал, бу безнең бер үк нәрсәгә төрлечә каравыбыздан шулай килеп чыгадыр. Шул исәптән чәчәкләргә дә.

Лилия Муллахмәтова, «Аль-Варис» клиникасы җитәкчесе, косметолог:

– Шулай да хатын-кызлар бизнесы ирләрнекеннән аерыла. Әйе, ул чыннан да күбрәк эмпатиягә һәм хис-тойгыларга нигезләнә. Минемчә, бүгенге көн – социаль кызыксынулар һәм команда туплау вакыты ул. Хәтта менә бирегә чәй эчеп, нәрсәдер турында гәпләшеп утырганда да, без берләшәбез. Бер баш яхшы, ә инде ун баш берьюлы уйлаганда, без теләсә нинди бурычны хәл итәргә сәләтле. Чөнки бөтен нәрсә белән безнең энергиябез идарә итә. Хатын-кыз – иң әүвәл энергия ул.

Әнисә Сәламова, финанс консультанты:

– Мин үз вакытында базарда яңа гына пәйда була башлаган пластик тәрәзәләр белән шөгыльләндем. Бу турыда башта бернәрсә дә белми идем. Бөтенесен иң вак техник деталенә кадәр өйрәндем. Бервакыт минем яныма Казандагы бер зур төзелеш компаниясе директоры килде, исәбе – коттеджына пластик тәрәзәләр куйдыру. Мин аңа тәрәзәләрне күрсәтәм, менә мондыйлары бар, башка төрлеләре бар, дим. Һәм аның мине бөтенләй аңламавын күрәм. Макет куям, тагын бер кат аңлатам, бу юлы инде бөтен техник вагы-төяге белән төшендерәм. Ярты сәгатьтән соң ул: «Ничә еллар төзелештә эшләп тә, мондый нечкәлекләрне белми идем, ә сез миңа барысын да аңлаттыгыз. Әйдәгез, заказны кабул итегез», – диде.

Мөгаен, бизнеска килгән һәр хатын-кыз аны тәртиптә һәм балансга тотуны максат итеп куядыр. Ирешелгәннәрне саклау гына түгел, арттыру да – хатын-кызга хас бу сыйфат белем алуга да кагыла. Еш кына ир-ат көндәшләрдән бер башка югарырак булырга туры килә.

Лиана Баһавиева, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» ТТИО президенты:

– Мин төрле дәрәҗәдәге бизнеста, аның төрле тармакларында эшләүче эшкуар хатын-кызларны берләштерәм. Күп еллар буе шундый стереотип яшәп килде: янәсе, хатын-кыз гаилә, балалар, матурлык, мәгариф белән генә бәйле була ала... Чынлыкта исә бүген җитәкче вазыйфаларда да, кече һәм урта эшкуарлык белән беррәттән, эре бизнеста да Татарстан һәм Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танылган хатын-кызларыбыз шактый. Хатын-кызлар үзләрен бизнеста таныткач, ирләр, теләсә-теләмәсәләр дә, аларның казанышлары белән килешергә мәҗбүр була. Ә икенче яктан караганда, күп нәрсә кешенең үзеннән, аның үзен ничек хис итүеннән тора. Әгәр ул үз эшенең остасы икән, аңардан тынычлык һәм ышаныч сирпелә.

Резеда Сәлимҗанова, «Пища жизни» ТХИО юристы:

– Эшкуар хатын-кызларыбызга чыннан да хас булган хисләлек, эмпатия ниндидер тискәре нәрсәдер, дип әйтә алмыйм. Шәхсән минем өчен – эчтән бәреп чыккан ниндидер бер талпыну бу. Моны махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү вазгыяте ачык күрсәтте. Никадәр хатын-кыз мәчет һәм чиркәүләрдә маскировка ятьмәләре үрә, кемдер шәм ясый, кемдер оекбаш бәйли, сабын һәм башка кирәк-ярак, азык-төлек җыя. Һәм моны беркем дә кемнеңдер әмере буенча эшләми. Хатын-кызлар ихлас күңелләреннән шулай булыша.

МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛЫЙК!

– Сезнең бизнестагы абруегыз өчен социаль җаваплылык никадәр мөһим? Адреслы ярдәмнең әһәмияте нигә шулкадәр зур?

Резеда Сәлимҗанова, «Пища жизни» ТХИО юристы:

– Мин бу сорауга ике яктан – «Пища жизни» хәйриячелек оешмасының барлык юридик эшләрен алып баручы юрист буларак һәм шул оешманың бәрәңге, яшелчә чистартучы, ризык салып бирүче (без Россиянең 36 төбәге урамнарындагы мохтаҗларны бушлай ашатабыз) волонтёры буларак җавап бирә алам.

Безнең мең волонтёрыбыз былтыр Донбасста гына да 896 469 кешене ашатты. Дөрес, безне башта анда кертмәделәр. Без качакларны ашаттык һәм балаларга ашамлыклар тараттык. Ә хәзер исә анда безнең кыр кухнясы тора. Икмәк пешерүне көйләдек, үзебез пешереп, икмәк һәм кайнар ризыкны бушлай таратабыз.

Компанияләрнең социаль җаваплылыгы сыйфатындагы хәйриячелек соңгы вакытта җәмгыятебездә тормышка бөтенләй башка төрле мөнәсәбәт формалаштыра. Һәм бу күркәм күренеш. Эшкуарлар хәйриячелеккә йөз тота. Күп акчалар сарыф итәләр, һәм моның өчен ниндидер ташламалар каралганга гына да түгел. Барысы да аларның күңел халәтенә бәйле – чөнки мохтаҗларга булышу игелекле һәм дөрес гамәл ул.

Мәрхәмәтле булырга кирәк. Кайчакта без моны онытып җибәрәбез, табыш артыннан куабыз. Ә инде күңел өчен, үзеңнең эчке дөньяң өчен, һичшиксез, хәйриячелек тә кирәк. Бу сафландыра.

Чулпан Йосыпова, «Метаскан» ҖЧҖ җитәкчесе:

– Безнең металл детекторлар җитештерә торган предприятиебез, МХО зонасында эшләү өчен, волонтёрларга 300 прибор җибәрде. Моны бездән беркем дә таләп итмәде. Минем фикеремне ирем – предприятиебезнең баш конструкторы Алексей Фоминых та хуплап алды.

Бу мизгелдә синең мохтаҗларга ярдәм кулы сузуың мөһим, чөнки бик кирәк. Бары шул гына...

Бераз гына темадан читкә китәм. Гомумән, бизнес-абруйның мөһимлеге хакында да әйтәсем килә. Бизнесның бөтен шәхси бренды хәзер шул нигездә төзелә.

Эшкуарларга теге яки бу брендны рекламалау тәкъдиме белән килүчеләр дә байтак. Әйе, бу табышлы нәрсә, әмма иң мөһиме абруй булуын беркайчан да онытмаска кирәк. Үзең җәмгыятьтә, гаиләдә, танышлары-дуслары каршында тәртипле тотучы кеше белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру да ышанычлырак. Бүген абруе шикле булган кешене бер генә базарга да кертмәячәкләр. Димәк, абруй – капитал ул.

Якындагы планнардан. Без дә хәйрия фонды ачуга гариза бирдек. Аның эшчәнлеге инженерия белән шөгыльләнүче яшьләр һәм студентларга ярдәм итүгә тәгаенләнәчәк.

Оксана Савинова, бизәү һәм яшелләндерү студиясе җитәкчесе:

– Өлкән яшьтәге кешеләргә мөнәсәбәт минем өчен хәйриячелектә мөһим аспект булып тора. Без ел саен «Добрые истории» пансионатларында флористика буенча осталык дәресләре үткәрәбез. Андагы әби-бабайлар инде безне көтеп тора: «Оксана, әйдә җырлыйбыз», – диләр. Менә шулай итеп җырлый-җырлый чәчәк композицияләре төзибез. Җәй көне пансионатларга территорияләрен төзекләндерергә һәм яшелләндерергә булышабыз, аларга чәчәкләр илтәбез.

Безнең компания өчен социаль җаваплылык – өлкән яшьтәге кешеләрне шундый катлаулы булмаган процессларга җәлеп итү ул. Игелекле эшләр, беренче чиратта, безнең үзебезгә дәрт өсти бит.

Гүзәл Галиева, «СкинМед» клиникасы директоры:

– Бу табында безнең дус кызларыбыз җыелган. Без һәрвакыт бер-беребезгә ярдәм итәбез, һәм безнең уртак хәйрия проектларыбыз шактый. Моннан тыш, мин Эшкуар мөселманнар ассоциациясендә дә торам. Андагы хәйрия фондына без даими ярдәм күрсәтәбез.

Күптән түгел шуны искәрдем әле: хәйриячелеккә бүлгән акчам буенча мин үземнең никадәр яхшы эшләвемне бәялим икән. Ул арткан саен, мин дә, сабый бала кебек, чын күңелдән куанам һәм горурланам!

ПРОЕКТНЫҢ ТӨП МИССИЯСЕ – ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЕМ ҺӘМ КАЙДАН ИКӘНЛЕГЕБЕЗНЕ ИСКӘ ТӨШЕРҮ

«Туган авылым» милли комплексындагы «Тегермән» һөнәрләр үзәге проекты авторы һәм җитәкчесе Фәридә Бибарс идеянең миссиягә әверелүе һәм, кунакларны Казанга гашыйк итеп, бәхетле кешегә әйләнү серләре турында фикер йөртә.

– Костюмнар – тулысынча минем идеям. Мин милли программа һәм проектлар булдыру белән 2011 елдан бирле шөгыльләнәм. Театрлаштыру, һөнәрләр һәм милли уеннар белән беренче тәҗрибә 2012 елда инвестор ярдәмендә оештырылган иде. Әмма, кызганычка, ул озакка бармады.

Мин исә идеямне үстерүне дәвам иттем һәм 2016 елда «Тегермән» милли һөнәрләр үзәге» проектын гамәлгә ашырдым, ул костюмнарга һәм һөнәрләргә багышланган осталык дәресләреннән гыйбарәт иде.

Миңа костюм буенча төрле рәссам һәм дизайнерлар булышты: Лариса Смирнова, Мәдинә Мәхмүтова, Эльмира Митрофанова, Анастасия Юсупова, шулай ук ТР Милли музеендагы тукыма реставраторлары.

Бөтен коллекция – җете стильләштерү ул, һич тә реконструкция түгел, шул ук вакытта силуэтлар XV–XVI һәм XIX гасырларда яшәгән Казан татарлары киемнәре өслүбендә эшләнгән.

Минемчә, костюмнарым бик уңайлы: киң, матур камзол һәм япмалар, киң чалбар – болар барысы да гәүдә кимчелекләрен күрсәтми һәм хәрәкәт иркенлеген чикләми.

Бай хатыны өчен бәйрәм вариантына килгәндә исә, монда үзенең кыенлыклары бар: бизәнү әйберләренең, япмаларның авырлыгы шактый... **Әмма иманым камил: хәзерге заман чибәркәйләренең күбесе үз гардеробында** фирүзә һәм тәңкәләр белән бизәлгән **шундый милли кием булуын телидер.**

Үз тупланмамны ел саен тулыландырырга тырышам, әмма бу шактый катлаулы, чөнки һәм костюм бик кыйммәткә төшә бит. Бүген минем коллекциямдә 60 тан артык кием бар, быел аны киментдә унга арттыру хакында хыялланам.

Минем өч яраткан костюмым бар: болгар амазонкалары темасына фантазия булган амазонка киеме, XIX гасырда Казан шәһәрендә яшәгән татарлар костюмы, алъяпкычлы һәм яулыклы авыл киеме. Бу – өч төрле холык, гүзәллек һәм тарихның өч төрле юнәлеше.

Мин үземне амазонка итеп тоям. Мин ирек, хәрәкәт, бәйсезлек яратам. Әмма безнең татар калфаклары, изүләре, камзолларының матурлыгы да хозурландыра.

Әйе, без бердәнбер түгел. Россиядә моңа охшаш проектлар бар, чөнки милли костюм һәрвакытта да игътибарны җәлеп итә бит. Әмма мондый проектларның һәркайсы шәхси, үзенә генә хас үзенчәлекләргә ия.

«Бибарс» костюмнар салоны «Татаватар» проекты белән дуслыкта хезмәттәшлек итә, бу үзләрен гадәти булмаган образда мәңгеләштерергә теләүче Казан халкы һәм кунаклары өчен бик яхшы тәкъдим булып тора.

Моннан тыш, һәр кунак милли кием, бизәк, көнкүреш тарихыннан кызыклы фактлар белән таныша, һөнәрләр буенча осталык дәресләрендә катнаша ала. Бу проектны бик күпкырлы итә.

Ышанып шуны әйтә алам: костюмнар салонында булган кунаклар үзләренең киемен төрләндерү турында уйланмый калмый, милли киемгә әйләнеп кайту, аның элементларын өстәү бәрабәренә төс-кыяфәтләрендәге шәхси үзенчәлекләренә басым ясарга тели.

Нәкъ менә шул проектның төп миссиясе һәм идеясе булып тора да инде – үзебезнең кем, кайдан булуыбызны искә төшерү, хәзерге җәмгыятьтә үз халкыбызның үзенчәлекләрен ничек күрсәтә алуыбыз турында уйланырга өндәү.

Мин бәхетле кеше, үземнең яраткан эшем белән шөгыльләнә һәм башкаларны да Казанга һәм безнең мәдәниятебезгә гашыйк итә алам.

редакция кухнясы

АЛЕКСАНДР САФРОНОВТАН ЗАТЛЫ ХАНЫМНАР ӨЧЕН ХАННАРЧА АТ ИТЕ

Татьяна Вафина

Бервакыт яшь татар ханы хакимлек итүдән тәмам гарык булуын тойган. Һәм ул чын эш белән шөгыльләнергә – пешекче булырга карар кылган. Сөекле патшабикә-ханбикәсен яраткан ризыгы – яшелчә һәм кипкән җиләк-җимешләр салып пешерелгән ат ите белән шәхсән үзе сыйлап, күңелен күрергә уйлаган. Әүвәл патша даирәләрендә мондый хәл гайре табигый саналганга, ханбикә кичке ашка үзенең барлык күршеләрен – Казанның затлы ханымнарын да чакырган, ат итеннән авыз итсеннәр, ханның ничек үзгәрүен дә күрсеннәр, янәсе. Мондый хәлләр ханнар белән көн саен булып тормый бит.

Ханымнар самавыр янында бер-берсеннән хәл-әхвәл сорашкан арада, хан керәч белән тышланган бик матур мичкә ягарга утын һәм хәзинәдә булган азык-төлекне алып килергә боера.

– Димәк, безгә менә нәрсәләр кирәк булачак! – дип игълан итә ул.

КИРӘК БУЛАЧАК:

- Ат ите – 300 г;
- Татлы борыч – 1 данә;
- Кишер – 1 данә;
- Бал – 1 аш кашыгы;
- Кипкән җимешләр – 200 г;
- Ит шулпасы – 2 аш чүмече;
- Тоз, борыч – тәменчә.
- Атланмай – 100 г.

Фото: Александр Ефремов

1
– Без, ханнар, чынлыкта кухняның кайда икәнен дә белмибез,
– дип аңлатып узды Александр.

2
– 8 Март – ханнарның гадәт-гамәлләрен үзгәртү өчен бик шәп сәбәп дип уйлап торыйк.

ХАН ЭШЕ ТҮГЕЛ, ӘММА...

Кыйммәтле ташлар белән бизәлгән затлы пычагын кулына тотып, кишерне тип-тигез божраларга турый-турый, бүген хан ролен башкаручы Александр Сафронов шунда ук кисәтеп куя: «Гомумән алганда, ханнарда, мондый теләк, ягъни үз куллары белән ашарга әзерләү нияте беркайчан да тумас иде».

– Без, ханнар, чынлыкта кухняның кайда икәнен дә белмибез, – дип аңлатты ул. – Моның өчен махсус кешеләр, иң яхшы аш-су осталары булган, аларны еш кына чит илләрдән китерткәннәр. Яхшы ашчылар бик кыйммәт бәяләнгән.

– Ләкин икенче яктан карaганда, ханлык чорында Халыкара хатын-кызлар көне дигән бәйрәм булмаган бит, – ди ул, үзенең хан дәрәҗәсенә туры килмәгән «табак-савытлы гамәле»н акларга тырышып. – Кем белә, андый көн билгеләп үтелсә, бәлки хан да ханбикәсен законлы бәйрәмендә шундый тәмле сый белән сөендергән булыр иде. 8 Март – ханнарның гадәт-гамәлләрен үзгәртү өчен бик шәп сәбәп дип уйлап торыйк. Шуңа күрә без аш-су эшен дәвам итәбез!

Шул сүзләрдән соң Александр, затлы хан киемен пычратмас өчен, өстеннән «Татарстан»ның матур алъяпкычын бәйләп куйды.

ВАУ-ЭФФЕКТ

Александр итне юка телемнәргә турады да тоз-борыч салып маринадлады.

– Тәмләткечләр артык кирәкми, ат итенең тәмен басмасыннар, – дип кисәтә ул.

Ә ит маринадланган арада, «Татарстан» журналының бүгенге санында чыгучы барлык гүзәл затлардан ханбикә ясау фикеренең ничек башына (башлыгын салса, бөтенләй ханнарныкына охшамаган башына!) килүе турында сөйләп бирде.

– Моның өчен берничә сәбәп, алшарт бар иде, – дип башлады ул сүзен. – Танылган бер блогер кыз Питердан Себергә сәфәр кыла, юл уңаенда төрле шәһәрләргә кагылып, үзенең постларында алар турында сөйләп бара.

Аның Казанга килергә җыенганын һәм монда берәр кызыклы нәрсә күрсәтүне сораганын сторисында күрдем. Мин аңа шәһәрне күрсәтергә тәкъдим иттем.

Кунакчыл халык буларак, Казанда яшәүче һәркемнең калабызга килгән мосафирны шаккатырырга теләве табигый. Шуңа күрә мин, татар милли киемнәрен арендага алып, кунаклар өчен Кремльдә, Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы һәм башка истәлекле урыннар фонында фотосессия үткәрдем.

Шуннан соң блогер кыз матур пост язды, үзенең хисләре белән уртаклашты, фотосурәтләр куйды, шуның белән Казанның туристлык рейтингын җиде кат күккә күтәрде дияргә мөмкин. Милли киемнәрдә фотога төшү идеясе бөтен кешегә ошады. Блогерның язылучылары арасында бу шундый «вау-эффект» тудырды ки, күпләрнең Казанга киләселәре, карыйсылары

килә башлады, башкалабыз зур кызыксыну уятты.

ҮЗБӘКСТАН ЯРДӘМ ИТТЕ

Аннары мин Үзбәкстанга сәяхәт кылдым. Һәм Сәмәркандта, Регистан мәйданында, милли киемнәрне арендага бирә торган кием салоны эшләгәнен күрдем. Кешеләр шуларны киеп, фотога төшәләр. Ник әле Казанда да шундый берәр салон ачып җибәрмәскә дип уйлап куйдым. Бездә матур урыннар да, туристлар да күп... Килгән кунаклар, шуннан файдаланып, шәһәребезне, республикабызны танытырга ярдәм итәр иде.

АВАТАРНЫ АЛЫШТЫРЫГЫЗ!

Үзбәкстаннан кайткач, мин Фәридә Бибарс белән сөйләштем. Теге блогер кыз өчен татар милли киемнәрен Фәридә ханымнан алып торган идем. Без киләчәк проектыбыз турында сөйләштек. Ул таркау түгел, бербөтен рәвештә эшләсен, ягъни киеме бер урында, фотографы бүтән җирдә булмасын, дидек. Киемнәрнең дә, фото өчен локацияләрнең дә матур булуын, яктылык куелышының да, гомумән фотосессиянең дә профессиональ дәрәҗәдә эшләнүен теләдек...

Без Фәридә белән былтыр 18 гыйнварда очраштык. 19 гыйнварда инде «Тататватар» проектын эшләтеп җибәрдек.

Россиядә мондый проектлар юк дәрәҗәсендә икән ләбаса. Төркиядә, Кытайда шактый киң таралган, ә Россиядә, ни кызганыч... Мәскәүдә туристларны әрмән киемнәрендә фотога төшерүче егетләрне таптым, Суздальдә – рус милли киемнәрендә төшерүчеләрне – һәм шуның белән вәссәлам!

Югыйсә туристларда мондый нәрсәгә ихтыяҗ зур, социаль челтәрләрдә дә кайтавазы һәрвакыт күренеп тора.

ЧЫНАЯК КИРПЕЧЛЕ МИЧ

Ит маринадланды һәм Александр, кызган табада атланмай эретеп, итне шул табада мичкә озатты. Ат ите пешкән арада, без күз явын алырлык матур мич турында бик күп кызыклы нәрсәләр белергә өлгердек.

Чынаяк кирпечле мичләр XV гасыр ахырында ук барлыкка килгән. Мичне каплаган керәч керамик плиткага охшаган, ләкин аның арткы ягында кечкенә тартма – румпа бар, шуның ярдәмендә ул мичкә ябыштырыла.

XVII гасырда мичләр яшел төскә керә – аларны мурава, ялтыравык йөгертелгән, дип атыйлар. Чөнки чынаяк кирпечне яшел ялтыравык белән каплыйлар. Шул гасыр ахырына гына алар төрле төсле итеп ясала башлый. Иң оста чүлмәкчеләр патша сараенда хезмәт итә һәм «сарай чүлмәк осталары» дип йөртелә.

XVIII гасырда шома рәсемле чынаяк кирпечләр барлыкка килә, һәм мичләр йортларның, ашау-эчү сарайларының, кенәз тирмәләренең, гыйбадәтханәләрнең бер бизәгенә әверелә.

3
– Киемнәрнең дә, фото өчен локацияләрнең дә матур булуын, яктылык куелышының да, гомумән фотосессиянең дә профессиональ дәрәҗәдә эшләнүен теләдек...

4
Ат ите пешкән арада, без күз явын алырлык матур мич турында бик күп кызыклы нәрсәләр белергә өлгерәбез.

1 Турыйбыз

2 Тоз, борыч салабыз

3 Турыйбыз

4 Ваклыйбыз

5 Кыздырабыз

«ТАТАВАТАР» әкиятенә эләгергә теләгәннәр +7 999 169-28-25 телефоны буенча мөрәҗәгать итә ала. @tatavatar

XIX гасырда керәч кирпечләрдән чып-чын сәнгать әсәрләре ясала – бу ысул белән капланган мич һәм каминнар байларның, аксөякләрнең көнкүрешендә мәҗбүри кирәкле бер сыйфатка, шартка әйләнә...

Кыскасы, нәкъ менә шундый мичтә безнең ханнарча әзерләнә торган итебез пешәр-пешмәс хәлгә җитте, аңа яшелчә һәм киптерелгән җиләк-җимеш өстәп җибәрергә вакыт. Аннары табага бераз ит шулпасы өстәп, томаланып пешсен өчен, кабат мичкә тыгабыз.

– Бу ризыкны әзерләүдә төп кыенлык шул: һәр ике минут саен табаны мичтән алып, болгаткалап торырга кирәк, – дип аңлата үз гамәлләрен Александр. – 10–15 минут, тәмам пешеп чыкканчы шулай болгатып тору тиеш. Эш җиңел түгел, табагач һәм мич белән бәйле башка коралларны куллана белмәсәң, хәтта куркыныч та әле. Өстәвенә, яшелчәләрне дә караштырып торырга кирәк – алар «al dente» дәрәҗәсендә генә пешкән булырга тиеш.

Менә ханнарча пешерелгән ат ите әзер дә инде.

Александр ит һәм яшелчәләрне көлчәгә тезде, өстен борчак үрентесе белән бизәде һәм, татып карау өчен, үзенең ханбикәсенә китерде. Ханбикә дә, аның кунаклары да соклануларын белдерми кала алмадылар. Ни дисәк тә, 8 Мартта ир-атлар бөтен нәрсәне эшли ала. Бераз гына хан булсалар – бигрәк тә.

6 Өстибез

7 Ябабыз

8 Өстибез, томалап пешерәбез

9 Өстибез

10 Алабыз

11 Тезәбез

«Татарстан» журналы редакциясе «Туган авылым» ресторан комплексына кунакчыллыгы, чынаяк кирпечле матур миче, чын ханнарча ризык әзерләүдәге ярдәме, уңайлы җиһазлары һәм үзен әкият дөньясындагыдай хис иттергәне өчен ихлас күңелдән рәхмәтен белдерә!

РЕКЛАМА

«Татарстан» журналының махсус проекты

«ТАТАРСТАН» ХАНБИКӘЛӘРЕ

милли гүзәллек елы

КАЗАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНА КАРАГАН МИЛЛИ КИЕМЕ.

Калфак – аның биеклеге 80 см га җитә алган. Чигеш калфак иясенең дәрәҗәсенә һәм байлыгына ишарәләгән.

Изү – ярымтүгәрәк рәвешендәге күкрәкчә күлмәкне бизәп торган. Изү ташлар, төрле төстәге тасмалар һәм ука белән бизәлгән.

Жилет (кыскартылган вариант) – XIX гасыр ахыры, XX гасыр башы стилизациясе.

Камзул милли киемне затлырак итә. Аны бәрхет, парча, ефәк һәм башка кыйммәтле тукымалардан текләннәр.

«Бибарс» киемнәр салоны тупланмасында дүрт дизайнер һәм рәссамның эше тәкъдим ителгән. Бу, тарихи материалларга таянып, милли киемгә заманча карашны чагылдыру омтылышы, XV–XVI һәм XIX гасырлардагы милли кием культурасына якынаю мөмкинлеге.

XV-XVI ГАСЫРДАГЫ КАЗАН ХАНЛЫГЫНА КАРАГАН МИЛЛИ КИЕМ

Конус формасындагы баш киеме. Аның формасы кием хуҗасының дәрәҗәсен күрсәткән. Бәйрәмгә киелә торган баш киеме кыйммәтле ташлар, тәңкәләр белән бизәлгән.

Асылмалы чигә бизәнгечләре, чулпылар шул чорда яшәгән хатын-кызларның баш киеме өчен хас әйберләр булган.

Хәситә – күлмәк өстеннән сул як җилкә аша үткәреп, уң култык астына киелә торган бәйләвеч. Хәситә хуҗабикәнең дәрәҗәсен, гаиләсе һәм нәселенең байлыгын күрсәткән. Еш кына ул ир бүләге, ата-ана тарафыннан әзерләнгән бирнә саналган.

«Татарстан» журналының махсус проекты

«ТАТАРСТАН» ХАНБИКӘЛӘРЕ

Татарстанда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы «Татарстан» укучыларына республиканың иң матур милли киемнәренә соклану мөмкинлеге бирә. Проектта катнашучыларның һәрберсе бишәр сорауга җавап бирде. Җаваплар сезнең алдыгызда.

ПРОЕКТ АВТОРЛАРЫ:

Фото: **Александр Сафронов**

Костюмнар: «**Бибарс» киемнәр салоны; Казан татарларының XV–XVI гасырлардагы милли костюмнарын чагылдырган тупланма**

Текст: **Мария Ермакова**

1 **Сез үз халкыгызның милли киеменә ничек карыйсыз?**

2 **Сез ничек уйлыйсыз: ул заманнарда хатын-кызларга бу киемнәрне кию уңайлы булганмы? Мондый кием киеп яшәү?**

3 **Милли киемдә үзегезне ничек хис итәсез? Әгәр мода кинәт кире кайтса, сез аны көндәлек тормышта кия алыр идегезме?**

4 **Йөз елдан соң варисларыбыз бүген без кигән киемнәрне фотосессияләр өчен сайлармы?**

5 **Бүген сез кигән кием иясен ничек күрәсез? Аның тормышын, көнкүрешен, гаиләсен тасвирлый алыр идегезме? Безгә үткәннәрдән сәлам әйтеп карагыз әле.**

МОНДЫЙ КИЕМНЕ КИЮ – ҮЗЕ ҮК СӘНГАТЬ

ГҮЗӘЛ ГАЛИЕВА,
«СкинМед» инновацияле косметология клиникасы җитәкчесе:

1

– Милләтем буенча мин – татар. Мондый фотога төшү мөмкинлегенә бик шат, чөнки **минем өчен милли киемебез, гореф-гадәтләребез, мәдәниятебез бик кадерле. Аларны популярлаштыру да минем өчен мөһим.**

2

– Әгәр ханым мондый затлы киемнән икән, димәк, аңа киенергә һәм, мөгаен, көнкүрешне алып барырга булышучы хезмәтчеләр дә булгандыр.

Ә хуҗабикәнең бурычы – мондый матур киемне кия белеп кию. Ул аны бик рәхәтләнеп кигәндер, дип уйлыйм.

3

– Бик уңайлы хис итәм, чәч турында кайгыртырга кирәк түгел, чөнки баш киеме каплый, кием матур, купшы. Мондый костюмны бик рәхәтләнеп кияр идем, ләкин көн саен түгел, берәр тантаналы чарага.

4

– Күптән түгел Казан модельеры Ася Бажан «Совет модасы» темасына лекция сөйләде. Минемчә бик кызык булды. **Шулай ук киләчәктә кемгәдер безнең киемне киеп карау да кызыклы булыр.**

5

– Ихтимал, бу нугай ханы Йосыфның кызы, Казан ханлыгы ханбикәсе, берничә Казан ханының хатыны Сөембикә костюмы булгандыр.

Ул максатчан, үз кадерен белә, гаилә традицияләрен саклый, нәрсә һәм ни өчен эшләгәнен ачык аңлый торган ханым буларак күз алдына килә. Югары даирәгә караган ханым булганлыктан Сөембикә еш кына мөһим очрашулар үткәргәндер, ихтимал, бу костюмга охшаш киемдә.



МӘХӘББӘТ НУРЫ. ҮЗЕҢӘ КАРАТА

Дөнья дәрәҗәсендәге нәтиҗәле косметологик технологияләрне һәркем өчен куллана алырлык итү – «СкинМед» косметология клиникасының гади эш принцибы әнә шул. Нәтиҗәсе күзгә күренеп тора.

Анастасиягә 35 яшь. Бүген иртә белән ул гомерендә беренче мәртәбә көзгегә рәхәтләнеп карый. Яшүсмер чактагы бетчәләрдән калган эзләр, әңгәмә, танышу, очрашулар вакытындагы оялулар ниһаять юкка чыга. Анастасия хәзер үзен теләгәненә ирешерлек, дөньяны яулап алырлык итеп тоя.

– Безгә еш кына олы кешеләр дә мөрәҗәгать итә, алар озак еллар битләрендәге тап, җөйләрне зур кимчелек дип санаган, – дип сөйли «СкинМед» косметология клиникасы директоры Гүзәл Галиева. – Мин һәрвакыт пациентларым белән бу проблемалардан котылу шатлыгын уртаклашам. Озак еллар мин үзем дә акнедан интектем. Миңа чыннан да өр-яңа ысул – пикосекундлы лазер технологиясе[*] генә булышты. Мин ихтыяҗы булган һәркем мондый процедурадан файдалана алырга тиеш дигән фикергә килдем. «СкинМед» клиникасында бу аппарат шул рәвешле пәйда булды.

ТИРӘН ДӘРӘҖӘДӘГЕ МАТУРЛЫК

– Уңыш хәзер күбесенчә шәхси бренд белән ассоциацияләнә. Ә бит тиресенең чиста, матур булуы – аның бик мөһим өлеше. «СкинМед» клиникасының өстенлеге – процедураларның максималь дәрәҗәдә куркынычсыз һәм нәтиҗәле булуы, – ди «СкинМед» директоры.

Нәкъ менә шуңа күрә Гүзәл Галиева, барлык тиешле сынауларны узып, сертификация алган аппарат косметологиясе яклы. Аның клиникасында иң популяр процедураларның берсе – «Альтера» аппараты ярдәмендә SMAS-лифтинг[**] ясау. Ультратавышлы лифтинг процедурасы тиренең эчке тирән катламнарында башкарыла (SMAS[***] дип аталган дәрәҗәдә), анда пластик хирурглар гына эшләгән. «Альтера» тирене операциясез генә тарттырырга мөмкинлек бирә. Процедура төрле яшьтәге хатын-кызларда да, ир-атларда да күзгә күренерлек сыйфатлы нәтиҗә бирә.

– Минем максат – «СкинМед» клиникасын Казанда һәм Татарстанда SMAS-лифтинг буенча иң яхшысы итү. Без мондый бик күп процедуралар ясыйбыз, бик уңай фикерләр ишетәбез. Хирургия ысулын куллану мөмкинлеген караган хатын-кызларның бу уйдан кире кайтуы аеруча сөендерә. «Миңа хәзер барысы да ошый!» – ди безгә пациентларыбыз. Мондый мизгелләрдә без үзебезне бәхетле хис итәбез! Хәзер без алынган мәгълүматларны гомумиләштерү һәм Татарстан Республикасы халкына нәтиҗәләр күрсәтү белән шөгыльләнәбез, – ди клиника директоры.

ЫШАНЫЧКА НИГЕЗЛӘНГӘН НӘТИҖӘЛЕЛЕК

Гүзәл Галиева фикеренчә, сәламәт тире – иң беренче чиратта үзе турында кайгырту нәтиҗәсе. Матур йөзегезне күргәндә көзгегә карау искиткеч рәхәт. Бу көч-дәрт, илһам бирә, һәм тормыш юлын шатланып үтәргә ярдәм итә.

– Үткәрелгән косметологик процедуралардан кирәкле нәтиҗә алу өчен тиренең беренчел халәтен теркәргә, дәвалану планын төзергә һәм аны төгәл үтәргә кирәк. Мондый дәвалану планын беренче тапкыр консультациягә килгәч дерматолог-косметолог төзи, – ди «СкинМед» җитәкчесе. – Эксперт-табибка ышаныч безнең эштә иң мөһиме. Без психологик уңайлыклар, эчкерсез кайгырту һәм һәрнәрсәдә уңайлык тудырырга тырышабыз. Безнең өчен пациентның ышанычы кадерле.

** Пикосекундлы лазер ярдәмендә бит тиресен тарттыру – тиренең өске катламнарына стимуллаштыручы косметик процедура. Пикосекундлы лазер шулай ук җөйләрне, татуировкаларны эзен калдырмый бетерү өчен кулланыла.*

*** Альтера-терапия (Ultherapy ®) – микрофокуслы УЗИ ярдәмендә, реаль вакытны күрсәтеп, бит тиресен хирургик булмаган ысул белән тарттыруның һәм җыерчыкларны киметүнең дөньяда бердәнбер технологиясе.*

**** SMAS – superficial muscul araponeurotic system, ингл. – өске мускул-апоневротик система.*

Фото «СкинМед» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ДӘРӘҖӘЛЕ ҺӘМ ГАҖӘЕП НӘФИС

ГӨЛНАРА ШӘЙХЕТДИНОВА,
«Печать-Сервис-XXI гасыр» нәшрияты һәм мөһер һәм штамплар ясау остаханәсе җитәкчесе:

1

– Милләтем буенча мин татар һәм **милли костюмнарыбыз миңа бик ошый** Хәтерлим әле, без бәләкәй чакта бию түгәрәгенә йөри, төрле чыгышлар ясый идек. Сабантуйда, башка татар бәйрәмнәрендә татар биюләре биедек. Һәрвакыт костюмнар тектерә, аларны бизи, матурлый идек.

2

– Минемчә, мондый киемне, бигрәк тә бизәнү әйберләрен бәйрәмнәрдә кигәннәр. Мондый кием, әлбәттә, бик уңайлы булмагандыр.

Бу костюмнар шул заман чынбарлыгына туры килгән: һәрбер деталь уйланылган, һәм ул вакытта бик табигый күренгән.

3

– **XVIII-XIX гасыр татар морзабикәсе киемен киеп карау кию бик кызык.** Купшылык һәм дәрәҗәлелек, бу ханымның затлы нәселдән булуы һәм шул ук вакытта нәфислек һәм матурлык сизелеп тора. Бүген дә күп кенә туташ-ханымнар озын күлмәк һәм жилетларны яратып кия. Әмма монда аерым үзенчәлекләр бар: бөрмәле киң җиңнәр, жабо яка, катлаулы баш киеме – бүгенге тормышта, әштә һәрвакытта да уңайлы түгел. Милли кием яисә милли чигеш элементлары кертеп тегелгән күлмәк яисә жилетны бик рәхәтләнеп кияр идем!

4

– Кем белә, бәлки киләчәк буын да заманча киемне яңа вакытка туры китереп үзгәртер.

5

– Әлеге костюмның затлылыгына карағанда, мин югары даирәгә керүче ханым. Ләкин мөселман патриархаль тормыш рәвеше хөкем сөргән чорда минем ролем бик чикле: балаларымны тәрбияләү турында кайгыртам, иремне яратам, хуҗалыкны алып бару белән идарә итәм, әлбәттә, минем ярдәмчеләрем яисә хезмәтчеләрем дә күп. **Һәм мине бүгенге заманның шәхси һәм социаль үсеш өчен хатын-кызларга ул вакытларга карағанда шактый күбрәк мөмкинлекләр бирүе бик шатландыра.**

КИТАПЛАР, ШӘҖӘРӘЛӘР ҺӘМ НӘШРИЯТ ЯҢАЛЫКЛАРЫ ТУРЫНДА

Мәңгелек кыйммәтләребез – китаплар. Бу турыда хәбәрчебез «ПЕЧАТЬ-СЕРВИС-XXI ГАСЫР» ҖЧҖ компаниясе генераль директоры Гөлнара Шәйхетдинова белән сөйләште.

– Гөлнара Шамилевна, китап бастыру эшенең киләчәге нинди? Гомер-гомергә гыйлем чыганагы саналган кәгазь китапны гаять зур хәтер күләменә ия, тиз эшли торган гаджетлар алыштырмаслармы?

– Бер яктан, бүгенге көндә электрон форматның күпмедер дәрәҗәдә кәгазьдәгесен кысрыклый баруын танырга кирәк. Хәзер теләсә кайсы җайланмада китап укып була: телефонда, сәгатьтә. Икенче яктан, китаплар һәрвакыт булган, бар һәм булачак: без калын-калын томнарны кулыбызда тотарга, исен иснәргә, рәсемнәренә сокланырга яратабыз. Ярар, мин элекке чыныгу алган буын кешесе буларак электроникага күнекмәгән, ә менә яшьләр китап турында нәрсә уйлый соң? Монда ике тенденция күзәтелә. Беренчедән, электрон мәгълүмат менталь яктан авыррак үзләштерелә. Кешегә игътибарны туплау өчен күбрәк көч куярга кирәк. Икенчедән, яшьләр арасында төрле комикслар популяр. Ә бу рәсемнәрнең төсле булуын күз уңында тота һәм сериялэп басыла. Бу шулай ук басма китап файдасына сөйли. Шуңа күрә нәрсәне – эволюция, ә нәрсәне вакытлыча мавыгу дип санарга кирәклеген өздереп әйтүе авыр. Ләкин китапның безнең белән әле бик озак яшәячәгенә шик юк, һәм әлегә гаджетның китапны җиңәргә теше үтми.

– Бай басма продукция базарына үзегезне нинди яңалык керттегез, дип саныйсыз?

– Кызыклы юнәлеш пәйда булды һәм ул үсеш кичерә: кешеләр үз гаиләләре, нәселләре тарихы, ягъни шәҗәрәләре белән кызыксына башлады. Эзләнүләр барышында еш кына якын һәм ерак туганнары тарафыннан язылган шигырь, хикәя, истәлекләр табалар. Әлеге язмаларны үзләрендә калдыру, эти-әниләренә, балаларына истәлеккә бүләк итү өчен, кешеләрнең табылган бөтен мәгълүматны туплап, китап чыгарасылары килә. Тамырларың белән кызыксыну, аларга хөрмәт күрсәтү, ата-бабаларыңның истәлеген саклау һәм шул ук вакытта гаилә тарыхында үз эзеңне калдыру бик шәп ният. Без мондый гамәлләрне тормышка ашыруга бик рәхәтләнеп булышабыз һәм, әйтергә кирәк, заказларның саны арта бара.

– Китап бастыру белән шөгыльләнгәндә, эшчәнлегегезнең агарту юнәлешен дә күздә тотуы өчен җаваплылык тоясызмы?

– Әлбәттә, тоям. Безнең үзебезнең билгеле бер юнәлешебез, урыныбыз бар – без күбрәк фәнни-методик нәшрият һәм төрле вузлар, мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләр белән эшлибез. Без методик әдәбият, конференция материаллары җыентыкларын, авторлык дәреслекләрен һәм эш дәфтәрләрен, ягъни балаларыбызның үсешенә һәм белеменә турыдан-туры йогынты ясаучы басмаларны нәшер итәбез. Безгә ялгышырга ярамый.

– Китап кыйммәтләнә бара. Гадирәк материаллар куллану, яңа бастыру технологияләрен кертү, башка инновацияләр ярдәмендә аларның бәясен киметү мөмкинлеге бармы?

– Беренче чиратта без продукциябезнең сыйфаты турында кайгыртабыз, шуңа күрә оригиналь чыгым материаллары һәм югары сыйфатлы кәгазь кулланабыз. Кызганычка каршы, бүгенге вазгыятьтә басма продукцияне кыйммәтләндермәү юллары турында уйларга туры килә. Кәгазь базарында безнең илгә карата кулланылган санкцияләр шактый көчле булды: кәгазьнең күп кенә сортларын һәм кайбер кирәкле химикатларны кертү кыскартылды. Аларга алмаш эзләргә туры килә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: күп кенә аналоглар сыйфат буенча чит илнекеннән бер дә калышмый, бәясе дә кулайрак. Бу басма продукциябезнең төрлелеген һәм сыйфатын саклап калырга ярдәм итә.

– Әгәр сез китап бастыру белән шөгыльләнмәгән булсагыз, нинди эшчәнлек төрен сайлар идегез? Яхшы китапларны нәрсәгә алыштырып була?

– Үз бизнесымны һәм нәшриятемне җитәкләгәнче, мин мәктәптә шактый еллар физика һәм информатика укытучысы булып эшләдем. Барысы да ошый иде, балалар да мине яратты. Мөгаен, мин мәгариф тармагында эшләвемне дәвам итәр идем әле.

Ләкин нәтиҗәдә үзем өчен шундый иҗади һәм файдалы эшчәнлек өлкәсен сайлавыма мин бик шат!

Фото: Александр Сафронов. РЕКЛАМА

PRESSA

МИН УЛ ЗАМАНДА ЯШӘР ИДЕМ...

АЛЬБИНА СЕРГЕЕВА,
«Игелекле тарихлар» пансионатлар челтәренә нигез салучы һәм аның җитәкчесе:

1 – Әлеге акциядә бик рәхәтләнеп катнаштым. Миңа күлмәгем дә бик ошады. Мин ике – татар һәм рус халыклары баласы. Һәм **Татарстанда, гомумән Россия территориясендә яшәүче халыкларның бердәмлеген** хуплауны бик дөрес дип саныйм. Бердәмлек хөкем сөргән зур илдә дус-тату гомер итү, шул ук вакытта милли үзенчәлекне җуймыйча, үз тамырларыңны онытмыйча яшәү мөһим.

2 – Уңайлылыкка килгәндә, белмим, **миңа калса, аларның сайлау мөмкинлеге булмаган, шуңа күрә костюмга ияләшәсең.** Миңа калса, аларга авыр булмагандыр.

3 – **Бу костюмда мин үземне бик матур, гүзәл ханымдай хис иттем,** чөнки нинди затлы алкалар, муенсалар... Әйе, мөгаен, мин ул заманда, шул чорда яшәп карар идем. Ни дисәң дә, ул вакытта да хатын-кызлар кеше арасына чыккан, иң яхшы киемнәрен күрсәтә алган. Кызганычка каршы, хәзер барысы да гадирәк. Без чалбар киюне хуп күрәбез, күлмәкләрдән азрак йөрибез.

4 – **Әйе, әлбәттә.**

5 – Мин бит ханбикә киемендә. **Миңа калса, ул бик акыллы, зыялы ханым булган.** Янәшәсендә – ире, балалары. Ул нәзакәтле, укымышлы, аңардан тирә-юньгә җылылык, миһербанлык сирпелә.

ХӘТЕР ЯЛГЫШУЫ КӨТКӘНДӘ...

Деменция – бүгенге заманга хас иң куркыныч авыруларның берсе һәм, ул миңа кагылмаячак, дип беребез дә әйтә алмый. Әмма шулай да бу авыруга каршы тору ысуллары бар. Алдагы саннарда без «Игелекле тарихлар» пансионатлар челтәре һәм аның эшчәнлеге турында язган идек инде. Акыл зәгыйфьлегенә дучар булган кешеләргә упкын кырыенда тукталып калырга ярдәм кулы сузучылар турындагы бәянебезне дәвам итәбез.

КАРАҢГЫЛЫКТА ҮЗЕҢНЕ ЮГАЛТМА

Бүгенге көндә алты пансионат эшли, алар белән өлкән яшьтәге кешеләрне һәм инвалидларны карау-тәрбияләү буенча эксперт Альбина Сергеева җитәкчелек итә. Табиб һәм педагог гаиләсендә туып үскән ханым үзенә хәтер һәм фикерләү сәләтен югалтудан, шулай ук катлаулы аяк авыртуларыннан интегүче ир-атлар һәм хатын-кызлар белән эшләү кебек авыр юлны сайлаган. Бу – үзләре дучар булган бәхетсезлектән югалып калган кешеләр. Ә җитәкче кул астында эшләүчеләрнең бурычы – дәваланучыларны тынычландыру, җылы сүз белән күңелләрен күрү, нәрсә белән кызыксынуларына, хәлләренә карап, аларны берләштерү, ә иң мөһиме – төшенкелектән коткару.

Альбина Васильевна фикеренчә, деменцияне башка авыруларны җиңгән кебек күпмедер вакыттан соң җиңеп булмаса да, «алдаларга» мөмкин. Когнитив тайпылышлары булган кешеләрнең төп проблемалары – әлеге авыру китереп чыгарган депрессия һәм алга таба да бары тик начараюны гына көтү. Бу очракта максатчан белгечләр генә ярдәм итә ала, һәм «Игелекле тарихлар» пансионатларында авыру кешегә ничек итеп уңай кичерешләрне кайтарып булуын беләләр.

Үзара аралашу бу очракта зур дәва була ала – кешеләр бергә рәсемнәр, сыннар, ниндидер башка әйберләр ясыйлар, чәй эчәләр. Аларга артистлар концерт куя, һәр пансионатта мәдәният белгече, аниматор эшли. 2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүгә ТР грантын оту нәтиҗәсендә «Игелекле тарихлар» пансионатларында «Хәтердә калу» дип аталган социаль проект башланып китә. Аның кысаларында тәрбияләнүчеләр белән этикет, бию буенча мастер-класслар, күчмә экскурсияләр оештырыла. Нәтиҗәдә элек үз-үзенә йомылган кешеләрдә аралашуга, яңа тәэсирләр алуга кызыксыну уяна. Персоналның мәрхәмәтле мөнәсәбәте дә бик зур роль уйный – «Игелекле тарихлар»га эшнең үзенчәлеген аңлаган җаваплы кешеләр генә килә. Алар җилкәсенә көн саен зур физик һәм рухи көч сорый торган йөк төшә, чөнки сабыр була, юата, кеше хәленә керә белү – бик авыр эш...

ТӘН ҺӘМ ҖАН ЯРАЛАРЫ ТУРЫНДА

Деменция һәм авыр җәрәхәтләр корбаннарының туганнарына да җиңел түгел. Мондый хәлгә тарыган якынына булыша алмаудан гаҗизләнгән кеше үзе дә гаять көчле нерв киеренкелеге кичерә. «Игелекле вакыйгалар» пансионатлар челтәре – эш, балалар һәм чынбарлык арасында бәргәләнергә мәҗбүр кешеләрне коткару урыны. Авыруга дучар кеше – биредә тиз арада тиешле ярдәмне, ә туганнары психиатр киңәшләрен, алга таба нишләргә кирәклеге турындагы тәкъдимнәрне ала.

«Игелекле тарихлар» челтәренә караган пансионатлар торган саен ешрак кунакханә ролен дә үти бара. Бергә катлаулы сөяк сынуларыннан соң дәваланып бетәргә килеләр. Монда өйләрендә газ һәм ут-суны сүндерергә онытып җибәрә торган әби-бабайларны гаилә ялга киткәндә вакытлыча калдырып та торалар. Кайчандыр пансионатта дуслар тапкан күп кеше туганнарына «шифаханә»гә кунакка алып барып кайтуларын да сорый. Җәй айларында бигрәк тә тыгыз була һәм, билгеле булганча, пансионатлар челтәре киңәйтеләчәк.

Сөекемле кызлар һәм туташларны, гүзәл ханымнар һәм хөрмәтле әбиләрне яз бәйрәме – 8 Март бәйрәме белән котлыйм!

88432608020

dobrostory.ru

Альбина Сергеева фотосы. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

МОНДЫЙ КИЕМДӘ ПАТШАЛЫК КЫНА ИТӘРГӘ

АНАСТАСИЯ ГЫЙЛЬМАНУРОВА,
«Ментор» коучинг академиясенә нигез салучы:

1

– Минем әнием татар, этием – рус, ирем – татар. Менә шундый күпмилләтле гаилә. Шуңа күрә **төрле милли костюмнарга хөрмәтем һәм соклануым чиксез, мин аларга гасырлар зирәклеге сеңгән, һичшиксез сакланырга тиешле изге әйбер кебек карыйм.**

2

– Барысы да яшәү рәвешенә бәйле. **Мондый костюмда беркая да ашыгырга ярамый. Мондый киемдә, боерыклар биреп, патшалык кына итәргә кирәк.**

3

– Мин, мөгаен, мондый кием киеп йөри алыр идем. Ихтимал, берникадәр вакыт җайлашырга, тормыш системасын көйләргә туры килер иде. **Ләкин вакыт узу белән, барысы да җайга салыныр иде, һәм без костюм белән бер-беребезгә күнегеп бетәр идек.**

4

– **Кешеләргә «үткәннәрдә» булып карау һәрвакыт кызык, дип уйлыйм.** Минем мондый проектларны төрле журналларда күргәнем бар: кешеләр, мәсәлән, танылган картинадагы киемнәргә киенеп карыйлар. Бу шактый кызык тоела.

5

– Миңа өлкән яшьтәге ханым костюмы туры килде, минемчә, ул тыныч, зур ихтыяр көченә, зирәклеккә ия. Бу киемне бик иҗади, хәзергечә әйтсәк, креатив кеше теккәне сизелә. Ханымның гаиләсе ишле булгандыр, анда мәхәббәт һәм шатлык хөкем сөргән. Аның исеменнән үткәннәрдән сәлам биреп, **мин замандашларыма бәхетле мизгелләрне күрә, тоя белегез, дип әйтер идем, шул чакта гына тормышыбыз түгәрәк булачак.**

ШӘХСИ ҮСЕШ ТЕРРИТОРИЯСЕ

Пандемия һәм цифрлы технологияләр үсеше онлайн-хезмәттәшлекне безнең тормышның бер өлешенә әйләндерде. Әмма чын элемтә серләре тере аралашуда гына ачыла.

– «Мин үзем җиләккә каймак салып ашарга яратам, ләкин балык нигәдер суалчанны өстен күрә. Менә ни өчен мин балык тотарга барганда, үзем турында түгел, балык турында уйлыйм». Дейл Карнегиның бу сүзләре үзебез өчен мөһим булган кешеләр белән мөнәсәбәтләребезне аңлауда ачкыч булып тора, – дип аңлата тыңлаучыларга тренингны алып баручы.

Афоризмнар, фильм, экиятләрдән алынган өзекләр – мондый алымны «Ментор» академиясендә эре компанияләр җитәкчеләрен бизнес-тренерлар сыйфатында укыту өчен файдаланалар.

– Әлеге курсларны тыңлаучылар – үз өлкәләрендә бик яхшы белгечләр – риелторлар, финансистлар, иминият агентлары. Җитәкче булып эшли башлагач, алар команданы өйрәтергә кирәклеген аңлый. Ләкин үз осталыгыңны башкаларга җиткерә белү – сәнгать. Яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен аңа өйрәнергә кирәк, – ди Анастасия Гыйльманурова. Ул ире Радмир Гыйльмануров белән бергә берничә ел элек «Ментор» коучинг академиясен оештыра. Бүген тренинглар, мастер-класслар, төрле форматтагы сессияләр уздыру буенча зур тәҗрибә туплаган академия төрле белем бирү чараларын оештыручылар өчен ишекләрен ача.

БӨТЕН ДӨНЬЯ ЛИДЕРЛАРЫ

Коучинг – кешенең үзе дә белмәгән сәләтен һәм мөмкинлекләрен ачу коралы, әңгәмәдәшкә ул үзенең иҗади ресурсларын аңлый алырлык итеп сорау бирү осталыгы. Бу махсус һөнәр, аны профессионаллардан өйрәнергә кирәк.

– Коуч юлы – даими профессиональ үсеш юлы ул. Без клиентларыбызга үзебезнең хәрәкәтебез, трансформация, һөнәри осталыгыбыз аларныкыннан артып киткән очракта гына кызыклы, – ди әңгәмәләрнең берсендә Рус телле коучлар ассоциациясе идарәсе рәисе Андрей Королихин. «Ментор» бүген аның белән хезмәттәшлекне актив үстерә.

– Без – ICBT бизнес-тренерларының халыкара мәктәбе провайдерлары, шуңа күрә без җирле компанияләр өчен кечкенә сессияләрдән алып эре корпоратив белем бирү проектларына кадәр – төрле форматтагы әйдәп баручы яки тренерны сайлый алабыз, – ди Анастасия Гыйльманурова. – Безнең партнерыбыз һәм коллегаларыбыз – коуч, медиатор, профориентолог, уен алып баручыларыбыз бик күп. Шуңа күрә академия икмәк пешерү челтәре өчен квест та, эре республика автоконцерны өчен команда оештыру тренинглары да оештыра ала.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ КОМФОРТТА ҮСТЕРҮ

Академия үз клиентларына үсеш юнәлешен эшләргә ярдәм итә. Алынган күнекмәләр аларга көчне максималь дәрәҗәдә туплау юнәлешләрен ачыкларга, якындагы 10–15 елда керемнәрне арттыру һәм шәхси яктан үсү перспективаларын табарга булыша. «Ментор» программалары профессионаллар тарафыннан бик җайлы итеп төзелгән һәм бер-берсе белән бәйләнмәгән берничә курсны сатып алганда акчаны янга калдырырлык итеп эшләнгән. «Бик шәп компания! Казанда кешеләр белән эшләү өлкәсендә мондый позитив, драйв һәм белем бирү башка юк! Тренингка барырга телисезме? Үзеңне, мөмкинлекләреңне ничек аңларга һәм максатыңа ни рәвешле ирешергә? Балагыз тормышында активлыкны үстерергә телисезме? Рәхим итегез!» – «Ментор» академиясендә узган чараларда катнашучылар әнә шундый фикерләр калдырган.

Диләрә Фәтхуллинаның маркетологлар мәктәбе, Казан йога мәктәбе, «Социаль уеннар» проекты «Ментор»ны яраткан мәйданчык итеп юкка гына сайлап алмаган. Параллель рәвештә берничә чара үткәрергә һәм диварларында презентация материалларын эләргә мөмкин булган ике кат, тиешле күләмдәге флип-чартлар, кофе-брейк зоналары, кирәкле җиһазлар, бушлай иркен машина кую урыны – бу шартларның барысыннан да үз мәгариф активлыклары өчен академия бүлмәләрен арендага алган оешмалар бик рәхәтләнеп файдалана.

– Без хәрәкәттә, алгарышта булырга яратабыз. Без икътисадта, җәмгыятьтә, фәндә пайда булган үзгәрешләрне күзәтәбез һәм аларга ияреләргә тырышабыз, – ди Анастасия Гыйльманурова. – «Ментор» академиясендә апрель аенда узачак «Арт-техник» фестивале программасына шәхси бренд, матур чыгыш әзерләү, стресска каршы көрәшү ысуллары сыйфатында арт-практика кебек актуаль, көнүзәк темаларны керттек.

«Ментор» академиясе Татарстанда 17 елдан артык эшли. Әлеге вакыт эчендә биредә 1,5 меңнән артык коуч, бизнес-тренер, ментор, уен технигы, остаз белем алды. Коучингка өйрәтү – Халыкара коучинг федерациясе программасы буенча, тренерларны укыту ICBT Бизнес-тренерлар мәктәбенең (Мәскәү) эксклюзив программасы буенча алып барыла. Академияне тәмамлаучылар яңадан һөнәри әзерлек узу турында диплом һәм программа сертификаты ала. Академия партнерлары арасында – «Аудэкс», «Мегафон», ICL, X5 Group, «ТМС групп», «Корд Оптика» компанияләре, «Этажи», «Флэт» һәм башка агентлыклар.

Фото Анастасия Гыйльмануровадан алынды. РЕКЛАМА

СЕЗ ЭЗЛӘГӘН НӘРСӘ: ВӘГЪДӘСЕН ҮТИ ТОРГАН ТАБИГЫЙ КОСМЕТИКА

Дистәләгән төрле абруйлы бүләк алган бренд. Россия, Франция һәм Көньяк Кореяның халыкара лабораторияләрендә тикшеренүләр белән расланган нәтиҗәлелек һәм иң мөһиме – меңләгән клиентның канәгать калуы. Сүз «Олеся Мостаева остаханәсе» турында бара.

ОЛЕСЯ МОСТАЕВА,
КОМПАНИЯГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ:

– Барысы да йөкле вакытта тире бозылу белән булган үз проблемаларымны чишүдән башланды. Миңа косметика кибете консультантлары, косметологлар булышырга тырышты, ләкин файдасы булмады. Үз чиратында бу хәл башка уңайсызлык та тудырды – идарәче вазифасында начар күренергә ярамый. Үзем ясаган косметика гына бу хәлдән котылырга ярдәм итте.

Аннары аны дус кызларым, аларның ахирәтләре куллана башлады, һәм берникадәр вакыттан соң үз брендымны булдырырга кирәк дигән фикер туды. Сүз уңаеннан, дус кызларым да моны хуплады...

Еш кына шулай килеп чыга да: үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен тудырылган әйбер бизнес булдыру идеясенә этәрә.

Нәтиҗәдә Россиядә табигый һәм экологик чиста косметиканың яңа бренды пәйда була.

13 ел элек формалашкан «Олеся Мостаева остаханәсе» брендының беренче линейкасы бүген Татарстанда гына түгел, Россиядән читтә дә билгеле. Якындагы планнарда – компаниянең Азия юнәлешендәге эшен көчәйтү. Кытай партнерлары белән эшләү дә ассортиментны билгеләү этабында.

ОЛЕСЯ МОСТАЕВА,
ТӨП ТЕХНОЛОГ-БАШКАРУЧЫ:

– Безнең бренд өчен продуктларның фәнни яктан раслануы һәм яхшы нәтиҗә бирүе мөһим.

Төп максатларыбызның берсе – кулланучы сатып ала алырлык продукция тудыру. Кайвакыт миннән, һичьюгы берничә мең сум тормаган крем файдалы була аламыни, дип сорыйлар. Әйе, була ала! Безнең тикшеренүләр дә моны раслый. Әлеге искиткеч нәтиҗәнең хикмәте – төрле ингредиентларны белеп сайлап, аларның кечкенә генә өлешләрен дөрес итеп кушу.

Табигый косметикадагы тенденцияләрнең берсе – бизәнү әйберләренең күпфункцияле булуы. Мин моңа бик шатланам. Сүз уңаеннан, табигый косметика үзе үк актуаль тенденция, статистика күрсәткәнчә, ул үсеш тенденциясенә ия.

Һәм шулай килеп чыга ки, «Олеся Мостаева остаханәсе» баштан ук исле матдәләр кермәгән, сизгер тирегә туры килми торган, дерматозлы, аллергияле кешеләр өчен ярамаган компонентлар кушылмаган продукция җитештерә.

Компания җитештергән барлык ассортимент «Хәләл» стандарты буенча сертификацияләнгән. Крем, шампунь, тоник, битлек, скраб сатып алганда, аларның составында бары тик табигый үсемлек компонентлары гына булуына ышанып була. Хайваннардан алынган ингредиентлардан балавыз һәм сөт пептидлары гына бар.

ОЛЕСЯ МОСТАЕВА,
ИКЕ БАЛА АНАСЫ:

– 14 яшьлек олы улым белән без бик күп сөйләшәбез. Мин аңа китап укытырга тырышам, бергә берәр нәрсә пешерергә дә яратабыз. 5 яшьлек кызым белән кул эшләре эшлибез, укыйбыз – өебездә зур китапханә бар. Сүз уңаеннан, кәгазь басмаларны өстенрәк күрәм. Минем өчен китапка кагылу, битләрен кыштырдату мөһим. Монда ниндидер яшерен сер бар кебек. Электрон китап карсыз Яңа ел кебек.

Мин үземне бизнестан аерып карый алмыйм. Асылда ул минем өченче балам. Нык арганда ял итеп алу өчен, тулы тынлыкта, ялгызлыкта калу да җитә. Минем өчен иң яхшы ял – эшчәнлегемне үзгәртү. Т

МАСТЕРСКАЯ ОЛЕСИ МУСТАЕВОЙ

master-om.com

mustaeva_beauty

masteromcom

Фото Олеся Мостаевадан алынды. РЕКЛАМА

ЯШЕЛ ҮЗӘН БЕСТСЕЛЛЕРЫ

Әгәр сез кешеләргә һәм дөньяга файда китерәсез икән, көндәшлек куркыныч түгел. Әнә шул идея героинябызны гаилә, бизнес, сәясәт белән шөгыльләнергә дә, мөмкин булмагандай тоелганны ни рәвешле чынбарлыкка әйләндерү турында китап язарга да илһамландыра.

Мәсәлән, дөнья дәрәҗәсендәге гигантлар һәм бик тиз үсә барган маркетплейслар фонында төзелеш товарлары сата торган кибетләр челтәренә ихтыяҗны ничек саклап калып булуы турында.

– Чехов: «Төрткәләшергә кирәкми, әдәбиятта урын барыбызга да җитә», – дип язган. Миңа калса, бу сүзләр теләсә кайсы вазгыятькә туры килә. Бары тик үз урыныңны табып, өстенлекләрне дөрес билгеләргә генә кирәк, – ди «Каенкай» төзелеш маркетлары һәм башка берничә бизнес челтәре хуҗасы Рузилә Тимергалиева. – Безнең өчен бу ел – барлык процессларның да нәтиҗәлелеген арттыру елы. Мәсәлән, без керем планын үтәргә һәм, өстәмә хезмәткәрләр җәлеп итмичә, тәэминат күләмнәрен арттырырга телибез. Уйлап бетерелмәгән логистиканы, дөрес бүленмәгән йөкләнешне, зыянлы гадәтләрне – кыскасы, кирәкмәгәннәрне ачыкларга һәм аннан арынырга кирәк.

Кирәксездән котылу – яңа мөмкинлекләр өчен урын ачу дигән сүз. Берничә ел элек Гүзәл Тимергалиева үзе өчен әһәмиятле кыйммәтләрне яңадан бәяли һәм яңа дәрәҗәгә чыга.

КИБЕТЛӘР ЮККА ЧЫГА, САТЫП АЛУЧЫЛАР ПӘЙДА БУЛА

– Миңа «Баланс тәгәрмәче" ярдәм итте – бу гап-гади диаграмма, аңа син эшләрнең ничек баруы белән канәгатьләнү дәрәҗәсен ясыйсың – эмоциональ, физик, профессиональ яктан. Иң зур җитешсезлекләремнең кайдалыгын аңлагач, мин бушка түгелгән энергияне һәм вакытны алып ташладым, ә кирәклеләрен берләштерергә өйрәндем. Хәзер миңа бер үк вакытта файдалы һәм яраткан берничә эш эшләү ошый: иртән наушникта лекция тыңлый-тыңлый йөгерергә, балалар белән бергә ял итәргә, яңалыкка өйрәнергә һәм шунда ук аларны бизнеста кулланырга, – ди Гүзәл Тимергалиева.

Сигез ел элек, Яшел Үзәндәге ике «Каенкай» кибете табыш китерми башлагач, эшмәкәр анда барысын да үзгәртергә карар кыла. Шул рәвешле «киштәләр» системасын үз-үзеңә хезмәт күрсәтү форматы алыштыра. Әлеге яңа модель буенча киләсе 8 елда Рузилә Тимергалиева тагын өч гипермаркет ача, шуларның берсе – Мари Элда. Ә 4 ел элек тормышында үсеш өчен башка юнәлешләр дә бар дигән карарга килә.

– Мин Татарстан Дәүләт Советы депутаты булгач, социаль челтәрләрдә: «Нигә ул сәясәткә кысыла?» дип яздылар. Җавап бик гади – минем бу эш өчен җитәрлек энергиям бар һәм мин кешеләргә файдалы була алам, дип уйлыйм, – ди Рузилә Тимергалиева. – Күбрәк биргән саен, күбрәк аласың – бу минем инануым.

БАШЛАР ӨЧЕН НОКТА КУЮ

«Яшь ярымлык бала белән ирсез һәм эшсез, әмма кызыл диплом белән калуны, мөгаен, хәрәкәтемне Б ноктасы юнәлешендә башлаган шәхси А ноктам дип санарга буладыр. Әлбәттә, ул чакта минем ноктала турында уйларга вакытым юк иде: яшәр өчен акча һәм урын кирәк. Мине өметсезлек биләп алды. Шул чакта бер туганым Ульяновск өлкәсенең Ишеевка бистәсенә чакырды, анда Ульяновск төзелеш пластмассасы заводы линолеум производствосын ачты. Мин баламны әниемә калдырдым да шунда киттем. Беренче мәлдә туганым янында тулай торакта яшәдем. Программист буларак заводта хезмәт хакын исәпләү программасын кертү һәм көйләү белән шөгыльләндем. Әмма тиздән мин тагын да кызыклырак нәрсә – коммерция белән шөгыльләнә алуымны аңладым. Һәм хаклы булып чыктым». «Кечкенә шәһәрдәге зур акчалар» китабы шулай башлана. Анда Рузилә Тимергалиева җирле бизнесны уңышка китерерлек 10 пункт турында сөйли.

– Кайбер пунктларның, әйтик, эш юнәлешен, тәэминатчыны сайлауның мөһимлеге күренеп тора. Икенчеләре, мәсәлән, үз-үзеңне тикшереп тору, күпләр өчен мөһим түгел. Чыннан да партнерың дустың яисә туганың булганда нигә кирәк кебек. Ләкин нәкъ менә вак әйберләрне санга сукмау корабны батырырга мөмкин, – ди безнең герой. – Ә мин кече һәм урта бизнес кораблары флотилиясенең арта баруын телим.

Фото Рузилә Тимергалиевадан алынды. РЕКЛАМА

ЛИЛИЯ МУЛЛАХМӘТОВА: «ҮЗЕҢНЕҢ ТИҢДӘШСЕЗ БУЛУЫҢНЫ ОНЫТМА!»

Тирене филлерлар һәм ботокстан башка да яшәртеп буламы, хатын-кызлар косметологиягә кагылышлы нинди хаталар ясый? «Татарстан» журналының әлеге һәм башка сорауларына Казандагы «Аль-Варис» медицина косметологиясе һәм трихологиясе клиникасының оештыручысы һәм баш табибы Лилия Муллахмәтова җавап бирә.

– Лилия Тәбрисовна, сез ни өчен башта медицинаны, аннары исә шуңа бәйле матурлык тармагын сайладыгыз?

– Гаиләдә мин төпчек, дүртенче бала һәм апаларымнан үрнәк алырга туры килде: аларның берсе – офтальмолог, икенчесе – стоматолог. Мин дә медицина институтыннан башка бернинди уку йортына да керергә теләмәдем. Матурлык тармагын сайлауга килгәндә исә, мин кешеләрне, бөтен гүзәл нәрсәне бик яратам һәм кешеләргә Аллаһ биргән сөйкемлелекне тагын да арттыра алуыма сөенәм. Мин косметолог һәм трихолог буларак кына түгел, превентив медицина (авыруларны кисәтү белән шөгыльләнә торган юнәлеш) табибы сыйфатында да кабул итәм.

– Сезгә хәзер барыннан да бигрәк нәрсә белән шөгыльләнү кызыклырак?

– Мин инде 23 ел табиб-косметолог булып эшлим, һәм тора-бара әлеге белгечлек кысалары миңа тар тоела башлады. Хәзер мине хезмәтем нәтиҗәсе буларак бит тиресенең яшәрүе, чәчнең ялтырап торуы гына канәгатьләндерми, чөнки күреп торасың – бөкрәеп, башын аска иеп йөрүе, йөзенең ассиметриясе пациентның үзенә дә ошамый. Моны табиб гына түгел, башкалар да күрә. Без бит барыбыз да образны тулаем бәяләргә күнеккән: кеше ничек сулый, утыра, йөри...

Моннан җиде ел элек мин Израильдәге бер бик шәп белгечнең эшен күзәтә башладым: хатын-кыз үзен ханбикәләрдәй тота башлый. Зифа буй-сын, төз җилкә, горур күтәрелгән баш... Мөмкинлек туу белән, мин әлеге белгечтә укып кайттым.

Минем тормышымдагы тагын бер әһәмиятле этап – Мәскәүдә, Россия Халыклар дуслыгы университетының эндокринология кафедрасында даими укуым, ул пациентларны комплекслы дәвалауга багышланган иде.

Мине илһамландырган өченче нәрсә – генетик тестлар белән эшләү. Геннарыгызның шифрын ачу нәтиҗәсендә сез чәчегезгә көмеш йөгергән вакытта нинди буласыгызны тәфсилле фаразлаган 150 битлек «китап»ка ия буласыз. Үзеңнең генетикаңны ачыклау – киләчәктә үзеңне нәрсә көтәсен алдан белү һәм кисәтү чараларын күрә алу, дигән сүз ул.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

«АЛЬ-ВАРИС» трансфер факторлар тәкъдим итә торган 4LIFE; DAIGO (ЯПОНИЯ); AVICENNA КОМПАНИЯЛӘРЕНЕҢ РӘСМИ ВӘКИЛЕ БУЛЫП ТОРА, профессор Калинченко клиникасының «Омега-3» препаратын тәкъдим итә. Күп клиникалар «Аль-Варис»тан D3 витамины, «Омега-3» кебек актуаль препаратлар сатып ала..

– Сезнең өчен 2022 елның иң мөһим нәтиҗәләре нинди?

– Мин Халыкара картаюга каршы превентив медицина институтын тәмамладым һәм Казан медуниверситетыннан соң икенче югары белем алдым. Бу – белемнәрнең яңа баскычы, аңны киңәйтү. Невропатологтан остеопластика методына өйрәндем, ул әллә кайчангы физик имгәнүләрне дә дәвалап, күпьеллык сызлану-интегүләрдән котылу мөмкинлеген бирә. Ил буйлап та күп йөрдем: Дагыстан, Осетия, Владивосток... Мин шуны аңладым: безнең Россия, чыннан да, бик юмарт, искиткеч бай һәм төрле икән.

Быелтыр «Аль-Варис» клиникасы арсеналы да яңарды. Ике төрле заманча җиһаз пәйда булды: битнең матур озынча түгәрәклеген саклау өчен энәле «Морфеус-8» RF-аппараты һәм 4D-яшәртү өчен легендар FOTONA. 4D-яшәртүгә тиңдәшләр юк – күз янындагы мускулларга авыз куышлыгының лайлалы тышчасы аша тәэсир ителәә. Бу бик сак, тире катлавына зыян китермичә эшләнә.

– Ә биткә күләмне кайтару нәрсә ул?

– Өлкәнәйгән саен йөз яссылана бара: яңак мускуллары салына, бит алмалары югала, өске һәм аскы казналыклар «күчә». Яңа методлар битне модельләштерүгә, аның күләмен, озынчалыгын торгызуга юнәлтелгән. Филлерларсыз гына! Остеопластика әле йөзнең симметриясен торгызуга да булыша.

– Үзеңнең сәламәтлегең һәм матурлыгыңны ни өчен нәкъ менә «Аль-Варис» клиникасына ышанып тапшырырга була?

– Без җавап бирә торган төп сорау: образның бөтенлегенә ничек ирешергә? Бик күп башка косметологлар кебек, мин битне матурайту һәм тирене яшәртү белән генә шөгыльләнмим, чөнки үзеңне яшь итеп тою өчен бу гына җитми. Безгә төз гәүдә, зифа силуэт, тигез-туры арка, горур чөелгән баш, ышанычлы караш та кирәк.

Без һәрвакыт физик сәламәтлектән башлыйбыз. Пациент анализлар бирә, без аларны бәяләп, витаминнар һәм минераль матдәләр кытлыгын бетерәбез.

Моннан тыш, клиникада аппаратлы яшәртү өчен өр-яңа җиһазлар куелган, аларның күпчелеге Казанда бер бездә генә бар. Өченчесе – безнең клиника медицина лицензиясенә ия, тәҗрибәле белгечләр исә һәркемгә бик игътибарлы.

Тагын шунысы да мөһим: клиникада бик уңайлы, якты, матур. Пациентлар билгеләнгән вакыттан алданрак килеп утыра, соңыннан да китәргә ашыкмый.

– Сезнең клиентларыгыз кем?

– Безнең пациентларыбыз – зыялы, затлы, әдәпле. Алар белән төрле темаларга рәхәтләнеп сөйләшеп була. Инде 10 елдан артык һәм хәтта 20 ел йөрүчеләр дә бар.

– Шундый җаваплы эштә ирегез һәм улыгыз турында кайгыртуга вакыт каламы?

– Мин үземнең эшемә яраткан шөгылем, иҗатым итеп карыйм. Син «киеренке хезмәт куймыйча» иҗат итәсең икән, бөтенләй башка төрле энергетика хасил була. Шул вакытта әлеге ике өлкәне гармонияле итеп берләштерү бик җиңел. Яраткан ирем белән без инде 18 ел бергә. Ул минем бөтен идеяләремне хуплый, клиниканы да бергә ачкан идек. Мин хисле, башымда туган фикерләремне тизрәк тормышка ашырырга ашыгам, ирем исә мине җиргә төшерә, азагына кадәр уйлап бетерә. Шунлыктан без бер-беребезне тулыландырып торабыз.

– Хатын-кыз үзенең матурлыгын кайгыртканда һәм образ тудырганда нинди хаталар ясый?

– Үзенең беркемне дә кабатламавын, бердәнбер булуын оныта. Миңа кызларның яңак сөяген төзәтү яки ботокс ярдәмендә иреннәрен күпертүне сорап мөрәҗәгать иткәннәре булды. Әмма бу очракта алар бер-берсенә охшашка әйләнә бит. Икенчедән, күп хатын-кызга үзенең матурлыгы турында системалы кайгырту җитми. Мәсәлән, әле яшь кенә ханымның күз тирәсендә җыерчыклар барлыкка килүен күрәм. Сораштыргач, күзендәге макияжны сөртү өчен махсус косметика алырга иренеп, тиресен юыну өчен гель белән чистартуы ачыклана. Физик эшнең җитмәве, аз хәрәкәтләнү дә сәламәтлеккә начар йогынты ясый.

– Картаюга каршы чаралар кулланганда, нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Күзәнәкләр билгеле бер санда гына бүленергә программалаштырылган, һәм уйланмаган процедуралар ярдәмендә, киресенчә, картаюны тизләтергә дә мөмкин. Шунлыктан мин тирегә бик сак тәэсир итү яклы һәм берничә елга сузылган курска исәп тотам. Нәтиҗәдә без сәламәт, чиста тиреле булабыз, аның өчен тональ крем һәм декоратив косметика кирәкми дә диярлек.

Сөйкемлелектән балкып торган сәламәт тире, җиңел атлап йөрү, төз буй-сын һәм горур чөелгән баш теләсә кайчан һәм теләсә нинди хәлдә дә ышаныч хисе тудыра ала.

«Аль-Варис» медицина косметологиясе һәм трихологиясе клиникасы, Казан шәһәре, Сибгат Хәким урамы, 41 нче йорт, **тел. +7 (902) 719-77-99**

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Лилия Муллахмәтова фотосы. РЕКЛАМА



ТӘВӘККӘЛЛӘСӘҢ – БУЛА!

Фото: Александр Сафронов. РЕКЛАМА

Таныш булыгыз, Ольга Глухова, Казандагы танылган VIVAT реклама агентлыгы хуҗасы. Рекламада эш тәҗрибәсе – егерме елдан артык. Германия, Кытай, АКШ, Япония һәм башка илләрнең абруйлы реклама агентлыкларында өйрәнү үткән, бизнес-сәяхәтләр турында китап авторы. Бүгенге катлаулы заманда уңышка ирешү серләре хакында Ольга «Татарстан» журналы укучыларына ихлас һәм үзенчәлекле итеп шәхсән үзе сөйләргә булды.

Беренче адым.

Әлеге тәүге адымның кая илтеп җиткерәсен без һәрвакыт беләбезме соң? Ул кая юнәлгән?

Тормышта да, бизнеста да. Беренче адымны ясау зарур. Нәрсә дә булса һичшиксез үзгәрәчәк.

Син ахырына кадәр аңлап та бетермисең әле – нәрсә һәм күпмегә үзгәрәчәк соң? Барысын да алдан ук исәпләп һәм фаразлап куйсаң да, нәрсәдер барыбер башкачарак килеп чыгачак.

Минем VIVAT турында. Мин дөньяда бик кәттә реклама агентлыклары булуын белә идем. Әмма мин алар турында йә кайдандыр ишеттем, йә кайдадыр укыдым.

Әллә никадәр укырга була, әмма үзеңә шулар янына барырга нәрсә комачаулый соң? Иңиңнәрдән өйрәнүгә ни җитә бит!

Сез, бу мөмкин түгел, дип уйлыйсызмы?

Мин соңгы 7 елда 12 илдә булдым һәм дөньядагы 150 дән артык иң шәп реклама агентлыгында өйрәнү үттем.

Бу минем үземне бәяләвемне дә, белемемне дә арттырды.

Бу минем агентлыгымны Татарстанда иң яхшылардан берсенә әйләндерде.

Бу хәзер бигрәк тә мөһим. Дөрес карар кабул итеп, илдән китмәү. Бөтен бюджетлар тупланган Мәскәүгә китмәү.

Без Татарстанда калабыз һәм биредә, үзебездә, федераль агентлык төзибез.

Без үз белем-тәҗрибәбез белән уртаклашабыз һәм үзебезнең Татарстан җитештерүчеләре һәм компанияләренә булышабыз.

Сүз уңаеннан, шәхси брендым турында.

Мин китапларны әллә кемнәр түгел, гади кешеләр язуын белә идем, әлбәттә. Мәктәптә рус теле һәм әдәбиятыннан сәләтсез укытучыда уку исә эпистоляр жанрга булган бөтен мәхәббәтемне юкка чыгарды.

Әмма!

Чит илләрдә тәҗрибә уртаклашканда мин һәрвакыт үземнең тәэсирләремне, фикерләремне, төрле файдалы киңәшләрне язып бардым. Бу исә китап язуга беренче адымым булган икән... Мин боларны бернәрсәне дә онытмас өчен, үзем өчен генә язган идем. Көннәрдән бер көнне минем өчен бик абруйлы кеше: «Оля. Китап яз. Синең хәлеңнән килә бу. Бизнеста яңа үрләр яуларга да булышачак», – диде.

Мин үз язмаларымны яңабаштан укып чыктым. Рәхәтләнеп китап яздым һәм бастырдым. Бу минем бизнес-сәяхәтләрем турында китап. Аны ЛитРес нәшрияты бастырды. Минем китабым дөньядагы иң зур реклама агентлыклары хуҗаларына бүләк ителгән. Коллегаларыма. VIVAT клиентларына.

Һәм һәрвакыт соклану тудыра. Мин аны бик рәхәтләнеп бүләк итәм һәм кемдер автограф сорагында бик оялам. «Укучыга ошармы, юкмы?» – дип дулкынланам. Бу – һәр авторга хас сыйфат. Дәвамын язу хакында хыялланам.

Казанда 2015 елда су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты узды. Без анда эшләдек, иганәчеләрне рекламаладык.

Шуннан соң дүрт ел үткәч, мин бассейнга йөзәргә йөри башладым.

Әмма бусы да беренче адым булган икән! Нибары 10 ай шөгыльләнгәннән соң, Кореяда узган дөнья чемпионатында «Мастерс» категориясендә катнашырмын дип уйлап та карамаган идем!

Иң авыры нәрсә?

Беренче адымны ясау авыр түгел. Еш кына ни белән төгәлләнәчәген дә аңламыйча тәвәккәллисең. Аннары исә үзенә бертөрле дәрт, кыюлык өстәлә.

Дөнья чемпионатында катнашуга тренер фатыйха бирә. Аннары стресс, курку, үз-үзеңә ышанмау стадиясе башлана. Дулкынланасың. Шикләнәсең. Шүрлисең. Әмма стартка килеп басасың. Һәм шул чакта көч-куәт пәйда була.

Кичә генә дөньяның иң көчле йөзүчеләре ярышкан бассейндагы әлеге 50 метр ара синең яңа җиңүеңә әйләнә. Мин көчле көндәшләрем арасында бишенче булып килдем.

Бу стрессмы? Әйе. Әмма стресс – синең дошманың түгел! Ул синең дустың! Стресс вакытында син бөтен көчеңне туплыйсың, баш миең дистәләрчә тапкыр яхшырак эшли, һәм син искиткеч зур казанышларга ирешә аласың.

Әлеге тәүге адымның кая илтеп җиткерәсен син һәрвакыт беләсеңме соң? Тик син аны ясамасаң, бернәрсә дә булмаячак.

Беренче адым синдә һичшиксез ниндидер очкын кабызачак.

Шуңа да үзеңнең тәүге адымыңның кадерен белергә өйрәнү мөһим.

КМТТУ – КАИ университетының Икътисадый теория һәм ресурслар белән идарә итү кафедрасы программаларында белем алуга бәйле сорауларны **GGMustafina@kai.ru** адресына җибәрергә мөмкин.

КИЛӘЧӘК ЛИДЕРЫ ӨЧЕН РЕСУРС

Уңыш күп факторларга бәйле. Сыйфатлы белем – аларның иң мөһимнәреннән. Студентларын әнә шундый өстенлек белән тәэмин итү өчен, КМТТУ - КАИ үз эшчәнлеген даими камилләштерә.

– Безнең кафедрага 77 яшь, һәм бу – цифрлаштыру һәм универсальлек чорына аяк басу өчен менә дигән вакыт, әлеге чорда төрле фәнара багланышлар, кырыс күнекмәләр белән беррәттән йомшакларын да үстерү, тышкы тирәлек үзгәрешләренә тиз арада җайлаша һәм төрле форматтагы компанияләрдәге процесслар белән идарә итә белү беренче планга чыга, – ди Казан милли тикшеренү-техник университетының Икътисадый теория һәм ресурслар белән идарә итү кафедрасы җитәкчесе, икътисад фәннәре кандидаты, доцент, Татарстандагы эшкуар хатын-кызларның «ТРның эшлекле хатын-кызлары» бизнес-клубы әгъзасы Гөлнара Мостафина.

ҺӨНӘР БАКАЛАВРИАТТАН БАШЛАНА

– Хәзер базарга һәм предприятиеләргә шул тармакта да, икътисадта да белемнәре булган күп функцияле белгечләр бик кирәк. Икътисад юнәлешендәге «Сәнәгать коммерциясе» һәм «Инвестицион проектлау» бакалавр программалары һәм «Персонал белән идарә итү» юнәлеше әнә шул нигездә барлыкка килде, – дип аңлата Гөлнара Мостафина. – Студентлар практика узу урынын шактый зур исемлекне тәшкил иткән предприятиеләр арасыннан сайлый, ягъни алар үз белемнәрен һәм сәләтләрен мөмкин кадәр тирәнрәк кулланырлык база таба ала.

Кафедраның бакалавр программалары Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән абитуриентларны җәлеп итә. Четаев урамындагы заманча «Студент йорты» тулай торагы башка шәһәрләрдән килеп укучы студентларга уңайлы тормыш шартларын һәм шәһәр үзәгенә тиз арада барып җитүне тәэмин итәчәк. Тулай торак бик тиздән үз ишекләрен ачачак.

ДӨНЬЯКҮЛӘМ БИЗНЕСКА

Кытай белән хезмәттәшлекнең нинди юнәлешләрен үстерү аеруча өметле, ә Төркия белән? Россиянең иң зур чит ил партнерлары исемлегенә Нидерландлар ничек эләккән? Тышкы элемтәләрне үзгәртеп кору темасы бүген көн кадагында торганнарның берсен тәшкил итә. Димәк, яңа сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләр коруга һәм Россия компанияләрен ил эчендә һәм дөнья базарларында танытуга юнәлдерелгән проектларның берсендә үз урынын табар өчен, «Халыкара бизнес икътисады» юнәлеше магистрантларының бөтен мөмкинлекләре бар.

– Әлеге ике еллык программа бизнес һәм халыкара икътисадый мөнәсәбәтләр кушылмасыннан гыйбарәт. Ул эштә тиз арада үсү яки стартапны уңышлы эшләтеп җибәрү өчен кирәкле һәм җитәрлек барлык күнекмә-белемнәрне үзләштерергә омтылучылар өчен төзелгән, – ди Гөлнара Мостафина. – Дәресләрне иң яхшы укытучылар, шулай ук халыкара дәрәҗәдә танылган, шәхси үрнәкләре турында сөйләргә, бизнес-кейслары белән уртаклашырга әзер булган күренекле эшкуарлар алып бара.

ФӘН ҺӘМ ПРАКТИКА СИНТЕЗЫ

Кафедра төрле фәнни мәктәпләр – икътисад, хокук, персонал белән идарә итү һәм хезмәт психологиясе белгечләрен берләштерә. Булачак белгечләргә инде бүген үк кирәкле дисциплиналарны кертә барып, укытучыларыбыз трендлардан калышмый.

– Мондый синтез сыйфатлы белем продуктын булдыру өчен мөһим. Төрле фәнни алымнарны берләштереп, үз белгечлек дәрәҗәбезне күтәреп, без бакалавриат һәм магистратурадагы төп белем бирү программаларының юнәлешләрен киңәйттек, – дип ачыклык кертә Гөлнара Мостафина. – Югарыда искә алынганнардан тыш, без зур мәгълүматлар ярдәмендә бизнес-процессларны анализларга өйрәтә торган «HR: оештыручанлыкны үстерү һәм стратегик идарә» магистрлык программасын керттек. Хәзерге көндә бик кирәкле «Электрон сәүдә һәм интернет-маркетинг» һәм башка магистрлык программалары әзерләнә. Киләчәктә үзләренә көндәшлеккә сәләтлелекне тәэмин итәчәк перспективалы белем алырга теләгән бакалавр һәм белгечләрне әлеге программаларны үзләштерергә көтеп калабыз!

Фото: kai.ru. РЕКЛАМА

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+

«Татарстан» журналының махсус проекты

КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА...

**Кайвакыт язмыш кешегә бик зур сынаулар әзерләп куя.
Бик куркыныч югалтуларга юлыктыра.
Ирегеңне югалту.
Сәламәтлегеңне югалту.
Хәрәкәт итү сәләтеңне югалту.
Өеңне югалту.
Мәхәббәтеңне югалту.
Бик якын кешеләреңне югалту.
Кешеләргә, тормышка ышанычыңны югалту.
Мондый кайгы-хәсрәт бездән эчкече дә, хыянәтче дә, үч алучы да, үтерүче дә, хәтта үз-үзеңә кул салучы да ясарга сәләтле. Мондый мизгелләрдә дөнья җимерелә һәм тирә-юнебез караңгылана. Без, көчсезрәк, рәхимсезрәккә яисә, киресенчә, көчлерәккә әйләнеп, бөтенләй үзгәрәбез...
«Ачы югалтуларга, өметсезлек һәм газапларга карамастан, иң мөһиме – Кеше булып кала алу», – диләр геройларыбыз.**

**Андый кешеләр хәзер дә бар. Алар безнең янәшәбездә, күршебездә генә яши.
Язмаларыбыз җиңүчеләр,
сынмаган-сыгылмаган,
явызланмыйча,
көчле, шәфкатьле,
чын Кеше булып кала алганнар турында.**

Фото: tatar-inform.ru, «Татарстан» журналы, геройларның шәхси архивларыннан

Фото Лусине Маргарян архивыннан

ЛУСИНЕ МАРГАРЯН
ҺӘМ ЯМАН ЧИРЛЕ ХАНЫМНАР ӨЧЕН МАТУР КАШЛАР

Мария Ермакова

– Үзендә онкология булуын белгән хатын-кызда каш ясату кайгысы калмый инде, – ди Яр Чаллыдан перманент макияж остасы Лусине Маргарян. Шулай булса да, иманы камил: химия терапиясе вакытында үзеңне көзгедән матур итеп күрү мөһим.

Химия алганда чәч, каш һәм керфекләре коелган онкологияле хатын-кызның көзге каршында ни кичергәнен Лусине яхшы белә. Рак һәм химия терапиясен үз башыннан үткәргәч, Лусине яман шештән интегүче хатын-кызларга үзләрен матур итеп тоярга булышырга карар кыла.

ЯРТЫ ЕЛГА СУЗЫЛГАН ХӘЛСЕЗЛЕК

– Минем язмышым да, мөгаен, бу бәлагә тарыган күпчелек хатын-кызларныкы кебек үктер: мин күкрәгемдә төер булуын очраклы гына белеп алдым. Моңа кадәр бер тапкыр да тикшеренгәнем юк иде. Үземне сәламәткә санап йөрдем һәм тәнемдә яман шеш пәйда булу ихтималын башыма да китермәдем. Әмма 2020 елда барысы да үзгәрде. Табиблар киста дип уйлаган нәрсәне операция ясап алгач, аның яман шеш булуы ачыкланды. Һәм шуннан башланды инде: операция, химия терапиясе, нур терапиясе...

Яман шеш турында ишеткәч, башта ышанмадым: анализ нәтиҗәләрен кабат-кабат тикшерттем. Ул чакта мин бу чирнең үлемгә китерәчәген генә белә идем. Әмма, тормыш күрсәткәнчә, моннан 10, 20 ел элек авырый башлаган бик күп кеше хәзергә кадәр яши икән. Чир башланган вакытында ук ачыкланса, тулысынча савыгып була.

Дәвалану барышында организмым шактый үзгәреш кичерде. Химия терапиясе файда гына түгел, зыян да китерә бит. Бик тиз картаясың кебек. Бу бик катлаулы, авыр дәвалану. Мин химия терапиясенең сигез курсын үттем – бу ярты елга диярлек сузылды. Ярты ел буена даими хәлсезлек халәтендә булырга туры килде.

КАШСЫЗ, КЕРФЕКСЕЗ, ЧӘЧСЕЗ...

Онкология диспансерын мин күз яше һәм хәсрәт тулы шомлы урын дип күз алдына китергән идем. Әмма бу бөтенләй алай булып чыкмады. Хатын-кызлар кәефсезләнмәскә, сабыр булырга тырышты. Операциядән соң Казанда ятканда палатада сигезәү идек. Кемнеңдер беренче стадия, кемнеңдер хәле начаррак – өченче стадия. Һәм барыбыз да терелүгә өметләнәбез. Ул өмет тулы күзләрне мин хәзергә кадәр хәтерлим әле.

Минем белән ятучылар химия терапиясе курсын башлаган иде инде. Барысы да кашсыз, керфексез, чәчсез. Үзләрендә булган үзгәрешләрне ничек авыр кабул итүләрен мин күреп тордым. Чәчсез калгач, парик киеп була, ә менә кашсыз нишләргә? Шул эшнең остасы булмасаң, үз битеңә каш ясап кую шактый катлаулы бит. **Мин шул вакытта яман чирдән интегүчеләргә бушлай каш ясарга карар кылдым. Палатадашларымның барысын да үземнең янга – Чаллыга, перманент макияж ясатырга чакырдым.**

ИРТӘРӘК ЯСАТСАҢ, ЯХШЫРАК

Үзендә онкология булуын белеп алган хатын-кызда каш ясату кайгысы калмый инде. Әмма химия терапиясе вакытында бөтен чәче коелып, үзен көзгедә күргәч, ул перманент ясатмаганына үкенәчәк. Тик инде химия вакытында соң булачак – иммунитет зәгыйфьләнә һәм тире озак төзәлми бит. **Шунлыктан хатын-кыз алдан ук химия терапиясенә әзерләнсен өчен, мин бу процедураны бушлай ясыйм.**

БЕР-БЕРЕБЕЗГӘ ТЕРӘК БЕЗ...

Күптән түгел минем яныма каш ясатырга өлкән яшьтәге бер ханым килгән иде. Химия терапиясе курсы башлангач, ул миңа шалтыратты. Көзгегә карагач, сөенүен әйтте. **Һәм мондый рәхмәт сүзләре ишетү минем күңелемә искиткеч рәхәтлек бирә.**

Мин күп кеше белән язышып торам: үзем каш ясаганнар белән дә, хастаханәдә бергә яткан кызлар белән дә. Без бер-беребезгә терәк булырга тиеш. Мин хәлкадәри һәркемгә булышырга тырышам. Кайвакыт юату сүзләре ишетү дә бик мөһим бит.

Яныма килгән һәр хатын-кызның язмышы күңелләрне кузгатырлык. Нигездә бу – яшь әниләр яки тормышка яңа гына аяк басучы яшь кызлар. Аларга матур булып калу һәм алга таба да яшәү өчен көч табу аеручы мөһим.

МӘРХӘМӘТ ЧАТКЫСЫ

Дөресен әйтим, баштарак мин мондый процедурага ихтыяҗ юктыр, дип уйлаган идем. Әмма Чаллыда яман чирдән интегүче хатын-кызларның никадәр күп икәнен күргәч һәм үзем дә аларның берсенә әйләнгәч, мин мондый хезмәтнең никадәр әһәмиятле булуын аңладым.

Мондый акцияләр оештырганда хатын-кызда аның өчен бик авыр чорда мәрхәмәт, өмет чаткысы кабына, дип уйлыйм. Сирәк кенә булса да, мине дә яхшы сүз белән искә төшерерләр...

Фото Наталья Бикчурина архивыннан

НАТАЛЬЯ БИКЧУРИНА: УЛЫМНЫ АЯККА БАСТЫРДЫМ

Анастасия Маркелова

Көтмәгәндә бәла-каза килгәндә, аяз көнне яшен суккандай булды, диләр. 2015 елның 3 октябрендә Наталья Бикчурина гаиләсендә зур фаҗига була: улы Артём коточкыч юл һәлакәтенә эләгә.

– Мин моны ничек кичердемме? Сүз белән тасвирлап булмый. Улымны хастаханәдә күргәч, дөньяның асты-өскә килде: битендә бик күп җәрәхәт, күз чокыры һәм казналыгы биш җирдән сынган, маңгай сөяге бөтенләй юк, тешләре коелган, сул боты чыккан һәм умрау сөяге сынган... Үз балаңны мондый халәттә күрүдән дә куркынычрак әйбер юктыр ул.

ИМАНЫМ ГЫНА КӨЧ БИРДЕ

Икенче көннән үк мин чиркәүгә гыйбадәткә йөри башладым, реанимациягә, дога укысын өчен, батюшканы чакырдым. Мине бары тик иманым һәм чиркәү генә тынычландыра, шул гына көч бирә иде.

Булган хәлдә гаепләләрне эзләмәдем. Дөресен әйткәндә, минем бу турыда уйларга вакытым булмады, улымны аякка бастырырга кирәк иде.

КОМА

Артём өч ай ярым Казанда реанимациядә ятты, аннары безне, монда болай ятуның мәгънәсе юк дип, өйгә җибәрергә булдылар. Мин бик каты үтенгәч, тагын берничә айга калдырдылар. Фаразлар бер дә юатырлык түгел иде: «Күп дигәндә ярты ел яшәячәк, исән калса да, беркайчан сөйләшмәячәк һәм йөрмәячәк», – диде табиблар.

МИНИМАЛЬ АҢ ХАЛӘТЕ

Мин, күп эзли торгач, Барселонадагы Гуттманн институтын таптым, бу – баш миен терһәкләндерү буенча бөтен дөньяга танылган клиника. Аларга бөтен документларны җибәрдем. Бу вакытта Артём минималь аң халәтенә күчкән иде инде. Дусларым тиз арада акча җыярга ярдәм итте. Аларның һәм битараф булмаган тагын бик күпләрнең ярдәме белән без реабилитация юлын башладык һәм хәзергә кадәр дәвам итәбез.

ХАСТАХАНӘ ИНФЕКЦИЯСЕ

Испаниядә улымның үпкәсендә хастаханә инфекциясен таптылар, ул бик озак дәваланды – ел ярымга якын антибиотик кабул итәргә туры килде. Икенче клиникада трахеостоманы (аны авариядән соң ук ясалма сулыш алуны тәэмин итү өчен урнаштырганнар иде) томалый алгач кына, инфекция куркынычсызга әйләнде.

ҖИДЕ ЕЛГА СУЗЫЛГАН ТЕРНӘКЛӘНҮ

Авариядән соң ел ярым вакыт узгач, Артём сөйләшә башлады.

Җиде ел эчендә без бик катлаулы берничә операция кичердек. Һәм искиткеч нәтиҗәләргә ирештек: хәзер Артём шаяртта, җырлый, берничә (рус, татар, инглиз, испан) телдә сөйләшә. Үзенең һәлакәткә кадәрге гомерен исенә төшерде, хәзер кыска вакытлы хәтергә кагылышлы вак-төяк проблемалар гына калды.

МАКСАТЫБЫЗ – ТУЛЫСЫНЧА САВЫГУ

Бернәрсәгә дә карамыйча, без алга баруыбызны дәвам итәбез һәм тагын да зуррак уңышларга ирешергә телибез, мәсәлән, йөрергә өйрәнергә өметләнәбез. Бүгенге көндә Артём култык таяклары белән үзе генә дә йөри ала инде. Баланс, тигезлек саклау өстендә эшлибез, нейротерапевт, логопед, массаж ясаучы, психолог белән шөгыльләнәбез.

Максатыбыз – тулысынча савыгу.

Киләчәгебезне без менә болайрак күзаллыйбыз: Артём сау-сәламәт, аның хатыны, балалары, үз эше бар, мин исә – бәхетле әби!

МӨМКИН БУЛМАГАН НӘРСӘ ЮК

Безнекеннән дә аянычрак хәлләр буладырмы-юкмы, әйтә алмыйм. Ни генә булмасын, иң мөһиме – паникага һәм төшенкелеккә бирелмәү, күңелен кушканча эшләү һәм гыйбадәт кылу.

Бу бик катлаулы юл, әмма мөмкин булмаган бернәрсә дә юк, мин моңа көннән-көн инана барам. Максатны төгәл күрә белү һәм аңа барганда бернинди киртәләрдән дә курыкмау мөһим.

Һәм тагын: үзеңә ышанырга, кешеләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәк. Бары тик игелек-шәфкать кенә бөтен нәрсәне дә җиңәргә сәләтле!

Артём Бикчуринга ярдәм итү өчен элемтә:
https://vk.com/id201671194
https://taplink.cc/artembikchurin_help?fbclid=PAAaYzi80ChVF8LpcJMLIHdtKbuGd1zqMrYYc1AKcLwAnwudZ9aOYmqm3Ece4

АВЫРУГА ЯШӘҮ ХОКУКЫ КАЛДЫРМАУ

Диләрә Сафиуллина

Чирне дәвалауга караганда, кисәтү җиңелрәк, дигән сүзләр яңалык түгел. Яңалык шунда: профилактика медицинасы кешене киләчәктә пәйда булачак авырулардан саклап кала алмый диярлек.
– Моңа превентив медицина сәләтле, – ди табиб-превентолог, «Лениногорск» шифаханәсенең туклану гигиенасы буенча белгече Резеда Журавлёва.



КЕШЕ – ҮЗЕ БЕР ГАЛӘМ

Кеше – үзе бер галәм, ди шагыйрьләр. Сүз авыруларны кисәтү турында барганда табиблар да шул фикердә. Сәламәтлекне саклау күзлегеннән караганда шунысы ачык: һәркемгә бертөрле киңәш – күп ашамаска, рационга файдалы ризыкларны кертергә, күбрәк хәрәкәт итәргә, йокы гигиенасын үтәргә һәм стресска каршы көрәшергә кебек «коллектив» алым җитәрлек дәрәҗәдә эшләми. Югыйсә статистика алай ук куркыныч булмас иде – 2001–2021 елларда кадәр Татарстанда онкологик авырулар статусы алган кешеләр саны – ике тапкыр, шикәр авыруы диагнозы белән өч тапкырга арткан. Йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлүчеләр саны арта бара.

Һәр организмның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, стандарт күрсәтмәләрне алыштырыр вакыт җитте. Бу медицина юнәлеше «превентология» дип атала.

ОРГАНИЗМНЫ «РЕМОНТЛАУ» ХӘЛЕНӘ ҖИТКЕРМӘГЕЗ

Әлбәттә, бер җире дә авыртмаган кешенең кинәт табиб янына баруын күз алдына китерүе кыен. Чөнки безнең аңда табиб авыруны дәвалый дигән аксиома ныклап урнашкан. Тик инде барлыкка килгән авыруны дәвалау – ремонт, дип саный Резеда Журавлёва. Сүз, мәсәлән, сынулар, инфекция турында барганда мондый алым үзен аклый. Калган күпчелек саналган очракларда ремонт организмны эш халәтендә тотарга гына ярдәм итә, ул авыруны китереп чыгарган сәбәпләрне бетерми. Ә врач-превентолог нәкъ менә авыру килеп чыгуга юл куймау, ягъни аңа яшәү хокукы бирмәү белән шөгыльләнә.

Фото Резеда Журавлёваның гаилә архивыннан

АВЫРУ КУРКЫНЫЧЫН АЧЫКЛАУ

Ни өчен моны традицион медицина эшли алмый? Бер кешене кабул итү өчен табибка 10 минуттан бераз күбрәк вакыт бирелүдә генә дә түгел. Кай җирең авыртканны сорарга, картаны тутырырга өлгерергә дә кирәк... Эш шунда ки, киләчәктә авыру башланачак күзәнәкләрдәге патологик үзгәрешләрне стандарт тикшеренү ысуллары – УЗИ, рентген, ЭКГ, КТ, ФГДС һәм башкалар ярдәмендә «күреп» булмый. Лаборатор тикшеренүләр күпмедер мәгълүмат бирергә сәләтле. Әмма кеше галәменә бары тик махсус тикшерүләр ярдәмендә генә күз салырга була, алар тормышыбызны бозачак авыруга әйләнгәнче үк организмдагы үзгәрешләрне ачыклый. Һәм сүз хәзер модада булган һәм кешегә геннар буенча бирелгән авыруларны (сүз уңаеннан, аларны гаиләнең өлкән вәкилләренең нинди авыру кичерүен анализлап фаразлау җиңел) күрсәткән генетик-молекуляр тест турында бармый. Сүз организмның май кислоталары арасындагы баланс кебек мөһим компоненты аша теге яки бу авыруның килеп чыгу куркынычын ачыклау мөмкинлеге турында бара.

БАЛАНСНЫ САКЛАГЫЗ!

Мөгаен, омега-3 һәм омега-6 май кислоталарының файдасы турында ишетмәгән кеше юктыр. Организм икесенә дә мохтаҗ – ләкин бер-берсе белән катгый балансто! Хәзерге кешенең диетасында омега-6 кислотасы өстенлек итә, чөнки һәркемнең өстәлендә ким дигәндә чистартылган көнбагыш мае кергән продуктлар бар. Шул ук вакытта алар арасындагы балансның омега-6 ягына авышуы организмда ялкынсыну мөмкинлеге көткән бар нәрсәне эшләтеп җибәрәчәк! Омега-6 ның ялкынсындыру факторы шундый көчле!

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ АГАРТУ

Бик җиңел кебек! Омега-6 куллануны киметү һәм омега-3 не арттыру! Ләкин шунысы бар: сез әллә никадәр күләмдә сардина һәм скумбрия балыгы (омега-3 нең күплеге буенча рекордсменнар) ашый аласыз, тик, кызганычка каршы, ашаган бөтен әйбер диярлек юкка гына булачак, чөнки инде май-кислота дисбалансыннан интегүче күзәнәкләр файдалы матдәләрне үзләштерә алмый. Аларга омега-3 кә генә түгел, ә витаминнар, минераллар, БАД ларга да тиешле дәрәҗәдә үтеп керергә ирек бирми торган йозак элеп куелган кебек – кышку инфекцияләр чорында авырулардан саклану өмете белән без үзебезне юмарт сыйлыйбыз.

Бу дисбалансны ничек бетерергә һәм, «авыру» һәм «картлык» сүзләре үткәннәрнең калдыгыдай истә калсын өчен, организмдагы биологик процесслар белән идарә итәргә өйрәнергә? Милләтне савыктыру дәүләтнең өстенлекле эш юнәлешенә әйләнмәгән очракта, бердәнбер юл – кешенең (һәм аеруча баланың сәламәтлеге өчен җаваплы ата-ананың) үз-үзен агартуы һәм туклануга карата аңлы карашы, дип саный табиб-превентологлар.

> БӨТЕНДӨНЬЯ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ОЕШМАСЫ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ БУЕНЧА ОМЕГА-6 ҺӘМ ОМЕГА-3 АРАСЫНДА НОРМАЛЬ НИСБӘТ – 4:1 КҮРСӘТКЕЧЕ. ЕВРОПАДА БУ КҮРСӘТКЕЧЛӘР – 15:1, АКШТА – 23:1, Ә ТАТАРСТАНДА – 25:1! АЛЛЕРГИЯЛЕ БАЛАЛАР, СПОРТЧЫЛАР, ВЕГЕТАРИАННАР ҺӘМ ХРОНИК АВЫРУЛАРЫ БУЛГАН КЕШЕЛӘР КУРКЫНЫЧ ТӨРКЕМДӘ!

ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ ПОЛИГОН ОЕШТЫРУ

Резеда Журавлёваның киләчәккә планнарында – сәламәтлек саклауның превентив ысулларын исбатлау максатында медицина учреждениесе базасында экспериментал полигон оештыру. Әмма бу озын һәм сикәлтәле юл. Гаделлеге, сатылмавы аркасында башына «очраклы рәвештә» кирпеч төшү мөмкинлеге турында кисәткән сәүдәгәрләр белән 90 нчы елларда санитар табибы булып эшләү тәҗрибәсе аның өчен чыныгу мәктәбе була, шуңа күрә Резеда Журавлёва үзе сайлаган юлдан тайпылмаячагына ышана.

– Үз кулларыбыз белән үсеп килүче буынның сәламәтлеген бетерүебез белән мин берничек тә килешә алмыйм! – ди Резеда, үз эшчәнлегенең иң мөһим аспектына – балалар сәламәтлеген саклауга басым ясап.

ТУКЛАНУНЫ КӨЙЛӘГЕЗ

Бүген үк инновацион эшләнмәләрне гамәлгә кертү өчен, шулай ук төрле белгечлек табиблары белән методик эш алып барыла. Превентолог кабинеты әлегә һәр поликлиникада ачылмаган, шуңа күрә Резеда Журавлёва түбәндәгене истә тотарга чакыра: генетикабыз, яшәү рәвешебез яки экологик вазгыять аркасында булган проблемаларыбызны туклануны дөресләү ярдәмендә 80 процентка кисәтә алабыз.

Менә превентологтан берничә киңәш. Бу һәркемгә авыруларга һәм картлыкка ышанычлы киртә куярга мөмкинлек бирә:

- ТӘМЛӘТКЕЧЛӘР КУЛЛАНЫГЫЗ (аеруча тимьян һәм орегано) – алар май кислотасы дисбалансының катастрофик нәтиҗәләрен киметә.
- ЭТИКЕТКАЛАРНЫ ӨЙРӘНЕГЕЗ – продукт составында «кондитер мае», «гидрогенизированный», «спред», «эквивалент» яки «алмаштыргыч» сүзләре булса, аны киштәдә калдырыгыз.
- ЧИСТАРТЫЛГАН ҮСЕМЛЕК МАЕН – ЗӘЙТҮН ҺӘМ ЭРЕТЕЛГӘН АТЛАН-МАЙ, ә ашлык белән туклындырылган сыер итен һәм сөтен болында көтелү бәхете тәтегән мал продукциясенә алыштырыгыз.
- Ә иң мөһиме – авыруны башлангыч халәттә тотарга һәм аңа проблемага әйләнергә юл куймаска мөмкинлек бирә торган заманча ДИАГНОСТИКА АЛЫМНАРЫ БЕЛӘН КОРАЛЛАНГАН ТАБИБНЫ ТАБЫГЫЗ.

һөнәрле хурлымас

СЕЛТЕ СУЫНДА... КЕР ЮАБЫЗ!

Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне барлауны дәвам итә. Бу юлы селте суында кер юдык.

Биектау районының Дөбъяз авылында яшәүче Гөлсем апа Адаева безгә бу эштә ярдәм итте. Чоланыннан кер юу тактасы алып кереп, селте суын әзерләп куйган иде. Соңыннан, рәвешенә туры китереп, юылган керләрне чайкарга чишмә буена да төштек. Егерме градус салкында, тешне сындырырлык чишмә суына кулыңны тыгып, кер чайкап кара әле! «Берьюлы шулай өчәр, дүртәр чиләк кер юганнар бит», – дип сөйләшә-сөйләшә, элеккеге хатын-кызларны кызганыштык.

Фото: Илнар Өметбаев

«БАШ ЮАРГА, КЕР ЮАРГА ДА ЯРЫЙ»

Кер юу. Бүген без аны гомумән эшкә санамыйбыз. Ә нәрсә, автомат машинага кернәрне тутырасың да ике тапкыр төймәгә басасың. Эшен бетергәч, машина үзе хәбәр сала. Җан рәхәте, билләһи. Хәтта хәзер керне киптереп утырасы да юк, шундый машиналар да чыкты. Юкка гына әбиләр, бүгенге яшәү рәвешебезне күреп: «Җәннәттә яшибез», – дими шул.

– Кер юу ул элек олы бер эш иде, – дип сөйләде безгә Дөбъяз авылының үткен, абруйлы әбисе Гөлсем апа. – Башта бер атна алдан селте суы ясап куясың. Аннары аны махсус иләк аша сөзеп, икенче савытка агызасың. Шул рәвешле көле иләктә кала. Тонгач исә селте суы кер юарга да, баш юарга да ярый. Ул чагында бит бөтен кеше басуда эшли, киемнәр пычранып бетә. Ә селте суы керне агарта.

– Селте суы белән баш та юдыгызмы? – дибез, аптырашып.

– Әйе, баш юарга бик әйбәт ул. Чәчне йомшарта да, матурлата да.

– Кер юар өчен сабыннар булгандыр бит? – дибез.

– Бар иде. 1950-1960 нчы елларда кибетләргә кайтты инде ул. Чиста киемнәрне сабын белән юасың. Ә селте суын пычраграк керләрне агарту өчен кулландык.

Гөлсем апага 88 яшь. Башта аптырап та калган идем, аннан 60 яшендәге кызын күргәч тә аңлашылды: нәселләре шундый икән – яшь күренәләр. Әбекәй мәрхүм ире белән өч бала – ике кыз, бер малай үстергән. Игезәк кызлар бүген әниләре янында Дөбьязда яши. Ә төпчек улы гаиләсе белән Казанда гомер итә икән.

– Әле кызымның берсе Казанга – оныкны карашырга китте, – диде Гөлсем апа. – Гөлсинәм исә янымда тора. Лаеклы ялга чыкканчы Казанда яшәде ул, заводта бухгалтер булып эшләде. Без барыбыз да математика белән бик тату. Телдән дә яхшы исәплибез. Сигез класс тәмамлагач, Бөгелмәгә укырга киттем. Ике елдан соң кайтып, Дөбъяз райпосына ревизор булып эшкә кердем. Яшь дип тормадылар, алдылар. 1955 ел иде ул. Ул чагында Дөбъяз район үзәге бит. Безнең районга 101 авыл керә иде. Менә мин шул авылларның барысын да йөреп чыктым. Ревизорлар сәүдә өлкәсен гел карап, тикшереп торды. Кибет киштәләрендә һәрвакыт сабын, керосин, шырпы, тоз булырга тиеш иде. Баргач та иң беренче шуларны карыйсың. Бер авылдан икенчесенә җәяү йөреп, шактый еллар эшләдем. Кешеләрдә кунып калган чаклар да булды, бигрәк тә кыш көннәре кайтырга авыр иде. Аннары исә РОНОда бухгалтер булып эшләдем.

1993 елдан башлап, Гөлсем апа авылның ветераннар советын җитәкли. Әле бу вазыйфадан киткәненә ике генә ел икән. Мәдәният йорты сәхнәсендә дә гел беренче: җырлаган, сөйләгән, әле дә шулай. Әбекәй бүген дә җәмәгать эшендә – авыл мәчетенең исәп-хисап эшләрен алып бара, мәчеткә җыелган сәдака акчалары аңарда саклана. Авылдашлары каршында абруе зур.

КЕР ЮУ ТАКТАСЫ, СЫРЛЫ БӘЛӘК...

Кер юу тактасына әйләнеп кайтыйк. Әле урта буын хәтерлидер: һәр йортта булган җиһаз ул. Аны зур тагаракка куеп, керне яхшылап ышкыйсың.

– Кер юа торган агач тактаны әти үзе ясый иде, – диде Гөлсем апа. – Ул безнең заманда гына чыкты. Әбиләр яшь чакта булмаган. Һәрхәлдә, әни шулай дип сөйли иде. Тормыш алга барган саен халык көнкүрешен яхшыртырга тырышкан. Кер юу тактасы җайлы инде: куллар бик суелмый, ышкый торгач, кара керләр агара.

Зур агач тагаракны да ир-атлар үзләре ясаган. (Әле без үскәндә дә чишмә улаклары агачтан иде. Су агып аның ян-яклары яшелләнеп беткән була.) Тагаракны кер юар өчен махсус тотканнар. Башта аграк керләрне, аннан кара керләрне шунда салып, яхшылап ышкып юганнар.

– Берьюлы икешәр, өчәр чиләк кер юдык, – диде әбекәй. – Керне ун көнгә, ике атнага бер генә юасың. Бик зур эш инде ул: казан астына ягып суны җылытырга кирәк, аннан исә көне буе чүгәләп утырып аяклар калмый. Куллар турында әйтмим дә.

Язманың видеоварианты да бар.

Эш беткәч, чәй табыны артына утырдык. Оештыру эшләрендә ярдәм иткәннәргә өчен Дөбъяз авылы мәдәният йорты хезмәткәрләренә зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

Гөлсем апа ун яшендә кер юганын хәтерли. Әтисе белән әнисе колхоз эшенә чыгып киткәндә, үсмер кызларына эш кушып калдырган. Көн саен яңа төрле эш.

– Безнең әни чисталыкны бик ярата иде, – диде әбекәй. – Әгәр чиста булмаса, идәнне дә, керне дә икенче кат юдырта. Шуның өчен дә керне башта җебетергә куя идек. Киемнәрне генә түгел, юрганнарны да юдык. Анысы инде җәй көне була, кышын киптерергә мөмкинлек юк. Хәзерге кебек атна саен мунча да тәтеми ул чакта. Бездә мунча юк та иде. Күршеләрдән рөхсәт сорап, мунча ягасың. Әле башта барып ул мунчаның идән-сәкеләрен юасың. Хуҗа кеше аннан сиңа рәхмәт әйтә: «Тагын ягарсыз, бер дә кыенсынмагыз», – дип кала.

Керне юу гына түгел, киптерүнең дә бер үзенчәлеге булган: башта яхшылап селкисең, аннан яулык, күлмәкләрне, читчитләрен таслап, җепкә эләсең. Кер кипкәч исә сырлы бәләк белән «үтүклисең». Хәер, бу очракта үтүкләү сүзе бик үк туры килми, тигезләү дип әйтү кирәктер.

– Кипкән керне түгәрәккә чорнап, аны сырлы бәләк белән кат-кат ышкыйсың. Керләр инде тигезләнеп, йомшап та китә, – диде Гөлсем апа.

– Ә күмер үтүкләре юк идеме? – дибез.

– Без бала чакта әле күмер үтүге юк иде, ул соңрак пәйда булды. Әни урын-җирләрне, яулык, күлмәкләрне дә сырлы бәләк белән ышкырга куша иде. Бәлки аны бөтен кеше алай эшләмәгәндер дә, төгәл генә әйтә алмыйм. Безнең гаиләдә кызлар булгач, әни кечкенәдән шулай эшкә өйрәтте. «Биткә кызыллык китермәгез. Кайнаналарыгыз: «Әниләре бер эшкә дә өйрәтмәгән», – димәсеннәр», – дия иде. Шуның өчен дә кечкенәдән кул арасына кереп, хезмәт белән тәрбияләндек.

...Нинди генә авыр заманнарда да халкыбыз пакь булырга тырышкан. Һәм заманга яраклашкан. Дөбъязга барып, Гөлсем апа Адаева белән танышкач, әнә шундый нәтиҗәгә килдек. Чисталык, тырышлык безнең канда шул.

*The effective technology**

Farmet 25 1992–2017

Майлы орлыклар, майлы үсемлекләр эшкәртү һәм комбиазык экструзиясе буенча белгеч

- Салкын ысул белән тыгызлау (пресслау)
- Кайнар ысул белән тыгызлау
- Экструзияләп тыгызлау
- Фильтрлау, рафинацияләү

Комбиазыкларны экструзияләү

Комбиазык заводлары

АО Фармет
Йиржинкова 276, 552 03 Ческа Скалице
Чехия Республикасы
Тел. +420 491 450 116
e-mail: oft@farmet.cz; **www.farmet.ru**

«Промтехника» ҖЧҖ Идел буе төбәгендә рәсми дилер
Михаил Миль ур., 39В, 2 нче офис, 420127, Казан ш., ТР, Россия
Моб. +7 917 395 65 38
e-mail: 2333124@gmail.com, s-petrunin@farmet116.ru.

Реклама

* эффектив технология

СЕРЛЕ МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

Руфия Фазылова

Аны берәү белән дә бутап булмый: әдәбиятта да, чыгышларында да... Киенү рәвеше, серле елмаю... – барысы да Марсель Галиевчә. Соңгы елларда ул тагын гаҗәпкә калдырды: Татарстанның халык язучысы фотога төшерү белән мавыга икән. Марсель абыйның фотолары да үзенчәлекле – агачта ул хан сурәтен күрә, ташларының күзе, авызы бар. Әйтәм бит, нәрсәгә алынса да, бер үзенчәлек таба.

– Марсель абый, Сез Такташның Алсуы кебек: «Үзе усал, үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле...» Сезнең әле кушаматыгыз да Купык икән. Холкыгыз буенча нинди сез?

– Бик нечкә күңелле мин. Менә шуны күрсәтмәс өчен кырыс булып күренәмдер. Хәтта бию караганда да күздән яшь чыга. Әйтик, югары дәрәҗәдә куелган балет. Сокланунның соң дәрәҗәсенә җиткәч, күз яшьләнә. Ә Купык кушаматына килгәндә, мин аны башта үзем кешеләргә куштым. Аннары инде ул үземә әйләнеп кайтты. (Көлә. – Авт.) Еш кына кешеләрдән: «Син купыкмы?»- дип сорый идем, янәсе, бөекме син? Кеше аңламыйча аптырап тора. Аннары ул сүзнең мәгънәсен аңлата башлыйм. Безнең авылда кызык сөйләшә торган халык яши, шуннан кергән сүз ул. Купык – яратып эндәшү. Кайчакта песиләргә дә шулай дип әйтәм. Бу кушаматны бик белмиләр, бары тик якыннан аралашкан берничә язучы шулай дип эндәшә.

– Яшьрәк чакта, аерым елларны санамаганда, сез гел ирекле булгансыз, ягъни

Фото: Александр Ефремов

даими бер җирдә генә эшләмәгәнсез. Моның сәбәбе нидә?

– Бер дә эшләмәдем дип әйтә алмыйм. КДУның журналистика факультетын тәмамлагач, биш ел Язучылар берлегендә эшләдем. Аннары дүрт ел «Казан утлары» журналында проза бүлеге мөхәррире булдым. Шуннан мине Мәскәүгә – М. Горький исемендәге Әдәбият институтының ике елга исәпләнгән Югары әдәби курсларына укырга җибәрделәр. Кайткач исә Язучылар берлегендә эшләп алдым. Аннан инде гел иректә хезмәттә булдым. Әмма беркайчан өйдә бикләнеп утырмадым – редакцияләргә йөреп, язучы, шагыйрьләр белән аралашып яшәдек. Хәзер дә шулай йөреп торам, кешесез яши алмыйм. Элек бит Язучылар берлеге бинасында кеше күп иде, күңелле яшәдек, төнге берләргә кадәр бильярд уйный идек. Анда утызар кеше җыела иде. Ул чакларны хәзер дә сагынып искә алам.

– Гафу итегез, Марсель абый, рәсми рәвештә эшләмәгәч, гаиләне ничек тәэмин иттегез?

– Ул вакытта язсаң гонорарны яхшы түлиләр иде. Дөресен генә әйткәндә, байлыкка беркайчан табынмадык. Ашарлык кына акча бар иде. Әти-әни авылда булгач, азык-төлекне аннан алып килдек.

Мин бит пропаганда бюросында эшләдем. Ул чагында язучының бер чыгышы 15 сум тора иде, ягъни бер мәктәпкә барып, үз иҗатың белән таныштырасың да акча аласың. Көненә ике-өч чыгыш ясап була. Менә шуннан язучының бер көнлек акчасын исәпләгез.

Хәтерлим, Хәсән Сарьян биш-алты көн шулай йөреп эшли дә ай буе өендә иҗат итә, чөнки бер баруда өчәр йөз сум акча алып кайта. Районнар буенча йөргән ул сәяхәтләребез турында аерым зурлап язарга дип торам. Аларның кайберләре турында яздым да инде.

– Сез азәрбайҗан, япон авторларының әсәрләрен, калмык галиме Әренҗән Карадауанның Чыңгыз хан турындагы тарихи монографиясен татар теленә тәрҗемә иткәнсез. Сез бу телләрне беләсезме? Ул халыкларның әдәбияты, мәдәнияте белән ни дәрәҗәдә яхшы таныш?

– Юк, телләрне белмим, мин аларны русчадан татарчага тәрҗемә иттем. Ә Чыңгыз хан монографиясенә килгәндә, мин ул хезмәтне яраттым. Дөресен генә әйткәндә, Чыңгыз хан турында җүнле әйбер юк иде. Ә Әренҗән Карадауан ачып бирә алган. Чит илгә эмиграциягә китә ул, шунда бакыйлыкка күчә. Мин ул китапны кырык елдан соң табып алдым да тәрҗемә итәргә булдым. Ничектер иҗат белән шөгыльләнә алмый торган бер чак иде ул, әсәр язарга

Кызыл Чын

Алтын күл

Газраил


Карт кедрның илһамы

кул бармый. Ә тәрҗемәгә утыра алдым. Сиксәненче еллар азагы, совет чоры бетүгә бара. Илдә булган вакыйгалар миңа авыр тәэсир итте.

– Сезгә бу сорауны биргәннәре бардыр инде, шулай да... Кайсысы күңелгә якынрак: прозамы, поэзияме?

– Проза. Хәзер шигырь язганым юк. Нишләптер поэзиядән читләштем.

– Сез яраткан жанр – «фотографика» турында да сөйләшик. Яшьтән фото төшерергә яратсагыз да, киң гавамга фотоларыгызны берничә ел элек кенә тәкъдим иттегез. Ни өчен?

– Унберенче сыйныфны тәмамлагач, үзебезнең Азнакай районы төзелеш оешмасына рәссам-бизәүче булып эшкә кердем. Ул бик бай оешма булып чыкты. Ул чакта безнең төзүчеләр Төмән шәһәрен салды. Акча күп. Профсоюз җитәкчесе: «Нәрсә кирәк?» – дип кенә тора. Шуннан мин бик яхшы фотоаппарат, камера һәм бик яхшы велосипед алдырдым. Мине комсомол секретаре итеп сайладылар. Менә шунда чын фотоаппарат белән эшләргә өйрәндем. Җиденче сыйныфта укыганда фото эшенә өйрәткәннәр иде. Ул чакта фотоаппарат ала алмадым, ләкин кызыксыну калды.

Беренче фотоаппаратым «Зоркий» иде. Аннары Nikon, Canon ишеләрне унлапны алыштырдым. Аннан исә цифрлы фотоаппаратлар чыкты. Алар белән эшләргә җайлы, нәрсә төшергәнеңне шунда ук карап та була. Менә шуның өчен дә профессиональ фотолар ясый башладым.

Рун язулы тау

– Рәссам-бизәүче булып төзелеш оешмасына эшкә алганнар, димәк, сез рәсемне оста ясаган?

– Балачактан рәсем ясарга ярата идем. Нәни бармаклар арасына карандаш кыстырып, акшарланган мич диварын төрле рәсемнәр ясап тутырганым хәтердә. Күбрәк кеше сурәтләре ясадым. Бервакыт әти миңа Бөгелмә базарыннан рәсем альбомы белән алты төстәге карандаш алып кайтып бирде. Ярлы балачакның көтелмәгән байлыкка тиенгән көне иде бу! И, шуннан көн дә рәсем ясыйм, күбрәк кеше сурәтләре. Әбием, боларны күреп, яныма килде дә бик серле тавыш белән: «Сурәтле өйгә фәрештәләр кермәс, диелгән Изге китапта. Мавыкма, улым. Кыямәт көнендә килеп, һәрберсе җан сорый башласалар нишләрсең?» – диде.

Шул төндә мин төш күрдем. Кыямәт көне җиткән, имеш. Мин офыкка тоташкан күк йөзе уртасында басып торам. Әллә нинди шөкәтсез бәндәләр, кулларын бутый-бутый, миңа кычкыра. Миннән җан сорыйлар, имеш. Манма тиргә батып, йокымнан уянып киттем. Бүтән рәсем ясамыйм дип, карандашларымны яшереп куйдым... Еллар узган саен күңелгә кереп оялаган курку хисе дә әкренләп суына барды. Үсә төшкәч, рәсем ясау белән янә мавыгып алдым. Тик инде күптән рәсем ясау белән шөгыльләнмим. Бәләкәйдән үк рәсем «әлифба»сын өйрәнү, чын остазлар канаты астында үсү эләкмәде. Шуның өчен дә үзешчәнлек баскычында калганлыгымны елдан-ел ныграк аңлый бардым.

– Марсель абый, фотосурәтләрегездә күбрәк таулар, чәчәкләр, агачлар... Ә тауларга мәхәббәт Чатыр таудан башландымы?

– Беренче тапкыр Чатыр тауны утыз өч яшемдә генә күрдем. Балачакта мин аңа ерактан гына карый идем. Чатыр тау туган авылым Балтачтан егерме биш чакрымнар тирәсе. Җәяү барылмаган инде, аннары, алай тауларга йөрү гадәте дә булмаган. Дөресен генә әйткәндә, мин яза башлагач кына популярлашты ул. Ерактан караганда әллә ни биек кебек күренмәсә дә, өскә менгәч, аның биниһая биеклеге күренә. Туфаннар көлә иде: «Түмгәк кебек тауны Джомолунгма кебек күтәрде». Ә чынлыкта ул Татарстанның иң биек нокталарының берсе, диңгез өслегеннән 321,7 метр биеклектә.

– Соңгы дүрт-биш елда берничә тапкыр Алтайга баргансыз. Кат-кат сәяхәт кылуыгызның максаты нидә иде: мәгърур тауларны фотога төшерүме, әллә инде борынгы бабаларыбызның эзен табумы?

– Алтайга күптәннән барырга хыяллана идем, иптәш кенә таба алмадым. Ниһаять, 2019 елда хыял тормышка ашты – июньдә

Ташны мендәр иткән нарат




Сарыклар

беренче тапкыр шагыйрь Газинур Морат белән сәфәр кылдык. Алтай табигатен Аллаһ үзе төшеп ял итәр өчен яралткан кебек: киңлекләре очсыз-кырыйсыз, искиткеч манзаралардан тора, карап чыгарга бер гомерең җитмәс. Шуңа да без, иркенләп йөрер өчен, машиналы гидны яллады. Бер урыннан икенчесенә машинада хәрәкәтләнсәк тә, җәяүләп йөрергә дә туры килде – ике мең чакрым юл үтеп, аяклар арган-талган иде...

Икенче тапкыр ике дустым белән бардык, алар язучы түгел. Аннары үзем генә булдым. Бер юлны белгәч, авыр түгел. Тагын Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат белән дә бардым. Сөйли торгач алар да кызыкты.

Алтайга бару балачак хыялы түгел иде. Тарих сәхифәләреннән борынгы бабаларыбызның Алтай-Саян төбәгеннән чыкканын белгәч, ул якка бару теләге елдан-ел көчәя барды. Алтайда кумандин дигән халык бар, куман – кыпчак дигән сүз. Европа галимнәре кыпчакны куман дип атый. Алтайда җирле халыктан: «Татарча беләсезме?» – дип сорагач, «Акча юк, дигән сүзне генә беләбез», – диделәр. Ата-баба телләрен оныткаңнар инде.

Алтай җирләрендә казу эшләре дә алып барыла. Шунда кеше сөякләрен табалар да: «Бу славян кешесе булган», – диләр. Килешмим. Төрки халык Европа халыкларының кыяфәтенә тартым. Казан татарлары, үзбәк, азәрбайҗан, Кырым татарлары, төрекмәннәрне мин Европа кешеләре тибында дип саныйм.

Татар халкын монгол йөзле кеше дип уйлау стереотибы киң таралган. Сәбәбен аңлатам: совет чорында тарихи фильмнар төшергәндә татар образларын казах, тува яки кыргыз артисты уйный иде. Шул вакыттан бирле безне кысык күзле булганбыз, дип уйлыйлар. Кысык күзле, җәйпәк йөзле кешеләр усал булып күренә. Бер таныш рәссамга да: «Нигә картиналарыңда татарларны кысык күзле итеп ясадың? Көзгегә кара әле, күзләрең кысылганмыни?» – дип кызыксындым. Ул моны «Так принято» дип аңлатты.

– Алтайга җәй дә, кыш та баргансыз. Таулар кайсы чорда матуррак?

– Алтайга июньдә барырга киңәш итәм. Мин үзем Алтайда яз, җәй, көз булдым. Көз анда бөтәнчәрәк, мисал өчен, Кырымдагы кебек агачлар төрле төсләргә буялмый. Ылыслы агачлар күп анда, шуның өчен дә көз килгәне бик аңлашылмый. Язын маральник (марал абагасы, рододендрон – ред.) чәчәк ата, таулар шәмәхә төскә керә. Тик узган ел мин барганда аның чәчәге беткән иде. Кызганыч, шул матурлыкны күрми калдым. Алтайны тагын күрәсе килә, әлбәттә. Тик анда бару елдан-ел кыйммәтләнә. Машина белән тауга менү генә дә 10 мең сум тора, ә вертолёт ялласаң, 80 мең түләргә кирәк. Белуха тавын якыннан күрәсе килгән иде, мөмкинлек булмады. Анда бары вертолёт белән генә менеп була...

– Алтайда туристлар өчен шартлар тудырылганмы?

– Барлык шартлар бар. Кунакханәләр биш йолдызлы ук булмаса да, йоклап, ял итү өчен менә дигән. Кирәк икән, табигать кочагында да кунып калырга мөмкин. Мәсәлән, Чалышман елгасының тирә-ягын биек таулар каймалап алган. Елга ярында кечкенә генә өйләр бар. Шуны арендага алып, яшәргә мөмкин. Һавасы саф, тирә-ягында утчәчәк, монгол чәе яки чагыр (бадан – ред.), эдельвейслар, эрбет агачлары үсә. Беркем борчымый, анда хәтта озынборыннар да юк, җәннәткә эләктеме икән, дип уйлап куясың. Туристлар өчен йортлар төзелгән, шифаханәләр салынган. Биредә маралларны (Алтай боланнарын – ред.), тау кәҗәләрен дә очратырга мөмкин.

– Тагын кайларга сәяхәт кылганыгыз бар? Кайларга барыр идегез?

– Шактый йөрелде: Кырым, Абхазия, Төркия... Тик барыбер янә Алтайга барыр идем, күреп бетермәгән җирләрем бар. Андый бай табигать бүтән җирдә юк бит.

– Марсель абый, бүген көнегез ничек уза? Иҗат белән шөгыльләнәсезме?

– Бер ел инде, бер нәрсә язганым юк. Күңел үсми. Сиксәненче еллар азагында шулай булган иде, анда да атом сугышы, фәлән дип сөйләделәр. Хәзер дә илдә, дөньяда барган вакыйгалар күңел тынычлыгын ала...

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Габделбари Баттал татар тарихында **нинди** эз калдырган

«Төшенкелеккә каршы» концерт **кайда** узачак

«Чутай» сүзе **нәрсәне** аңлата

Зөягә **ни өчен** кышын барырга кирәк

ГАБДЕЛБАРИ БАТТАЛ-ТАЙМАС – КҮП ТЕЛЛӘР БЕЛГӘН КАЛӘМ ИЯСЕ

Илдус Заһидуллин

XX гасыр башында кискен иҗтимагый һәм сәяси үзгәрешләр кайбер шәхесләрнең язмышларын гына түгел, исем-атларын да үзгәртә. Күренекле татар зыялысы Батталның мулла кушкан исеме Габделбәр булып, аңа Троицк мәдрәсәсендә укыганда иптәшләре кушкан Габделбари аты ябышып кала. Китапларын һәм вакытлы матбугатта мәкаләләрен ул төрле псевдонимнар куеп бастырып килә. Төркиядә яши башлагач, андагы реформа кысаларында исеменә тагын үзгәреш кертә. Татар һәм төрек халкына ихластан хезмәт иткән бу шәхесне җәмәгатьчелек Габделбари Баттал-Таймас дип белә.

ШӘКЕРТЛЕК ЕЛЛАРЫ

Габделбари Баттал 1882 елның 8 декабрендә элекке Самара губернасы Бозаулык өязе Яңавыл авылында Мәсрура һәм Габдулла Баттал гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә, биш балалы гаиләдә тәрбияләнә. Фамилиясе бабасының этисе Сәетбаттал исеменнән алынган була.

Оренбургның Кәрвансарай мәдрәсәсендә укыган абыйсы Гарифулла энекәшен үзе белән алып китә. 2-3 елдан соң Габделбари, остазы Хәсән хәлфәгә ияреп, Каргалы мәдрәсәсенә күченә, биредә нык мавыгып дини тәгълиматны өйрәнә. Аннары Троицк каласына китеп, «Рәсүлия» мәдрәсәсе шәкерте һәм аның җитәкчесе Зәйнулла ишанның мөрите була, гарәп телен һәм дин фәннәрен тирәнтен үзләштерә. Матур әдәбиятны сөюче һәм татар китабы белән сәүдә итүче Сабир Хөсәен хәлфәдән китаплар алып укый.

«Рәсүлия»дә хәлфә булып эшли башлаган 1904 елны Мифтахетдин Акмулла әсәрләренең беренче тупланмасы рәвешендә, шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен дә язып, «Акмулла» исемле китап нәшер итә.

КАҺИРӘНЕҢ РЕДАКТОР-ЖУРНАЛИСТЫ

1905 елда 23 яшьлек Габделбари Баттал белем эстәү максатыннан Каһирәгә бара. Ләкин университетка укырга керми, мөстәкыйль рәвештә белемен арттыру белән шөгыльләнә: курсларда хәзерге гарәп телен үзләштерә, әсәрләр укый. Мисырда гарәпчә мәкаләләр язып, Габделбари Баттал журналист һәм публицист буларак формалаша. Аның Россиядәге төрки халыклар турында язмалары үзе эшләгән «Әл-Җәридә» газетасында, шулай ук «Әл-Мөәййяд», «Әл-Мөкаттәм»дә һәм «Әл-Мәнар» журналларында дөнья күрә.

Баттал гарәпчә укып туплаган белемен татар шәкертләренә җиткерү юлларын да таба. 1908 елда Казанда аның гарәпчәдән тәрҗемә итеп язылган «Ислам философлары Мөхәммәд Габдеһ вә Җамалетдин Әфгани» һәм «Мәгыйшәт юллары» исемле әсәрләре Муса Габдулла псевдонимы белән бер-бер артлы дөнья күрә.

Ул 1907 елның ахырында Каһирәгә килгән Исмәгыйль Гаспралы белән якыннан аралаша. Гаспралы 1908 елның язында шәһәрдә үз фикерләрен тарату өчен гарәп телендә «Ән-Нәхдә» («Яңарыш») исемле газета чыгара башлый. Бу проект Бөтендөнья мөселманнары конгрессын оештыру кысаларында

Фотолар автордан алынды

башкарыла. Аның мәкаләләрен гарәпчәгә газетаның редакторы Габделбари Баттал тәрҗемә итә, ләкин язмалар гарәп җәмгатьчелеге игътибарын җәлеп итә алмый. 16 сан бастырылгач, газета чыгудан туктый.

Исмәгыйль Гаспралы белән аралашу Батталга нык тәэсир итә. Аның күңелендә милләткә хезмәт итү программасы шушы аралашу нәтиҗәсендә калыплашкан дип уйларга кирәк. Гаспралы киңәшен тотып, ул туган иленә кайта. Кайтышлый Бакчасарайда «Тәрҗеман» газетасының 25 еллык юбилее уңаеннан оештырылган мәҗлестә катнаша, күп генә күренекле шәхесләр белән таныша.

ОРЕНБУРГ ЖУРНАЛИСТЫ ҺӘМ ТРОИЦК МӨГАЛЛИМЕ

Габделбари Баттал 1908 елны туган иленә кайтканда югары хәзерлекле редактор-нәшир була. «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәрими моны таный һәм Батталны редакциягә эшкә ала, мәкалә-очеркларын бик теләп бастыра. Шул ук елны Габделбари хәрби хезмәткә алына, ләкин 1909 елның язында, нык авырып китү сәбәпле, аннан азат ителә. Оренбургта урнашып, «Вакыт» һәм «Шура» журналында күпсанлы мәкаләләр, очерклар бастыруын дәвам итә. Юльязмалары арасында журналистның 1910 елны Кавказга сәяхәтен тасвирлаган һәм шул елны аерым китап булып Оренбургта дөнья күргән «Кавказия мәктүпләре» игътибарга лаек.

XX гасыр башында Оренбург татар дөньясының интеллектуаль үзәгенә әверелә. Баттал биредә Ризаэтдин Фәхретдин, «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытырга килгән мөгаллимнәр Муса Бигиев, Габдулла Шинаси-Ибраһимов, шагыйрь Гобәйдулла Рәдуди, Җамал Вәлиди һ.б. зыялылар белән якыннан аралаша.

Шулай да дуслары һәм җәмгатьчелек чакыруы буенча 1910 елның көзендә Троицк каласына күченә һәм биредә өч уку елы дәвамында Яушевларның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә гарәп теле, татар тарихы һәм әдәбияты дәресләрен алып бара.

1910 елны, армиядән кайткач, туган авылы кызы Кафия туташка өйләнгән була, ләкин озак та үтми хәләл җефете тиф авыруыннан үлеп китә. 1913 елда Троицкида рус теле укытучысы Газизә туташка өйләнә. Бу бәхетле никахтан Билгивар исемле уллары туа.

Укытудан тыш, Баттал вакытлы матбугатта күпсанлы мәкаләләр белән катнаша һәм тарихи эзләнүләр алып бара. Мөгаллим 1909 елны урта мәктәп өчен дәреслек сыйфатында «Татар тарихы» китабын әзерләп бастыра. Автор шул елны «Шура» журналында башланган «Без татармы, төрекме?» дигән бәхәстә татарчылык фикерен яклаучыларның әйдәманына әверелә. Дәреслек берничә мәртәбә тулыландырылып бастырыла. Дүртенче басмасы 1938 елда Мукден шәһәрендә «Төрек-татар тарихы» исеме белән нәшер ителә.

Шулай ук шәһәрнең күренекле химаячесе, 1 нче гильдия сәүдәгәре Габделвәли Яушев һәм аның нәселе турында хезмәт тәмамлый. 1912 елда дөнья күргән бу китап матди байлык һәм иганәчелек ресурслары булганда, теләсә нинди сәяси режим шартларында милли мәдәниятне саклап калу, үстерүне тәэмин итү мөмкинлеген искәртә.

Габделбари Баттал, 1922 ел.

Габделбари Баттал хатыны һәм улы белән. Төркия.

«Йолдыз» газетасы.

1913–1917 ЕЛЛАРДА КАЗАНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1913 елда «Йолдыз» газетасының редакторы Әхмәтһади Максуди чакыруын кабул итеп, Баттал җаваплы сәркатибе вазифасын башкарырга Казанга күченә. Бу вакытка «Йолдыз», «алтын урталыкны» саклап, сәяси темаларга кискен кагылмый торган газета сыйфатында танылган була. Баттал да, сәясәткә караганда, әдәби эшчәнлекне өстен күрә. Аның тырышлыгы бушка китми, атнага 3 тапкыр бастырылган газета 5 тапкыр нәшер ителә башлый, абунәчеләр саны арта, сәркатип «Йолдыз»га яңа рух һәм җитдилек бирүгә ирешә. Аның «Йолдыз»да, яңа гына нәшер ителә башлаган «Мәктәп», «Сөембикә» журналларында басылган күпсанлы мәкаләләре авторны күренекле җәмәгать эшлеклесенә әверелдерә.

Баттал Казанда әдәбият галиме буларак та таныла. Дөресрәге, бу юнәлештә күптән алып барган эшчәнлеген яңа баскычка күтәрә. Ул Оренбургта яшәгәндә үк әдәбият мәсьәләләре буенча «Вакыт» газетасы битләрендә язышa. Әйтик, 1909 елгы бер мәкаләсендә әдәби әсәрне бәяләгәндә андагы фикернең яңалыгы һәм тирәнлеге, язучы теленең матурлыгы күз уңында тотылырга тиеш, дигән караш белдерә.

Татар нәзари фикере үсешенә багышланган Г.Сәгъди, Н.Хәлфин һәм Җ.Вәлиди хезмәтләре белән рухланып, ул «Нәзарияте әдәбия» китабын (1913) яза. Хезмәтендә Европа әдәбият теориясендәге алдынгы фикерләрне милли әдәбиятка яраклаштырып кулланырга тәкъдим итә, татар нәзари фикерендә беренче тапкыр төр һәм жанрлар теориясен эшләп чыга.

«Йолдыз»да әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкләгән Галимҗан Ибраһимов белән хезмәттәшлек итеп, 1914 елда татар мәктәпләре өчен «Яңа әдәбият» исемле хрестоматия әзерләп бастыра. Китап җиде бүлектән тора: Туган як, Җәй, Көз, Кыш, Табигатьтәге могҗизалы хәлләр, Бәйрәм, Иртә. Аларга соңгы биш елда әдәбиятта мәйдан тоткан язучылар, шагыйрьләрнең әсәрләре, алардан өзекләр сайлап урнаштырыла.

Баттал халыкка аңлату максатында 1917 елны «Өч төрле идарә ысуллары: чикләнмәгән монархия, чикләнгән монархия һәм җөмһүрият» исемле китап нәшер итә. Шул ук елны Сөембикә манарасы турында укыган лекциясе 1918 елда аерым китап рәвешендә дөнья күрә.

1917 елгы кискен сәяси үзгәрешләр уртак тел табып килешеп эшли белгән Батталның да холкына тәэсир итә. Николай I һәм варисы Алексейның тәхеттән ваз кичү хәбәре уңае белән язган мәкаләсе 16 мартта редактор Әхмәтһади Максуди тарафыннан танымаслык итеп кыскартып бастырылгач, ул протест йөзеннән редакциядән китә.

1917–1921 ЕЛЛАРДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1917 елгы Февраль инкыйлабы йогынтысында Казанда татар җәмәгатьчелеге арасында иҗтимагый-сәяси активлык арта. Баттал да бу хәрәкәттән читтә кала алмый. Гаяз Исхакый тәкъдиме белән ул Төркестанга җирле мөселманнарга сәяси оешмалар төзүдә ярдәм итәргә тиешле татар делегациясе составына кертелә һәм июнь аенда Ташкентта булып кайта. Куйган максат үтәлми, әмма ул биредә Садри Максуди белән якыннан аралаша. Соңгысы Төркестан комитеты әгъзасы сыйфатында төбәк белән вакытлыча идарә итәргә җибәрелгән Дәүләт Думасы депутатлары төркемендә була.

Казанга кайткач, Мөселман комитетының «Корылтай» газетасында җаваплы сәркатип булып эшли башлый. Газета, Вакытлы хөкүмәт эшчәнлеген, федератив-демократик республика һәм милли-мәдәни автономия фикерләрен яклап, совет хөкүмәтенең милли сәясәтен тәнкыйтьләп, мәкаләләр бастыра.

Баттал Казанда июль аенда үткән Берләштерелгән съездда Милли мәҗлес вәкиле итеп сайлана. Аның 1917 елның 30 ноябрендә Уфада ачылган утырышларында катнаша. Милли-мәдәни мохтәрият тарафдары була. 1918 елның 24 гыйнварында Казанга кайта һәм «Корылтай»да эшләвен дәвам итә. Ә апрель башында большевиклар газетаны яба.

Корылтайчылар төркеме Г.Мохтаров һәм Габделбари Баттал редакторлыгында «Алтай» исемле газета нәшер итә башлый. Элекке эчтәлекне саклаган газетаның 13 саны чыккач, татар большевиклары аны да ябып куя. Батталны сак астына алалар һәм, башка матбугат оештырмау турында язма вәгъдә алгач кына, иреккә чыгаралар.

Эшсез калган Габделбари Баттал, якындагы авылга күченеп, Мөхетдин Корбанга-

лиев һәм Хуҗа Бәдигый белән берлектә татар мәктәпләренә дәреслекләр эшли башлый.

Гражданнар сугышы Казанга да килеп җитә: аклар гаскәре кызылларны Казаннан куып чыгаруның икенче көне – 6 августта Баттал шәһәргә кайта һәм «Корылтай» газетасын (август уртасы – 5 сентябрь) чыгаруга алына.

Кызыл гаскәрләр Казанга якынлашкач, бер төркем мәсләктәшләре белән Самарага, аннан Уфага күчәнә. Бирелә 3 сентябрьдә Бөтенроссия вакытлы хөкүмәтен оештыруга багышланган киңәшмәдә катнаша. Үзен «Бөтен Русиянең бөек хөкемдары» дип игълан иткән адмирал Колчак 1918 елның ноябрендә аны тарата. Ә Милли мәҗлес һәм Милли идарә әгъзалары, 1918 елның октябрендә Көнбатыш Себердәге Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә тупланып, Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының Милли идарәсен оештыра. Габделбари Баттал һәм Каюм Мостакай дүрт ай дәвамында аның матбагасын – атналык «Маяк» газетасын нәшер итә. Колчак сәясәте Милли идарәне яптыра, «Маяк» та чыгудан туктый.

Кабат эшсез калган Баттал башта Чиләбегә барып урнаша, җәй көне аклар кулында булган Екатеринбургта мөселманнар өчен ачылган курсларда тарих фәне укыта. Кызыллар килү куркычы тугач, качакларга ияреп, Эрбет шәһәренә юнәлә. Аннан Төмән, Омск аша Томскига килеп җитә. Совет хөкүмәтенең 1920 елның 15 гыйнварындагы үлем җәзасын бетерү турында карарын ишетеп, бирелдәге мөселман коммунистлары оешмасыннан китаплар һәм матбугат кирәк-яраклары алырга җибәрелә дигән кәгазь юнәтеп, март башында гаиләсе янына Казанга кайта.

Баттал Казанда кулга алына, ай ярым төрмәдә утырганнан соң, шәһәр янындагы мәҗбүри хезмәт лагерена эшкә җибәрелә. Качу уена килеп, ялган документ белән 1919 елның 19 августында Идел буйлап пароход белән Әстерхан аша Бакуга бара. Ләкин Грузиягә китү планы барып чыкмый, кире Казанга кайтырга мәҗбүр була. Шәһәрдә эзәрлекләүләр көчәйгәч, 1920 елның кышында бер крестьян исеменә алынган паспорт белән кабат Казаннан китә. Сембердә ялган документ эшләтеп, завод өчен бер вагон товар алып баручы буларак, зур маҗаралар белән Петроградка килеп ирешә. Мәчет аша яңа документ юнәтеп, тимер юлга эшкә урнаша.

Бу айларда күп шәхесләр киләчәк тормыш турында фикерләшә һәм Россиядән китәргә карар кыла. 39 яшьлек Баттал да 1921 елның сентябрендә, су юлы белән качып, Финляндиягә чыга.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТОРМЫШЫ

Баттал 1925 елның ноябренә кадәр Хельсинки татар җәмгыяте мәктәбендә балалар укыта, үзлегеннән француз һәм фин телләрен өйрәнә, 1921 елны Россиядә ачлык вакытында Казан төбәгендәге милләттәшләренә ярдәм оештыра. Финляндиядә вакытта үзенең иң әһәмиятле фәнни хезмәтен – «Казан төркиләре» китабын яза. Китап 1925, 1966, 1988 елларда Төркиядә нәшер ителә. Төркия җәмәгатьчелеге дистә еллар дәвамында татар тарихын Баттал китабы буенча күзаллый.

Баттал 1925 елда Төркиягә, Истанбулга күчәнә. Тюркология институты өчен русча фәнни текстларны тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Ике елдан Әнкарага күчеп, Матбугат гомум мөдирлегендә рус теленнән тәрҗемәче булып урнаша. 1928 елда, ниһаять, Казаннан килгән гаиләсе белән кушыла.

1931 елдан Тышкы эшләр министрлыгында тәрҗемәче булып эшли. 1947 елда лаеклы ялга чыга.

Батталның Төркиядә язган беренче хезмәте «Русиядән киткән милләтләр» дип атала. Журналистлык шөгылен дә ташлап бетерми. Беренче мәкаләләрен «Казанлы» псевдонимы белән бастыра. Аның мәкаләләре күпсанлы газета һәм журналларда дөнья күрә. Шул исәптән «Вакыт» газетасында һәм «Төрек йорду» журналында XX гасыр башы татар милли хәрәкәтенең күренекле идеологы Йосыф Акчура турында берничә мәкалә, истәлекләр бастыра.

Төркиядә аның төп эшчәнлеге фән белән бәйле булып, беренче планга төрки телләр буенча сүзлекләр эшләү чыга. Ул Истанбулда үткәрелгән Беренче Төрек теле корылтаенда катнаша, Төрек мәдәниятен өйрәнү институтының хәбәрләшү әгъзасы итеп сайлана, Төрек телен өйрәнү җәмгыятен оештыручыларның берсе була. Галим «Якут теле сүзлеге»н эзерләүгә үзеннән лаеклы өлеш кертә, «Кыргыз теле сүзлеге»н бастыруга зур хезмәт куя.

Габделбари Баттал, лаеклы ялга чыккач, нигездә истәлекләр язуга зур игътибар бирә. 1917–1921 еллардагы татар иҗтимагый хәрәкәтендә күп генә «ак тапларны» бүген тарихчыларга Батталның «Рус ихтилалыннан хатирәләр» һәм «Мин бер яктылык эзләгән идем (Кызыл дөнья)» истәлекләре тупланган китаплары ачыкларга мөмкинлек бирә. Бу хезмәтнең соңгысы Казанда татар телендә дөнья күрде.

Ул, күренекле замандашлары, аларның язмышлары хакында уйланып, «Казан төрки мәшһүрләреннән» сериясен нигезли. Батталның «Ризаэтдин Фәхретдин», «Галимҗан Баруди», «Муса Җарулла Биги», «Ике Максуди» исемле китаплары бүген дә фәнни әһәмиятләрен югалтмаган. Шунысы куанычлы: бу хезмәтләрнең соңгы икесе, 1990 нчы елларда Казанда татар телендә бастырылып, киң катлам укучыга барып ирешә.

Габделбари Баттал-Таймасның күпьеллык иҗаты 87 яшендә өзелә. Җәсәде 1969 елның 27 апрелендә Караҗаәхмәт зиратында дәфен кылына.

Габделбари Батталның Казанда нәшер ителгән китаплары.







PRESSA

КОМПАСЛАР КИРЕГӘ ӘЙЛӘНГӘНДӘ, ЯКИ ЯЛГЫЗЛЫК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШИК

Луиза Янсуар

12 мартта Америка киноакадемиясе, һәр елдагыча, «Оскар» җиңүчеләрен игълан итәчәк. Быелгы иң яхшы фильмнар исемлегендә – «Аватар: путь воды», «Тар», «Топ Ган: Мэверик», «Фабельманы», «Элвис», «На Западном фронте без перемен», «Все везде и сразу», «Банши Инишерина», «Говорят женщины», «Треугольник печали» картиналары. Арада киң катлам аудитория өчен кызыклы булган, киң масштаблы уен тамашалары да, эстетикасы һәм социаль эчтәлеге буенча аерым бер зәвыкка ия публика өчен каралганнары да бар. Шуларның икесенә тукталып үтик. Алар бүгенге көннең аеруча куркыныч бер зәхмәте – котылгысыз ялгызлык турында...

Фотолар: goodfon.ru, kinopoisk.ru

«БӘЛКИ, СИН АҢА ОШАМЫЙ БАШЛАГАНСЫҢДЫР...»

«БАНШИ ИНИШЕРИНА»

Елы: 2022

Иле: Бөекбритания

Жанры: драма, комедия

Режиссеры: Мартин Макдонах

Сценарий авторы: Мартин Макдонах

Рольләрдә: Колин Фаррелл, Брендан Глисон, Керри Кондон, Барри Кеоган, Пэт Шорт, Гари Лайдон, Джон Кенни, Шила Флиттон һ.б.

Бүләкләре: 3 номинациядә җиңүче – «Алтын глобус» («Иң яхшы фильм», «Иң яхшы сценарий», «Иң яхшы ир-ат роле»), 9 номинациядә «Оскар»га тәкъдим ителгән.

«Мин нинди генә темага язсам яки төшерсәм дә, барыбер кара юмор килеп чыга», – дип шаяртырга ярата Макдонах үзе. Чыннан да, «караңгы драматургия» юнәлешендә 90 нчы еллар азагыннан, бигрәк тә нуленчеләрдә ул дөнья күләмендә иң танылган һәм куелган драматургларның берсе булгандыр, мөгаен. «Калека с острова Инишмаан», «Лейтенант с острова Инишмор», «Королева красоты», «Сиротливый запад», «Человек-подушка», «Однорукий из Спокана» пьесаларын театраль һәм мәдәни мохиткә нинди булса да кагылышы булганнардан ишетмәгән кеше сирәктер. Макдонахның сценарий авторы, режиссер һәм продюсер буларак «Залечь на дно в Брюгге», «Семь психопатов», «Три билборда на границе Эббинга, Миссури» кебек эшләре билгеле. «Банши Инишерина» бу исемлекне уңышлы дәвам итә.

Кино өлкәсендәге күпчелек белгечләр фикеренчә, Макдонах, ниһаять, иң шәп картинасын төшергән.

> Фильм котылгысыз һәм сүз табалмас дәрәҗәдә искиткеч – әйтерсең, борынгы ирланд балладасы. Биредә эпоха 99 ел элек дип бирелсә дә, ул Вакыт кысаларыннан ирекле, хәер, урын чикләреннән дә: Инишерин утравы Җир йөзендә юк бит. Ватандашы, абсурд остасы Беккетнең иң яхшы традицияләрен дәвам иткән әлеге иҗат җимеше – чын мәгънәсендә алтын стандарт.
> **Антон Долин, кино тәнкыйтьчесе***

Нигездә, бу әсәрнең сценарие драматургия материалы буларак иҗат ителә башлый. Инишмаан белән Инишмор турындагы 2 пьесаны тәгәлләүче өченче өлеш нәкъ менә «Банши с острова Инишир» була. Әмма Макдонах, пьесаны дөньяга чыгармыйча, фильм өчен саклый.

Сюжет бит гади: Инишеринда яшәүче гадәти бер ачыкавыз Падриак (Колин Фаррелл) гадәттәгечә дусты Колм (Брендан Глисон) өенә сугыла һәм аны пабка чакыра. Әмма тегесе, ни сәер, ишеген ачмый. Падриак аптырап кала – мондый хәлнең әле булганы юк бит. Сеңлесе Шивон янына кайтып, бу турыда әйтә. Шивон шаярып: «Ә бәлки син аңа ошамый башлагансыңдыр», – ди. Һәм, чыннан да, очрашкач, Колм Падриакка бүтән аның белән аралашырга, хәтта сөйләшергә дә теләмәвен әйтә. Аның хәзер бөтен кызыксынуы, әйтерсең, кулындагы скрипкасына һәм музыкага гына юнәлтелгән. Әмма Падриак җиңел генә бирешергә теләми – сәбәбен аңлатуын таләп итә. Һәм Колм ультиматум куя: әгәр Падриак аны ялыктырудан туктамый икән, ул һәр сүз кушкан саен бармакларын кисәчәк...

Фильмның сценарие искиткеч, бары тик Макдонах кына яза алган стильдәге диалогларга корылган. Чыннан да, бу картина, кырыслыгына карамастан, гаҗәеп наз һәм поэзия белән сугарылган. Күз явын алырдай матур һәм соклангыч пейзажлар арасында яшәгән гадәти кешеләрнең тормышы бик фәкыйрь куанычлардан тора. Әйтер-

* РФнда чит ил агенты дип табылган

сең, алар тирә-ягына әйләнеп тә карарга ияләшмәгән. Бары тик ара-тирә каршы яктан ату тавышлары белән шартлаулар ишетелсә генә, башларын күтәреп карыйлар. Анда да озакка түгел – материкта Гражданнар сугышы бара, әмма бу – аларның сугышы түгел, шуңа әллә ни исләре китми, алга таба яшәвен дәвам итәләр.

Картинаның исеменә чыгарылган «Банши» – Ирландия белән таулы Шотландия фольклорында үлем килүен хәбәр итүче феяларның берсе. Экранда ул бик тә колоритлы, кара ябынчадан йөри торган карчык – миссис Маккормик образында гәүдәләнеш таба. Баштарак без аңа әллә ни игътибар да итмибез – коргаксыган гәүдәле бер карчык инде шунда, әле тегендә, әле монда йөргәләп тора. Әмма, тора-бара, аның елмаюы, сәер сүзләре артында ниндидер сер барын абайлап алабыз. Ул фильмның башында ук атна азагына кадәр Инишеринда кемдер һичшиксез үләчәген әйтеп куя.

Фильмның буеннан-буена бер тема үзәктә – кешенең ялгызлыгы, алай гына да түгел, котылгысыз ялгызлыгы.

Һәм без, бу бер-берсен күралмас хәлгә килгән ике дусны еллар буена нәрсә берләштергән соң, дип баш ватабыз. Асылда, бернәрсә дә түгел, бары тик янәшә яшәү белән элеге дә баягы котылгысызлык. Ахыр чиктә, араларының ясалма рәвештә суынуы, өзелүе шактый аяныч һәм фаҗигале хәлләргә китерә. Югыйсә, Колм дустына бары тик вакыт узып барганны, һәм үзеннән соң мәңгелеккә нидер калдырырга теләве турында гына аңлатырга тели шикелле... Әмма тулы бер гомерне, уртак язмышны бер селтәнү белән генә тураклап ташлап булмый икән шул.

Макдонах әсәренә хас булганча, беркем дә беркемне аямый – эленеп куелган мылтыклар да, тиешенчә, ата. Әмма алар, шулай ук Макдонах стилендәгечә, бөтенләй без уйламаган тарафка ата.

Макдонах картинасының иң ягымлы һәм фәлсәфи геройлары – хайваннар. Әлбәттә, фаҗига аларны да аямый, әмма фильмның башыннан азагына кадәр без аларның ничек итеп кешеләргә хәерхаһлы булуын күзәтәбез. Алар «аңгыра бәндәләр»нең ялгызлыгын булдыра алган кадәр җиңеләйтергә тырыша, аларны җылыталар, көлдерәләр, юаталар... Ике аяклы җүләрләр хакына хәтта корбан да булалар.

Фильмдагы мөһим геройлардан берсе – Дженни исемле ишәк. Аның исеме чыннан да – Дженни, режиссер, ишәкне аптыраштa калдырмас һәм тилмертмәс өчен, бу исемне калдыра. Колин Фаррелл аның үзен чын йолдызларча тотуын, ягъни гел кәефсез булуын искә ала.

«ҺӘРКЕМ ДИРИЖЕРЛЫК ИТӘ АЛМЫЙ, БУ БИТ ДЕМОКРАТИЯ ТҮГЕЛ»

«ТАР»

Елы: 2022

Иле: АКШ

Жанры: драма, музыкаль фильм

Режиссёры: Тодд Филд

Сценарий авторы: Тодд Филд

Рольләрдә: Кейт Бланшетт, Ноэми Мерлан, Нина Хосс, Софи Кауэр, Марк Стронг, Аллан Кордунер, Мила Богоджевич, Мари-Лу Селлем, Джулиан Гловер, Адам Гопник һ.б.

Бүләкләре: иң яхшы хатын-кыз роле (драма) – «Алтын глобус», Британия академиясе бүләге, Актерлар Гильдиясе премиясе – иң яхшы хатын-кыз роле (Кейт Бланшетт), Венеция кинофестивалендә «Иң яхшы хатын-кыз роле» өчен Вольпи кубогы (Кейт Бланшетт), 6 номинациядә «Оскар»га тәкъдим ителгән.

Тодд Филд кискен темаларга сөйләшергә курыкмый торган, әмма бер үк вакытта гаҗәеп сәнгати нечкәлек, төгәллек белән эш итүче режиссёрлардан. Америка киноакадемиясе һәм тамашачылар тарафыннан инде күптәннән классика саналган «Как малые дети» драмасыннан соң, нигездә ул зур кинода хыялларын чынга ашырмый килде шикелле. Әйтик, берара Филд заманыбызның иң үзенчәлекле язучыларыннан булган Кормак Маккартиның «Кровавый меридиан» эпик романын төшерәчәк икән, дигән сүзләр ишетелгәләде. Ахыр чиктә, аның эзләнүләр квинтэссенциясе «Тар» фильмында чагылыш тапкан булып чыкты.

Венеция кинофестивале бүләген алганнан соң, бу фильмны «Кейт Бланшетт белән 2 сәгать ярымлык ужас симфониясе» дип атаганнар иде. Фильмга тамашачыларның да, кино тәнкыйтьчеләренең дә карашлары гаять каршылыклы һәм төрле. «Искиткеч!» дип күккә чөюдән алып, «Нәрсәгә безгә мондый кино!» диючеләргә кадәр. Шәхсән үземнең фикергә килгәндә, 2 сәгать ярымлык чын эстетик ләззәт, дияр идем. Кейт Бланшетт бу фильмдагы төп роле өчен инде хә-

Яңа картинасында Филд бик тә анык итеп Икс буыны вәкилен күрсәтә – бу бумерлар һәм миллениаллар арасында калган үзенчәлекле катлам. Берәүләр өчен Лидия Тар – ирләрдән дә болайрак уңышка ирешкән һәм талантка ия булган уникаль хатын-кыз, гендер өлкәсендәге прогрессның эталоны. Ә менә миллениаллар өчен ул, киресенчә, «иске тәртипләр» символы, аны пыран-заран китерергә кирәк, димәк. Бу җәһәттән караганда, без чорның ни дәрәҗәдә бер чиктән икенчесенә ташлана торган кыйммәтләр белән эш итүен аңлыйбыз.

Геннадий Устиян, кино тәнкыйтьчесе

зер үк мөмкин булган барлык бүләкләрне җыеп чыкты, әле «Оскар»ның да булуы фаразлана. Һәм, булган очракта, чынлап та лаеклы – экранда аның виртуозларча оста, бар нечкәлекләре белән дә таң калдыра, сихерле торган роленә чын мәгънәсендә гашыйк буласың.

Рольгә әзерләнгәндә, Кейт Бланшетт яңадан фортепианода уйнарга өйрәнә, немец телендә сөйләшә башлый, дирижёрлык буенча дәресләр ала. Кадрда ул чынлыкта Дрезден филармония оркестры белән идарә итә. Героинясы Лидия Тар өчен сөйләшү манерасын куйганда, Бланшетт Сьюзен Зонтаг язмаларын тыңлый һәм үзләштерә.

Фильмның 40 нчы минутларына җиткәндә, аның байопик түгеллеген бөтенләй онытасың. Һәрхәлдә, Тодд Филд 16 ел буе төшерергә әзерләнгән бу фильмының нәкъ менә сәнгать әсәре булуын ассызыклый, реаль шәхесләргә ишарәне эзләмәскә киңәш итә. Әмма бүгенге чынбарлык белән параллельләр үзеннән-үзе калкып чыга. Хәзерге алыштырулар культурасы чәчәк аткан, соң дәрәҗәдә агрессия котырган бер чорда бу картина безнең кешелек дәрәҗәбезнең ни бәя торганын тагын бер мәртәбә искә төшерергә чакыра.

Сюжет буенча, Лидия Тар – Берлин филармония оркестрын җитәкләүче беренче һәм бердәнбер хатын-кыз дирижёр. Ул гомумән – бик күп өлкәләрдә бер һәм бердәнбер. Экранда вакыйгаларның башында аның интервью биргән мизгелләре тәкъдим ителә – озын һәм барлык нечкәлекләре белән төшерелгән бу интервью асылда «чын», аны Бланшетт героинясы чын журналистка псевдогероинясы исеменнән бирә. Ул Малерның Бишенче симфониясе буенча эш ничек баруын, булачак китабынаниләр керәчәген сөйли. Без, Лидия артыннан ияреп, аның уңышлы һәм затлы тормышы белән яши башлыйбыз. Менә ул, банкир Каплан белән очрашып, яшьлеген һәм тормышындагы җиңүләрне искә ала. Аларның бергәләп хатын-кыз дирижёрларны яклар һәм үстерер өчен фонд төзегән булулары ачыклана. Аннары без аның белән бергә атаклы Джульярд мәктәбенә барып эләгәбез – биредәге студентлар һәм, шул исәптән, без дә беренче мәртәбә Лидиядәге агрессия һәм тирания чаткылары белән очрашабыз. Баштарак аңа моны гафу да итәбез – шулай иyaләшенгән, иҗат кешеләренә эксцентриклык һәм кәеф үзгәрешләре килешә, алар башка кануннар буенча яши, алар үзләренең энергиясен күп сарыф итә... Һәм без аларга еш кына барысын да кичерәбез. Әмма иҗатчы, үзенең омтылышлары һәм амбицияләре артыннан куа-куа, кайсы чиккә кадәр барып җитәргә сәләтле? Һәм, бер үк вакытта, аның нәзберек йөрәген, талантын аяусыз чынбарлык белән каршылыкта ничек саклап калырга?

Бланшетт героинясы – зур талантка ия шәхес, әмма бу талант кешелеклелек белән бергә керешеп китмәгән очракта, без аның нинди фаҗигагә китерә алуын да күрәбез. Асылда, без фильмның буеннан-буена Тар очрагында да, башкалар очрагында да бер үзенчәлекне күзәтәбез – ничек итеп кешедә югары илаһият белән җанвари инстинктлар көрәшә. Һәм кайсы кайсысын җиңә...

Тар фикеренчә, ул инде – шундый биеклектә, аңа беркемнең дә кулы җитмәячәк. Һәрхәлдә, күтәрелмәячәк. Әмма нинди генә пьедесталга менеп басмасын, кешене иң гади, хәтта ки гадәти нәрсәләр харап итә һәм юкка чыгара. Шул ук фанатлар булсынмы ул, янәшәндәге «дуслар», «көндәшләр», иң якын, ышанычлы кешеләрме. Талант белән хакимлек бергә кушылган очракта, хәтәр һәр адымда сагалый.

Фильмда буыннар арасындагы конфликт белән аерма да шактый кискен, авырттыра торган итеп күрсәтелгән. Әйтик, яшь музыкантларның инде исеме билгеле, алардан бер биш башка югары маэстрога якынаерга бернинди дә мөмкинлеге юк. Алар өчен ул, билгеле ки, Алла урынында. Әмма нәкъ менә шул Алланы юкка чыгарып, аның турындагы мифны, легенданы таптап уйнарга яратуны да күрсәтә безгә режиссёр. Лидия үзенең лекцияләре, мастер-класслары вакытында да, гадәти аралашулары яссылыгында да өзлексез ау объекты булуы турында уйлап та карамый. Әмма смартфоннар аны даими рәвештә фаш итеп тора – видеоларны туры эфир режимында күрсәтеп торалар, «кирәкле» чатларга да җибәрәләр... Бүгенге «цифра буыны» өчен изге берни дә юк икәнлеген Тодд Филд аерым калкытмый гына бик аяусыз итеп ассызыклап уза – сак булыгыз, дими, ә без моңа әзер идекме, дип сорый, бәлки.

> «Тар» сюжеты үз эченә реаль фигураларны һәм аларның язмышларын ала, әмма режиссёр махсус аларны ачыктан-ачык күрсәтмәүне кулай тапкан. Аның героинясы – җыелма образ. Фактлар яшерелгән, барысы да – ишарәләр, ымнар, сылтамалар рәвешендә генә. Димәк, шул рәвешле, картина акыллы, зирәк тамашачыга юнәлтелгән. Интерпретация өчен фильмда җитәрлек урын һәм колач бар.
>
> **Алина Рослякова, театр тәнкыйтьчесе**

Фильмдагы тагын бер үзәк өзгеч тема – кешенең үз асылын югалтып, дөнья шаукымына бирешүе, аның колына әверелүе. Менә шушысы чын мәгънәсендә төп эчке лейтмотив булып тора да. Бу яссылыкта без гениаль Лидиянең эчке иблисләре белән ничек көрәшүен күзәтәбез. Аның төшләренә, ул төшләрдәге котылгысыз лабиринтларга кереп күмеләбез, адашабыз, котылып, кире чыгабыз. Кайсыдыр бер борылышта бөтенләйгә адашу ихтималы барлыгын да тоябыз...

Филд бик сак кына, тамчылап кына өстәгән тагын бер бизәк – чын иҗат, шул исәптән музыка да, бар тик ярату халәтеннән генә туа ала... Яратудан ук булмаса да, сокланудан, гашыйклыктан...

Әмма бу темага фильмда безне артык чакырып тормыйлар. Күрәсең, дөньялыкның ышанулардан, иманулардан тоталь рәвештә баш тарткан бер чорында... безне котылгысыз хроник ялгызлыктан хәтта ул да коткарырга сәләтле түгел... Т

АСЫЛЫҢА КАЙТУ (12+)

Черкиле дигән татар авылыннан Сәфәргали карт Актау дип аталган башкорт авылына бара, шуның белән шул. «Сәфәр» спектакленең сюжеты әнә шундый гади генә. Ләкин геройларның һәрберсе өчен бу сәфәр газаплар аша үз-үзеңне тану, тәүбә итү һәм үз асылыңа кайту булып тора. Нигә шулай? Бу сорауга җавап алу өчен, тамашаның финалын көтәргә кирәк. Әгәр спектакль барышында геройларда үзегезне танысагыз, гаҗәпләнмәгез – сәнгатьнең чын көче әнә шул була инде.

22 март, 19:00

Г. Камал исем. ТДАТ. Казан, Татарстан ур., 1

афиша



СКРИПКА МОҢЫ – ЗАМАН ҺӘМ МОХИТЛӘР ЧАТЫНДА (6+)

Казанның La Primavera камера оркестры март аенда үткәрә торган L'arte del Arco («Искусство смычка») халыкара фестивале – тиңе юк вакыйга. Мөгаен, монда гына виола д'амур, виола да гамба, барокко скрипкасы, эрху, гиджак, кылкубызны, шулай ук альт, скрипка, виолончельне берьюлы ишетергә-тыңларга мөмкиндер. Төрле халыкларның төрле заманга караган хәзерге һәм борынгы кыллы-смычоклы уен кораллары оркестр белән соло жанрында яңгыраячак. Фестивальдә әле беренче тапкыр электр скрипкасы да булачак. Башкаручыларның исемнәрен атау да җитә: Марк Дробинский, Мария Крестинская, Александр Гулин, Татьяна Чулочникова, Чжоу Чженьчжен, Джовидон Хәсәнов, Максат Медеубек, Киира Клаус! Концертлардан тыш, алар яшь музыкантлар өчен бушлай осталык дәресләре дә уздырачак.

13 март, 18:30

С. Сәйдәшев исем. дәүләт Зур концерт залы. Казан, Ирек мәйданы

14 март, 18:30

«Җәлил» театр комплексы залы. Түбән Кама, Лемаев мәйданы, 2

19 март, 18:30

Орган залы. Яр Чаллы, Автозавод проспекты, 8, 25/05

20 март, 18:30

Казан, С. Сәйдәшев исем. дәүләт Зур концерт залы

Фото: tatar-inform.ru, kamalteatr.ru, afisha.ru, wikipedia.org, igorlerman.com

ТИМУР ҺӘМ АНЫҢ БАЛЛАДАЛАРЫ (16+)

Рок-фестивальләрдә дә, бардлар арасында да бердәй хөрмәт казанган башкаручы бик сирәк булырга мөмкин. Тимур Шаов – әнә шундый сирәк затлардан. Аның бик киеренке гастрольләр графигында – Америка, Израиль, Австралия, Германия, Франция, Канада...– рус телле тамашачы булган һәр җирдә аны көтеп алалар, аңа сокланалар. Бәлки, бу аның һәр җыры тормыш-чынбарлыгыбызның кечкенә генә булса да бер өлешен чагылдыргангадыр. Еш кына көлкеле, тагын да еш рак очракта күз яшьләре аша көлдерә торган моңсу мизгелләрне. Шаовны автор-башкаручыларның Жванецкие дип атыйлар. Хәер, нәкъ менә юмор катлаулы чорыбызда рух ныклыгын һәм яхшыга өметне саклап калырга ярдәм итә. Мөгаен, шуңа күрә концерт «Төшенкелеккә каршы!» дип аталадыр да.

18 март, 18:00

Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе.

Казан, Павлюхин ур., 73

КАЗАН – ГАСЫРЛАР АША (0+)

Билгесез рәссамның XVII гасырда иҗат ителгән «Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән» парсунасы, Кабан күле төбендә табылган XV гасыр казаны, Туктамыш чорына караган Алтын Урда хәзинәсе – әнә шундый һәм башка ядкәрләрне «Казан – гасырлар аша» күргәзмәсендә күрергә мөмкин. Ә Татарстан рәссамнарының биредә тәкъдим ителгән әсәрләре берничә йөз ел дәвамында шәһәрнең ничек үзгәрүе турында сөйли.

30 апрельгә кадәр керү иректә.

Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ВОЛЬФГАНГ-АМАДЕЙ ШИФАСЫ (16+)

Бөек Моцарт музыкасының гаҗәеп аһәңлелеккә ия булуы галимнәр тарафыннан исбатланган. Ул кешенең эмоциональ халәтенә генә йогынты ясап, киеренкелекне киметеп, иҗатка рухландырып кына калмый, организмның барлык системаларына көчле уңай импульс бирә. Шуңа күрә Игорь Лерманның камера оркестры башкаруында Моцартның мәңгелек музыкасы белән ләззәтләнеп, сез бер үк вакытта шифалы музыка дәвасы сеансын да узачаксыз.

15 март, 18:30

Орган залы. Яр Чаллы, Автозавод проспекты, 8, 25/05.

ТӨНГЕ ШӘҮЛӘЛӘР ШИГЪРИЯТЕ (12+)

Масон, Казан сәүдәгәре, бургомистр, шагыйрь... Болар барысы да бер кеше – Гавриил Петрович Каменев. Бу искиткеч шәхеснең гомер юлы, язмышы һәм иҗаты белән «Поэзия ночных теней» күргәзмәсендә танышырга була. Аның кызыклы исеме пиар ысулы гына түгел. Гавриил Каменев рус әдәбиятында баллада жанрына нигез салучыларның берсе, «готик» шигърият, «зират» поэзиясе жанрларындагы әсәрләр авторы буларак тарихка кергән. Аның кыска гомере күп очракта иҗатында да чагылыш таба. Каменев биографиясендә романтик сәнгать әсәрләренең төп өлешләрен күрергә мөмкин: иртә ятимлек, җилбәзәк яшьлек, бәхетсез мәхәббәт, ихлас рухи дуслык, бихисап илһам чыганаклары, иртә үлем...

1 марттан 23 апрельгә кадәр

Зөя тарихы музее, 4 нче корпус.

Зөя утрау-шәһәре, Успенская ур., 22

PRESSA

Татарстан авыллары

НУРЛЫ ЧУТАЙ

Фото: Александр Ефремов

ЧУТАЙ

Ул көнне мартның иртәсе буранлы иде. Балтачка җиткәндә ябалак-ябалак кар явуыннан туктады. Чутайга кергәндә инде ялтырап яз кояшы чыкты – авыл безне «елмаеп» каршы алды.

Руфия Фазылова

«ЗУР БҮЛӘК...»

Чутайның үзәк урамы буенча барып, мәдәният йортына килеп туктадык. Машина тәрәзәсеннән күзәтә бардык: яңа йортлар шактый. Аннары ни гаҗәп: каралмаган, ишелә башлаган өйләр күрмәдек. Үзәк урамда заманча ике зур бина бер-берсенә карап тора. Аның берсе – башлангыч мәктәп белән балалар бакчасы, икенчесе – мәдәният йорты. Белем-тәрбия үзәге әле яңа төзелгән, ә мәдәният йорты капиталь төзекләндерүдән соң икән. Беренчесе 55 миллион сумга төшсә, мәдәният йортын төзекләндерүгә 45 миллион сум акча сарыф ителгән. Болар барысы да федераль программа нигезендә эшләнгән.

– Мәктәп белән бакчаны берләштергән үзәк 2022 елның 10 гыйнварында ачылды, – дип сөйләде директор Рәмзия Хәйруллина. – Аңа кадәр балаларыбыз иске мәктәп бинасында укып торды. Бу безнең авыл өчен бик зур бүләк булды. Мәктәптә – сигез, бакчада ундүрт бала исәпләнә. Бакчабызга тагын бер бала килергә тора. Әле бер яше тулмаган сабый да бар, Алла боерса, тагын берсе туачак. Шулай булгач, белем-тәрбия үзәгебезнең киләчәге өметле.

Биредә бер Чутай авылы балалары гына укый һәм тәрбияләнә. Югыйсә заманында Чутай төп белем бирү мәктәбенә берничә авылдан килеп белем алганнар. (Беренче мәктәп авылда 1933–1935 елларда төзелә.) Бүген Чутай башлангыч мәктәбендә ике классны бергә кушып укыталар. Дүрт класска ике укытучы белем бирә. Бишенче

1

Үзәк урамда заманча ике зур бина бер-берсенә карап тора. Аның берсе – башлангыч мәктәп белән балалар бакчасы, икенчесе – мәдәният йорты.

2

Икенчеләр белән дүртенчеләр бер сыйныфта белем ала.

сыйныфка балалар күрше Нөнәгәр авылына барып укый икән.

Беренчеләр белән өченчеләр, икенчеләр белән дүртенчеләр бер сыйныфта белем ала. Акыллы күзле, сөйкемле йөзле әлеге балалар белән без дә таныштык. Бер дигән итеп татарча сөйләшәләр, татарча укыйлар. Шундый итагатьлеләр! Республика олимпиадаларында катнашып, урыннар да яулыйлар, сигез генә бөртек булсалар да, балалар берсеннән-берсе тырыш.

Белем-тәрбия үзәгенең рәсми исеме: «Советлар Союзы Герое Василий Булатов исемендәге Чутай башлангыч мәктәбе – балалар бакчасы». Геройның исемен яңа бинага күчкәч, ягъни 2022 елда кушканнар. Василий Булатов Чутайда туган, беренче сыйныфны биредә укыган. Мулла кушкан исеме – Габдуллаҗан. 1937 нче елларда Булатовларны, кулак дип, авылдан сөрәләр. Себер якларында үскән малай әнә шулай Василийга әйләнә. Чита шәһәрендәге Байкал аръягы укчы-миномётчылар училищесының иң тәртипле, тырыш курсанты була ул. Аның бик төз атуына командирлар да еш соклана. Бөек Ватан сугышында исә үзен оста пулемётчы, аннан бигрәк взвод командиры итеп күрсәтә: дошманның тулы бер взводка якын сугышчысын юк итә. Шушы батырлыклары өчен 1944 елның 23 августында аңа иң югары бүләк – Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Василий Булатов исән вакытта туган ягына кайтмый. Үзе вафатыннан соң гына балалары белән элемтәләр урнаштырыла. Әтиләренең кече ватаннарында алар берничә тапкыр булып, төп нигезләрен карап китә...

Яңа төзелгән бинаның икенче ягында балалар бакчасы дидем. Якты, иркен, җете төсләргә буялган ул. Зур гына спорт залы, йокы, уен бүлмәсе – барысы да заман таләпләренә туры китереп эшләнгән. Балаларны яшь ярымнан кабул итәләр.

3

– Программа буенча эшлибез, – диде тәрбияче Гөлнар Нургалиева. – Зуррак балалар белән әвәләү, рәсем ясау, хәреф өйрәнү кебек дәресләр уздырабыз.

4

– Бу үзәк безнең авыл өчен бик зур бүләк булды, – ди директор Рәмзия Хәйруллина.

5

Авылның үткәне турында Чутайда туган, гомере буе биредә яшәгән Наилә апа Заһирова сөйләде.

– Программа буенча эшлибез, – диде тәрбияче Гөлнар Нургалиева. – Зуррак балалар белән әвәләү, рәсем ясау, хәреф өйрәнү кебек дәресләр уздырабыз. Бу вакытта нәни балалар белән кече тәрбияче эшләп тора. Балаларыбыз үзара бик тату. Һәр зур балага бер кечкенә бала билгеләнгән. Ул аңа киенергә ярдәм итә, урындыгын алып бирә. Кыскасы, гел күз-колак булып тора инде. Шул рәвешле малай-кызларыбыз кечкенәдән ярдәмләшеп үсә. Бездә усал балалар юк.

ДИНЛЕ, ҺӨНӘРЛЕ АВЫЛ

Чутай Балтач районының иң төньягында, Киров өлкәсе чигендә урнашкан. Турыдан чыксаң, Малмыжга ун гына чакрым. Заманында биредә ике мәчет, ике мәхәллә, ике су тегермәне эшләгән, кыскасы, авыл зур булган. Мисал өчен, 1894 елда биредә 1154 кеше теркәлгән. Бүген Чутай әллә ни зур авыллар рәтенә керми – 125 йортта көн дә ут яна, 458 кеше яши.

Авылның үткәне турында безгә Чутайда туган, гомере буе биредә яшәгән Наилә апа Заһирова сөйләде. Әбекәйгә 82 яшь тулган, төпчек улы Илшат белән гомер итә. Мәрхүм җәмәгате белән дүрт бала тәрбияләп үстергән, алар гаиләләре белән Малмыжда яши икән.

– Бабаемның вафатына унбиш ел була инде, – диде Наилә апа. – Ул да Чутайныкы иде. Без үскәндә авылда җидееллык мәктәп эшләде. Күрше авыллар, хәтта Киров өлкәсеннән дә укырга килделәр. Укытучылар бик көчле иде безнең. Җидееллык мәктәпнең нәкъ Чутайда ачылуының бер тарихы бар: Нөнәгәр авылы халкы да белем үзәгенең үзләрендә булуын теләгән. Җыенда сөйләшеп уртак фикергә килә алмагач, Сабан туенда ике авылның иң яхшы ике атын узыштырганнар, дип сөйлиләр. Беренчелекне Чутай аргамагы алган, мәктәп язмышы шулай хәл ителгән...

Чутай халкы башка күрше-тирә авыллардан ата-бабаларыннан калган һөнәр-кәсебе белән аерылып торган. Монда игенчелектән тыш ташчылар (заманында Казан шәһәренең Арча кырындагы хәрби училище казармаларын да Чутай ташчылары салган), балта осталары, миччеләр, кыса ясаучылар, пыялачылар, итек басу-

чылар күп булган. Бүген бу һөнәрләрнең күбесе юкка чыккан. Шулай да биредә җир эшен ярату, күп итеп мал асрау гадәте сакланган. Һаман да җәен көтү чыга. Икешәр, өчәр баш сыер тотучы гаиләләр байтак.

Авылның мәчет тарихы кызыклы тоелды. Алда әйтелгәнчә, Чутайда ике мәхәллә булган. Авылда кеше саны күбәеп киткәнгә, җирле аксакаллар, түбән оч ягына да мәчет кирәк, дигән фикергә килә. Нәтиҗәдә, 1901 елда өр-яңа гыйбадәтханә төзеп куялар. Иң сөенечлесе – ул бина бүген дә исән. Меңләгән бүтән мәчетләр кебек үк, колхозлашу елларында аның манарасы киселә, шактый еллар ул амбар вазыйфасын үти. 2000 елда исә аның манарасы яңадан торгызыла, төзекләндерелә, һәм Аллаһ йорты үз асылына кайтарыла.

ЯШӘСЕН КОЛХОЗ!

Балтач районында әле дә колхозлар системасы сакланып калган. Шул исәптән Чутай авылында да. Хәтта аның исеме дә совет чорындагы кебек «Кызыл юл» дип атала, рәсми атамасы – авыл хуҗалыгы күмәк предприятиесе. Өч авылны берләштерә ул – Чутай, Нөнәгәр, Комаров-Завод. Сезон вакытында 140 лап кешене эш белән тәэмин итәләр. Хуҗалыкның сөрүлек җирләре – 4 мең 200 гектар, болынлыклар белән исә 4 мең 700 гектарга тула икән. «Кызыл юл» хуҗалыгы районда алдынгылар рәтендә йөри.

– Заманнан артта калмаска тырышабыз, – ди хуҗалык җитәкчесе Фердинанд Хәйруллин. – Барлык техниканы ГЛОНАСС системасына көйләдек. Сыер фермаларыбыз да заманча, дүрт ел эчендә зур комплекс салып чыктык. Бәясе бер миллиард сумнан артыкка төште.

Яңа төзелгән комплекс мең ярым баш савым сыерына исәпләнгән, анда 360 бозаулату торагы бар. Сыер саву заллары «карусель» программасына көйләнгән. Автомат җайланма күпме сөт савылганын, сөтнең майлылыгын, башка мәгълүматны шунда ук күрсәтеп тора. Бүген тәүлегенә 35 тоннадан артык сөт савалар.

– Эшчеләрнең уртача хезмәт хакы күпме? – дип кызыксынам.

– Сыер савучылар уртача 47 мең сум ала. Механизаторлар төрлечә, сезон вакытында 70 әр мең дә була, – ди җитәкче.

– Фермерларга дәүләт тарафыннан төрле субсидияләр, программалар каралган. Ә сезнең кебек күмәк хуҗалыкларга дәүләт бирәр ярдәм күрсәтәме?

– Күрсәтә. Мәсәлән, савым комплексын төзегәндә, егерме биш процентын дәүләт кучерде. Ул кайтарылмый торган субсидия формасында эшләнелә. Аннары чәчү вакытында ташламалы ягулык алабыз. Ә болай нигездә үз көчебез белән барабыз. Кыска сроклы кредитлар алганыбыз юк. Комплекс төзегәндә генә 197 миллион сум акча алган идек, шуны түлибез. Банклар каршында бүтән бурычыбыз юк.

«Кызыл юл» хуҗалыгы өчен узган ел уңышлы килгән. Кукурузны да кертеп, гектарыннан 54 центнер уңыш алганнар. Тик әле ул җыелган уңышның 70 проценты амбарларда саклана икән, игенгә бәя арзан булгач, сатасылары килмәгән.

Инде язганым бар – колхозлар системасы сакланып калган авыллар бәхетле. Монда Сабан туе, башка бәйрәмнәр дә тиешле дәрәҗәдә уза, чөнки күмәк хуҗалык андый чараларны үткәрергә финанс ярдәмен күрсәтә. Авыл кешесенә бәла-каза килсә дә, иң беренче булып алар кул суза. «Кызыл юл» хуҗалыгы да боларның барысын эшли. Әлегә кадәр авыл халкын су белән дә тәэмин иткәннәр. Ә менә юл салу, аны төзекләндерү халыктан җыелган үзсалым акчасына эшләнә. Миңа тагын бер нәрсә кызык тоелды – хуҗасыз ишелеп яткан йортлар күренмәсен өчен, аларны яшел койма белән уратып алганнар. Бу да күмәк хуҗалык эше икән.

Ни гаҗәп, колхозда эшләргә кеше юк, шуның өчен дә эшчеләрне күрше Мари Элдан, Киров өлкәсеннән алып киләләр. Мәсәлән, Максим Максимов – Мари Эл Республикасында туып үскән егет. Үзенең туган авылында эш булмагач, күрше Киров өлкәсендә эшләп алган. Бер ел элек җәмәгате белән бирегә күченеп килгән. Бүген ул – «Кызыл юл» күмәк хуҗалыгының баш агрономы. Җәмәгате исә мөгезле эре терлек санын исәпкә алып баручы.

– Башта Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамладым, хәзер Казан авыл хуҗалыгы аграр университетында читтән торып укыйм, – диде Максим. – Авыл кешеләре безне бик җылы кабул итте. Чутайда тырыш халык яши, алар белән эшләве рәхәт.

Күмәк хуҗалык читтән килгән белгечләр өчен махсус йорт салган. Барлык уңайлыклары булган заманча тораклар ул. Максим җәмәгате белән шуларның берсендә яши. Ир белән хатын бер ел эчендә татарча өйрәнгәннәр. «Чутайда безнең белән татарча гына сөйләшәләр», – диде Максим.

6

– Заманнан артта калмаска тырышабыз, – ди хуҗалык җитәкчесе Фердинанд Хәйруллин.

7

Яңа төзелгән комплекс мең ярым баш савым сыерына исәпләнгән.

Татарча дигәннән, авылда Киров өлкәсеннән килгән тагын берничә гаилә бар. Алар барысы да татар телендә аралаша икән. Балалары да Чутай бакчасына, мәктәбенә йөргәч, тиз арада татарчага өйрәнгән.

БЕРДӘНБЕР ЭШКУАР

Чутайда фермерлар юк, гомумән, Балтач районында бу юнәлеш алга китмәгән. Колхозлар системасы сакланып калгач, халык элеккечә эшләү, яшәүне хуп күрә. (Бәлки үрнәк күрсәтүче дә бик юктыр.) Авылның бердәнбер шәхси эшкуары – Ринат Гарипов. 2004 елдан бирле техникаларга запас частьлар сату белән шөгыльләнә ул. (Банкротлыкка чыккан хуҗалыклардан иске техниканы сатып ала, төрле оешмаларга, колхозларга сата.) Авылдашлары аның турында җылы фикерләр әйтте – бәйрәмнәрдә даими ярдәм итә, үзсалым акчасын җыйганда да башкаларга караганда бик күпкә артык акча бирә.

– Без үскәндәге авыл юк инде, шуңа борчылам, – диде Ринат абый. – Бер сыйныфта кырык бала укыдык, хәзер менә бөтен авылына шуның кадәр бала. Нишләтәсең, ил күләмендә шул хәл. Әле безнең татар авылларында тормыш барыбер әйбәт. Эш буенча чит төбәкләргә еш йөрим – юлсызлык, суы юк, газы кермәгән. Әнә, ерак барасы түгел, күрше Мари Эл Республикасындагы, Киров өлкәсендәге авылларга күз салу да җитә.

Ринат абый җәмәгате Фирая апа белән өч бала үстергән. Балалары Казанда яши. Гариповлар сыер, атлар асрый, кош-корт үрчетәләр, тормышлары нык. Хуҗа кешенең бер фикере кызык тоелды:

– Шактый еллар әти-әни белән яшәдек, – диде Ринат абый. – Алар мәрхүм инде, урыннары оҗмахта булсын. Үзебез алар яшенә җиткәндә генә шуны аңладым: яшьләр белән өлкәннәр аерым яшәргә тиеш икән. Менә хәзер балалар җыелышып кайталар. Бик рәхәт, сөенешәбез. Берничә көн яшәгәч, арып китәсең. Тынычлыкта яшәргә өйрәнгән бит. Аннары, яшьләргә дә авыр – өлкән кешенең үзенчә эшлисе килә, ягъни йортта бер генә хуҗа була ала. Син гел әти-әниең кушканча яшәргә тиеш буласың.

Ринат абый белән Фирая апа һәр көнгә сөенеп яши. Хуҗалыкта эш бүленгән: хуҗабикә сыерны карый, сөтен савып, каймагын, катыгын ясый. Хуҗа исә атлар үстерә. Ит ыслый торган миче бар, ел әйләнәсе балаларына да җитәрлек тәмле ит әзерли.

...Балтач халкы тырышлыгы белән аерылып тора: тыйнак, күп сөйләмәс алар. Бу якларда хәтта кеше яшәмәгән нигездә дә кычыткан, каты кура үсми. Бер дә булмаса, күрше кеше, чүпкә батып ятмасын дип, шул ялгыз калган йортны карап тора. Матур, үзебезчә итеп яши белән Балтач халкы. Чутайга баргач та шуңа тагын бер кат инандык. Т

8
Максим Максимов бер ел элек җәмәгате белән бергә көченеп килгән.

9
Авылның бердәнбер шәхси эшкуары – Ринат Гарипов.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Академик Гомәр Саттаров әйтүенә караганда, Чутай (Чути) «нур», «яктылык» мәгънәсен аңлата, борынгы болгар-татарга хас кеше исеме бу. Идел-Чулман болгарларының кабер ташы язмаларында да Чутай исеменең барлыгы галимнәргә билгеле. Филология фәннәре докторы, академик Мирфатыйх Зәкиев «Чутай-Чутый» исеменең асылында җау+тый сүзләре ята һәм ул «күз явын алырдай» дигән мәгънәне белдерә, дип саный. Карачай-балкарлар арасында Чотай исемле кешеләрне бүген дә күрергә мөмкин. Димәк, бер хәерле болгар бәндәсе борынгы Чутай нигезенә беренче йортны салган булырга тиеш. Без, чутайлылар, шул Чутай исемле болгар-балкарның варисларыдыр.

Харис Салихҗан, «Чутай бабай малайлары» китабыннан

ай кәфе: карлы

ЮГАЛМАГАН УТРАУ

Сезнең кайчан да булса утрау-шәһәрдә булганыгыз бармы? Юк, храм, кафе, таш түшәлгән урамнарда, хәтта сукмакларда да туристлар ташкыныннан тын кысылган җәй көне түгел. Кышын, эш көннәрендә – утрау-шәһәр, тынычланып, йокымсырап, карга күмелеп утырган чагында.

Ул вакытта Зөя, нәкъ өч йөз ел элек кебек үк, кабат утрауга әверелә. Тыныч, уйчан, дөнья ыгы-зыгысыннан, һәртөрле вәсвәсәләрдән бушап калган мәл. Бары тик аяк астындагы карның рәхәт шыгырдавы, каяндыр ерактан ара-тирә ишетелгән тонык чаң тавышы һәм кайчак берәр әрсез сәүдәгәрнең: «Ыысланган чехонь, магнитлар, бәхеткә – дага, алыгыз, алмый китмәгез», – дигән өметсез тавышы гына бу илаһи тынлыкны боза кебек.

«Туңдырма» дип язылган күрсәткеч тә сезне каядыр кар көртенә юнәлтә, кыш көнне бушап, нәүмизләнеп калган елга вокзалы да оялчан гына кар көртенә күмелеп утыра, Иван Грозныйның яшьтәше – агачтан ясалган Успение чиркәвенең гөмбәзләре дә гүя кар өемнәре артына яшеренгән. Һәм сез, бу гаҗәеп тынлыкта калып, моржадан чыккан әчкелтем төтеннең алкаланып өскә күтәрелүен күзәтәсез.

Тынлыкка мөкиббән китеп, бәйләнчек экскурсоводлардан башка гына, рәхәтләнеп, храмнар арасында йөрисез. Үзегезнең күптәнге хыялыгызны тормышка ашырасыз – ниһаять, менгәндә алдыгыздагы кешенең аягына абынмыйча, берүзегез генә чаң манарасына күтәреләсез. Ә өстә, каршыгызда ачылган күренешкә хәйран калып, карашыгызны ерак офыкка барып тоташкан карлы манзарадан ала алмыйча, рәхәтләнеп ял итәсез.

Аннары, Мәңгелекне искә төшереп, галәмне күрү бәхетенә ирешкәндәй, кире җиргә төшәсез һәм ерак түгел генә кафе барлыгын шәйләп аласыз. Андагы хуҗаның Бакурианидан булуы, аның грузинча чын хачапури әзерләве турында, әлбәттә, ишеткәнегез бар. Кафеда да тынлык хөкем сөрә, ыгы-зыгы юк – бары тик сөйкемле хуҗабикә һәм авызда март кары кебек эреп китә торган кайнар хачапури гына...

Кышын бер дә Зөядә булганыгыз юкмы? Әле өлгерәсез – быел март карлы килде.

Фото: Эскар Сабиров

МОРОЖЕНОЕ
ICE CREAM
НАПИТКИ

ТАТМЕДИА

shop.tatmedia.ru

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+ Реклама